Безнең МИРАС
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
03
март 2018
ISSN:2500-011X
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ГАЙШӘ РАХМАНКУЛОВА. «КИЗИЛ ЧӘЧӘК АТКАНДА»

Кастамону – төрки дөньяның мәдәни башкаласы

2018 елда ТӨРЕКСОЙ халыкара оешмасы, төрки дөньяның мәдәни башкаласы итеп, Төркиянең Кастамону шәһәрен игълан итте. Безнең эрага кадәр XVIII гасырда нигез салынган бу борынгы шәһәр суфыйчылык мәркәзе, әүлияләр җире буларак билгеле. Төркиядә иң күп мәчетләр Кастамону провинциясендә төзелүен дә шуның белән аңлаталар. 360 мең кеше исәпләнгән төбәктә мәчетләр саны 2,5 меңгә җитә. 2018 елда ТӨРЕКСОЙ оешмасына 25 ел тула. Кастамонуда ел дәвамында төрки халыклар катнашында узачак мәдәни чаралар шулай ук әлеге истәлекле вакыйгага да багышланачак.

Лилия Гаделшина тексты һәм фотолары

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең мирас 12 +

03 (291)

март 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

28

40 Татар хатыны
нилләр күрми?
Илфар Габдрахманов

88 Кала юлы яки
качкын малай.
Хәлим Җәләй

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Саҗидә Сөләйманова

ТАРИХИ МИРАС

4 Нурсолтан. *О.Иванова*
12 Татар авылы: үткәне һәм бүгенгесе
15 «Бүз егет» белән «Таһир-Зөһрә»не язучы кем булган? *Г.Рәхим*
18 Күшәр морзалары. *Г.Рәхим*
20 Солтанайның солтаны. *Г.Мәсәгутова, А.Габдукаева*
28 Асылында ни, Русия? *Р.Хафизов*
34 «Сәнәкчеләр» фаҗигасе. *Г.Мостафина-Рәфыйкова*
40 Татар хатыны нилләр күрми? *И.Габдрахманов*
45 Каюм Насыйри хатлары

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

48 Сөрген шагыйре

ТАТАР ГАМЕ

50 Татар кайда да татар...
55 Безнең заман каһарманы. *Р.Батулла*

ДИНИ МИРАС

60 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
66 Хөсни хат. *М.Галләм*

ПЕДАГОГИК МИРАС

68 Уку китабы. *Х.Әбүзәров*

ӘДӘБИ МИРАС

72 Мәхмүт Хәсәнов хатлары
76 Милләтем, дип, халкым, дип... *К.Булатова*
80 Кыңгыраулар җыры

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Ленар Гобәйдуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррирләре
Марат Закиров
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

82 **Абдулла Алиш әкиятләренең басма вариантларындагы үзгәрешләр.** *Р.Мозаффаров*
85 **Мәктәп-музей**

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

86 **Фатих Сәйфи-Казанлы**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

88 **Кала юлы яки качкын малай.** *Х.Җәләй*
92 **Истә, һаман да истә!**
94 **Саимә апа, дисәм...** *Л.Лерон*

СӘНГАТИ МИРАС

99 **Кем ул Васил Әхмәтҗанов?**

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

106 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

108 **Киез итекләр иле**
111 **«Эш» газетасы**
115 **Гани Сафиуллин мирасы**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Март*

Заказ №Е-416. Тираж – 1960 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 21.02.2018
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан алынган фотосурәтләр, шулай ук томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Кизил чәчәк атканда»**. ***Г.Рахманкулова*** рәсеме. *Кәгазь, акварель*

Безнең мирас №3 март 2018



Саҗидә СӨЛӘЙМАНОВА

(3.10.1926-10.05.1980)

САТЫЛМАСКА

Казан. Печән базарында
Кәвеш-ката, чалма-чапан.
Үтә маллар, китә даннар,
Гөрли базар:
– Сатам, сатам!

Тәфтиләүләр сызып сула,
Зиләйлүкләр тора чатта.
Сәүдәгәргә кәеф-сафа –
Ала-сата, ала-сата
Яшь кызларны, намусларны...
Кайда да бер аңа ватан,
Иле ни дә, теле ни соң, –
Шул ук базар сүзе:
Сатам...

Сатылмаска һәм сатмаска –
Тукай анты, шагыйрь анты.
Ана каберендәге ташка
Тамган яше ачы, татлы.

Туган илгә, туган телгә
Тугры Тукай һаман сафта.
Мәрмәр ташта
Чакматаштай
Тора Тукай:
– Сатылмаска! ■

Безнең мирас №3 март 2018

НУРСОЛТАН

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән

Романның, журнал варианты буларак, шактый кыскартылган өлеше генә тәкъдим ителсә дә, өзлексез җеп булып сузылган драматик сәхифәләре белән таныштыруны дәвам итәбез. Хөрмәтле укучыларыбыздан аның турында фикер туплап яза башлауларын соравыбыз – бу, бәлки, аның агышын тизләтә төшәргә ярдәм итәр, дигән нияттән. Элемтәгә керү юлы бик кыска һәм гади: электрон почта адресыбыз – valeevtx@mail.ru. Мөмкинлек табып, кайдан язуыгызны һәм исем-шәрифләрегезне дә күрсәтсәгез, аеруча рәхмәтле булырбыз.

Мөдәррис Вәлиев.

Көзге көннәрнең берсендә Шаһназның бакчада йөреп аласы килде. Ул һәрвакыт ялгызы гына йөрергә ярата: тинтәк хезмәтчеләр һәм нечкә, чәрелдек тавышлы хәрәм агалары үзара сөйләшүләре белән аның ачуын чыгара, ә көндәше Фатыймасолтан дуамал холыклырак яшь бикә тирәсендә беркайчан да күзгә чалынмый. Ул көнне Шаһназ, үзенең матурлыгы белән бөтен дөньяның һушын алырга теләгән кебек, иң затлы бизәнү әйберләрен тагып чыгарга булды. Тимер морзабәк кызы, әкәмәт көмеш бизәкле кысага утыртылган

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2018) санында.

зур көзге каршысында бөтерелеп, үз-үзенә сокланып туя алмады. Кемнең әле шундый кысык кара күзләре болай ялтыраганы бар икән? Тагын кайсы чибәрнең шәһвәт белән тулы иреннәрен татлы чия белән чагыштырып була? Бай итеп чигелгән кәзәкиен җайлап, Исфахан атласыннан тегелгән киң чалбарындагы төрле төсләргә кереп ялтыраган бизәкләргә сокланып торгач, Шаһназ хезмәтчеләренә көмеш парча астарлы, ак мех белән укаланган тунын җилкәсенә салырга ризалык бирде. Инде шуннан соң, үзенең исләр китәрерлек булуына тәмам ышанып, бакчага чыгып китте.

Яшь бикә, тынып-катып калган сөңгеле-айбалталы сакчылар янынннан горур гына узып, һичкайчан як-ягына карамый торган иде. Ләкин бу юлы бакчага керер алдыннан кинәт туктап калды. Капка төбендә торган яшь сакчы ерак Нугай даласында калган Хөсәенгә бик тә охшаган кебек тоелды. Сулышы капканын тоеп, ул хәтта йөрәгенә тотынды. Яшь хатынның чибәр йөзен, бәләкәй баш миен яктыртып, шундый акылсыз фикер чуалып алды: «Бәлки, Хөсәеннең миңа дәрте кузгалып, яшертен генә Казанга килгәндер дә сакчы кыяфәтендә өемә үк үтеп кергәндер?» Ул укыштыргалаган китапларда шундый хәлләр еш очрый иде бит. Шуңа күрә Шаһназ үз хыялларының чынбарлыктан бик ерак торганы турында уйлап та карамады. Шундый шәйтани уйга бирелеп, ул сакчы егет каршысына барып басты да матур япмасын бер читкә атты. Тагын бер мизгелдән аның Хөсәен түгел икәнлеген күрде. Дөрес, алдындагы егет күзләрне камаштырырлык шәп, ул аңа һич тә онытылмый торган зәңгәр күзләре белән сокланып карап тора иде...

Капка янындагы бу очрашу Шаһназның бөтен тормышын әйләндереп каплады. Бала чагыннан ук Хөсәенгә булган самими тойгылары хәзер кинәт кенә ифрат зур, акылны алып китәрдәй көчле, дәртле дулкынга әверелде. Иренең бакчасын саклаучы егеткә гашыйк булуын баштарак хәтта үзенең дә таныйсы килмәгән иде, әмма вакыт узган саен, бу тойгының котылгысыз булуына ышана барды. Шуннан куркып, берара бакчага бөтенләй чыкмаска тырышты Шаһназ. Кургаштай авыр-кырыс күк йөзеннән коелган көзге яңгыр да аның бу ниятенә булышкан кебек иде. Ләкин тиздән, бакча сукмакларын һәм агачларны ак мамык келәм белән төреп, кыш килеп җитте дә, Шаһназ тыныч карлы сукмаклардан кабат йөри башлады. Ул яңадан очрашуны сабырсызланып көтә, чөнки йөрәген яулаган егетнең кайсы көннәрдә бакча капкасы төбендә торасын төгәл белә иде. Бу көннәрне Шаһназ, һич онытмыйча, бакчага чыга һәм аннан чиксез бәхетле булып кайта. Ул сагышлы сулыш алганда егетнең дә йөрәге тыныч кына типмәвен аңлый. Алар, бер-берсенә сүз катмыйча, күпмедер вакыт шулай күзгә-күз карашып торалар. Әмма күзләр очрашуы никадәр мәгънә аңлата иде! Саташтыргыч хәтәр уен аларны акылсызлык чоңгылына тартып керткәннән-кертә барды.

Ике яшь йөрәк язмышы хәл ителгән ул көндә Шаһназ беренче тапкыр аның белән сөйләшеп карарга батырчылык итте. Ә ир-егет аның башлап эндәшүен генә көтеп торган икән. Кояш астында кипкән-коргаксыган җир кебек, Шаһназ аның дәрт белән янган зәңгәр күзләре җылысында эреп, сокланып туймаслык мәхәббәт сүзләрен тыңлады.

– Гүзәл хуҗабикәм, мин Сезгә бәйле колыгыз гына. Әгәр мин кара төн булсам, Сез – минем алтын аем, әгәр якты көнмен, дисәм, Сез – күзләремне камаштыргыч кояш! Сездән гүзәлрәк хатын-кызны күргәнем бар микән минем? Сезне күрми торганда йөрәгем сусаудан туктамый, ә карашымны сагыш баса. Сез – минем күзләремә дәва, ә тавышыгыз колагыма бал булып агыла...

Үз-үзен белештермичә, күңелен яулаган ир-егеткә каршы атлады Шаһназ, гашыйкларның куллары бергә үрелде, ә егетнең иреннәре кайнар пышылдавын дәвам итте:

– Минем Сезнекедәй тансык иреннәрне татыганым юк. Алар чүлдәге чишмә кебек. Әй минем хакимем, бер үбәр өчен, мин үләргә дә әзер...

– Соң, алайса, сиңа нишләп әле чынлап торып үлмәскә! – Шаһназның артында иренең усал, үтә саркып торган тавышы яңгырады.

Шаһназ, агарынып, артына борылды. Ибраһим солтан, кулына тоткан камчысын уйнатып, алар каршысына ук килеп баскан иде. Нәфрәтле карашы белән яшь хатынын баштанаяк күздән кичереп, ул артындарак торган нукерларны (хезмәтчеләрен) дәшеп алды:

– Бу акылсызны минем базыма ташлагыз, шунда без уртак тел табарбыз, дип уйлыйм. Ә бикәне бүлмәсенә кертегез, аның белән нишлисен мин үзем соңыннан хәл итәрмен.

***

...Шаһназ нукерлар базга алып киткән сакчының хуҗасына бер сүз дә әйтмәгәнен белмәде, чөнки солтан, икәүдән-икәү генә калу белән, шунда ук аның башын чабып өзәргә өлгерде. Ибраһимны бу адымга ачуы килү генә түгел, ә гап-гади ният этәргән иде бу мәлдә. Инде берничә ел дәвамында тормышының төп максаты – хан варисы булып тәхеткә утыру бит. Хәлилдән ул бары бер генә яшькә кече, әмма аңардан олырак күренә. Озын буйлы, нык, саулыгы ташып торган кыю сугышчы, аны казаклар ярата, карачы бәкләр дә таный. Нишләп булачак хан түгел ди әле ул? Тик этисе сыек буынлы, чирле Хәлилгә ныклап торып ябышкан, Ибраһим бары шуның аркасында абыйсын эчтән генә күралмый. Шулай да аның яшерен хыялыннан аерыласы килми. Әкрен-әкрен, ләкин алдан исәпләнелгән адымнар белән, Ибраһим, казаклар, угланнар һәм бәкләр арасында үзен курку белмәс, бар эше дә уң булып бара торган солтан итеп танытырга тырыша. Казан дәүләтенең менә шул дәһшәтле, тәэсирле көчләре Мәхмүд ханның вафатыннан соң тәхеткә аны мендерер, дип өметләнә. Шундый зур хезмәт куеп ясалган илаһи сурәт бу фахишә нугай кызының тотнаксызлыгы аркасында күз ачып йомганчы ишелеп төшәргә мөмкин ләбаса! Яшь хатыны аның үз сакчылары белән чуалганын белсәләр, солтан турында ни генә сөйләмәсләр? Шул ук вакытта әнә Хәлилнең хатынын мактап туя алмыйлар.

Ул иртәдә, Шаһназ йоклаган бүлмәгә кергәндә, аның фикере катгый иде инде: берниндә дә шәригать хөкеме булмаячак! Мондый ахмак хәлгә таруын Ибраһим берәүгә дә белгертмәячәк. Кичә кышкы бакча янында ниләр булганын, аның үзеннән кала, өч тугрылыклы нукеры гына белә иде. Алар үз хуҗалары хакында яман сүз сөйләгән теләсә кемне бәреп үтерергә әзер тора. Аның намусына тап төшерергә ниятләгән сакчы инде тәмуг төбендә, газапларга түзә алмыйча, бәргәләнә торгандыр. Хәзер бер Шаһназ гына калды. Үзенең гөнаһсызлыгын исбатларга азапланган Шаһназ иренең инде аны үлемгә хөкем иткәнен белми әле.

– Синең сүзләреңнең бер мәгънәсе дә калмады, – дип, камзул чабуына ябышкан хатынының кулын Ибраһим тагын бер кат этеп җибәрде. – Имам дөресен әйткән шул: барлык хатыннар – Иблистән яратылган. Чын-чынлап шәйтан кызлары кебек, сез барыгыз да – ялганчы һәм төрлечә боргаланучылар! Бүген синең язмышыңны казый хәл итәчәк, хак мөселманнар сөяркәң белән икегезне таш бәреп тончыктырыр!

Аяк астына ятып үксегән Шаһназга беравык битараф-гамьсез генә карап торды ул. Яшь хатын инде акланырга көч таба алмый, аның үксүе, үлем бизгәге тоткан кебек, тавышсыз тоташ тетрәнүгә күчеп бара иде. Әмма Ибраһимның күңелендә кызгану әсәре юк, инде Шаһназ аның өчен Казан тәхетенә илтүче юлдагы бер кирәксез түмгәк кенә, бу хәерсез түмгәкне тизрәк алып атарга кирәк.

– Синең бердәнбер юлың бар, Шаһназ, – дип әкрен генә дәвам итте солтан. Күзләре яшь белән шешенгән яшь хатынның, әле дә булса нәрсәгәдер өметләнеп, аңа башын күтәреп каравын күрде. – Менә шушы йөзек! – Ул бармагыннан зур зөбәрҗәт кашлы калын алтын йөзеген салды. – Мин аны сиңа калдырып китәм. Бу бер дә катлаулы эш түгел, асылташын борасың да эчендәге порошокны эчә торган сыеклыгыңа саласың. Мин сиңа бары тик тиз һәм җиңел үлем генә бүләк итә алам. Шулай итеп, кырлы ташлардан канга батып, газапланып үлүдән котыла аласың. Бичара Шаһназ, син әле шәригать хөкемен үтәүче мөселманнарның ни дәрәҗәдә рәхимсез икәнлеген белмисең!

– Ибраһим... – кайнар сулыштан ярылган иреннәре белән, ишетелер-ишетелмәс кенә ялварды хатын.

– Миңа бик кызганыч, Шаһназ, әмма сиңа бүтән котылу чарасы юк. Күңелеңне дога белән ныгыт та, мәңгелек хурлыкка тарымас өчен, шушы адымга бар.

Инде бусагага җиткәч, артына борылып:

– Мин йөзегемне алырга ике сәгатьтән киләм... Гомереңне ике сәгатькә озайту – бу бер дә аз түгел инде! – дип өстәде.

Нурсолтанның кашавы, тимер табаннары белән шыгырдап, якты кояш астында ялтыраган тыгыз кар өстеннән Ибраһим солтанның ишегалдына атылып кергәндә, Шаһназ калтыраган куллары белән ширбәтле касәгә ире калдырган йөзек эчендәге порошокны салып маташа иде. Нурсолтан, тунын да ычкындырып тормыйча, Кече Сарайның хатын-кыз ягындагы тар коридорыннан ашыгып кергәндә, күкрәгән кыскан авыр тойгының кинәт көчле авыртуга әйләнүен тойды. Мондый авыртуны ул гомерендә бары бер тапкыр, Миңлегәрәен мәңгелеккә югалтканын аңлагач кына кичергән иде. Шаһназның ишек төбен гади хәрәм агасы түгел, ә айбалталы озын сөңге (алебарда) тоткан нукер саклап тора иде. Алай да тәхет варисының хатынын тоткарларга батырчылык итмәде ул. Нурсолтан ишекләрне киереп ачты, эчкә атлады да бозлы кул белән йөрәгеннән кысып алган куркыныч хәлне күреп, тынсыз калды. Шаһназ, әҗәл белән көрәшеп, идәндә бәргәләнә иде. Туганының зур булып ачылган күзләре чиксез газап белән тулы; бичаракай нидер әйтергә талпынды, тик аның бугазыннан хәлсез хырылдау авазы гына чыкты. Нурсолтан кулларын бәйләп торган тунын салып атты, аның артыннан калфак белән баш япмасы да очты. Ул үлем якасында торган туганы алдына тезләнде:

– Шаһназ! Шаһназ, бәгърем, сиңа ни булды? Ялварып сорыйм, зинһар, аңлат!

Яшь хатынның иңнәренә ябышкан хәлдә, ул, акылын җуеп, кычкыра, иңри башлады. Куркудан шартларга җитешкән йөрәге газапланган туганына ярдәм итә алмау гаҗизлегеннән кан белән тулды. Ә Шаһназның ишеккә юнәлгән күзләрендә нәрсәдәндер, кемнәндер курку чагылды, Нурсолтан да, моны күреп, артына ирексездән борылып карады. Бусагада Ибраһим солтан басып тора иде. Нурсолтан, авыр төштән уяна алмаган кебек, Хәлилнең энесенә ташланды, аның өзгәләнүе Шаһназның хырылдавына кушылып китте:

– Табибны... Аллаһ хакы өчен тизрәк табибны чакырыгыз! Сез бит күрәсез, ул соңгы сулышын ала!

– Күрәм, – дип җавап бирде Ибраһим солтан, күзләре белән аны бораулап, – ләкин минем хатыныма табибның инде кирәге юк, ул үзе шул юлны сайлады. Бу – коткарып булмастай агу.

Нурсолтан коры, салкын тавыш белән әйтелгән әлеге сүзләр аның саташуы гына түгеллегенә һаман да ышанып җитмәде, әмма ирдән бер читкә тайпылды. Инде тынып калган Шаһназга таба борылган гына иде, чайкалып китеп, егыла язды. Шул мәлдә мамыктай җиңеләеп калган гәүдәсенең чит-ят ир кулына килеп төшкәнен тойды. Аны

Ибраһим тотып калган иде, хәлсез хатынның чибәр йөзеннән, ишелеп-чәчелеп төшкән толымнарыннан күзен ала алмыйча, иелеп, аны кәнәфигә утыртты. Түзә алмыйча пышылдады:

– Нинди чибәр син, Нурсолтан! Әтинең сараенда матурлыгың турында юкка гына тел шартлатып сөйләмиләр икән. Бу яктан да абый уңды. Тик нигә гел ул соң, ә мин түгел?

Ибраһим, тезләнеп, хатынның нечкә нәфис бармакларына кагылды. Әрсез һәм нәфесендә чик-чама белми торган ул булып ул да шуннан артыгына үрелергә базмады, тик солтан моңа гына канәгать түгел иде, әлбәттә! Аның борыны яшь хатынның башларны әйләндерерлек хуш исен тойды, күзләре, соклангыч гүзәллекне күреп, туя алмыйча ләззәтләнде. Ә ни үкенеч – шушы хатын аныкы түгел, ул аңа ия була алмады, була алмас та шул...

– Аһ, әгәр Шаһназ урынында син булсаң, мин теләсә нинди гөнаһыңны кичерер идем, яисә, барысын да булмаса – күпчелеген... Син бит – ирләр йөрәгенә хуҗа булырга яратылган зат, ә мескен Хәлилгә насыйп булдың. Ул, шундый матурлыктан аңымны җуймагаем, дип, синең белән ятып йокларга да куркадыр әле! Аллаһ аңа өеп-өеп мәхәббәт йөген биргән, ә аның исә кигән күлмәген дә күтәрерлек хәле юк.

Нурсолтан аның сүзләрен ишетер-ишетмәс, аңлар-аңламас утыра иде, әмма Ибраһимның шул рәвешле ирен мыскыллавы көтмәгәндә аңа көч бирде. Ачулы нәфрәт белән ул солтанны этеп җибәрде дә кабат Шаһназ янына төште. Хатынның газапланудан үзгәргән тәне инде суынган, Нурсолтан сәер бер тойгы белән туганының агарып калган йөзен кочагына алды.

– Калдырыгыз аны, Нурсолтан. Күрәсез бит инде, Газраил аның җанын алып китте. Мин хәзер кол хатыннарны җибәрермен, алар барысын да кирәгенчә башкарып чыгарлар.

Солтан аңа таба атлаган иде, тик салкын, тыныч нәфрәт белән тулы тавыш аны туктап калырга мәҗбүр итте:

– Күземнән югалыгыз, Ибраһим! Монда торуыгыз белән аның хатирәсен пычратмагыз. Ханыбыз нәкъ менә Хәлилне варисы итеп сайлап, нинди зирәк карар кабул иткән! Белмим, сездәй аждаһа хан тәхетенә утыра калса, бу халык ниләр күргән булыр иде икән!

Шушы сүзләре белән ничек төгәл һәм авыртырлык итеп сукканын Нурсолтан үзе, бәлки, аңлап-тоеп та җиткермәгәндер, бу мәлдә ул анык кына фикер йөртерлек хәлдә түгел иде. Хәзер ни генә кылса яки сөйләсә дә, барысы да төштә, иксез-чиксез куркыныч төшендә генә күргән кебек. Шул халәттән һаман әле котылып булмый, аның уянасы да килми иде.

***

Казанга яз, Нәүруз бәйрәме белән кулга-кул тотынышып дигәндәй, килеп керде. Шәрык калаларына хас тар урамнар ерып чыга алмаслык ләмгә-былчыракка батарга өлгерде. Койма буйларында кара кар көртләре сураеп тора, көн саен чүгә барган ул көртләр пычрак күлдәвекләргә әйләнә. Мәгәр бу күлдәвекләр бәйрәмчә киенгән төркем-төркем шат күңелле шәкертләрне туктата алмый. Алар, Нәүруз таякчыкларына язылган дүртьюллыкларны җырлап, көтүләре белән ашыга-ашыга ишегалларыннан узалар. Киндер биштәрләренә кунакчыл йорт хуҗалары төрледән-төрле тәм-том, нигъмәт тутыралар: анда йомырка да бар, кисәк-кисәк итеп каклаган каз һәм елкы итләре дә, балчык чүлмәкләргә тутырылган бал-май дисеңме, пешерелгән татлы ризыкларны...

Ибраһим солтан үз яныннан ашыгып үтеп барган шәкертләр өерен уйчан карашы белән озатып кала. Җете төстәге постаудан тегелгән җылы кәзәкиләр кигән, башларына кар төсле ап-ак чалма ураган Казан егетләренең күбесе аның яшендәрәк, тик солтанны гаҗәпкә калдырганы – аларның, тормыш мәшәкатьләрен бар дип тә белмәгән кебек, тыеп булмаслык шат-ачык күңелле булулары иде. Алар әйтерсең лә бүтән дөньяда – байлыкка, малга ирешеп, рәхәт тормышта яшәү өчен генә туган, көн вә төн хан тәхете турында гына хыялланучы солтанга тәтемәгән бәхет диңгезендә коеналар. Башка урында һәм бүтән вакытта ул бу кавем турында уйлап та тормас иде. Каткан көлчә белән судан кала ризык күрмәгән гади шәкертләрне Ибраһим солтан белән чагыштырып буламыни? Тик хәзер ул кинәт кенә аларның ваем белмәгән куанычыннан һәм теләсә кайсы көнне бәйрәмгә әверелдерә алу осталыгыннан көнләшеп куйды. Яшь солтанны өзми-куймый газаплаган авыр уйлар боларның башын авырттырмый, аның җилкәсенә күтәрә алмаслык йөк булып төшкән фани дөнья мәшәкатьләреннән дә азат алар. Аларга, карачы бәкләргә, казакларга, хәтта кара халыкка ничегрәк күренәм икән, дип, минут саен уйлап тору хаҗәт түгел. Ибраһим солтан исә бу турыда һәрвакыт исендә тотарга мәҗбүр. Үзен артык озак һәм нечкәләп «ясады» бит ул, шул арада юлындагы күпме киртәне алып ташлады. Урамдагы саз-былчыракны читекләре белән изеп баручы әлеге гамьсез-ваемсыз яшьләр бу турыда нәрсә белсеннәр! Аларга һәрдаим алны-артны карап хәрәкәт итәргә, төрле мәкерле ниятләр корып, шуларны тормышка ашырырга һәм бөтен дошманнарын рәхимсез рәвештә кырып барырга туры килмәгән.

Мондый уйлардан Ибраһимның кашы җыерыла, гүр иясе булган яшь хатыны кинәт исенә төшә. Аның турындагы фикерләр солтанны торган саен ешрак борчый башлады, мәгәр һич тә вөҗданы уянып киткәнгә яисә Шаһназны шундый адымга мәҗбүр итүе өчен үзен гаепле санаганга түгел. Юк, аның җанын бөтенләй башка нәрсә кимерә. Ул – Нурсолтан. Абыйсының хатыны исенә төшү белән, күз алдындагы дөнья, тылсымлы таяк болгап алгандай, шул мәлдә үк үзгәрә.

Атының тезгенен ара-тирә тарткалап, Ибраһим солтан инде үзенең Кече Сараена кайтып бара: пычрак күлдәвекләр дә, урамның ике ягыннан сузылган юеш моңсу коймалар да артта калды; аны болытсыз күк зәңгәрлеге генә озата килә, мондый үтә күренмәле зәңгәрлек бары тик яз көннәрендә генә булучан. Нурсолтанның да күзләре шундый ук зәңгәр бит. Аның йөрәген җилкеткән ул күзләрнең төсе үзгәреп торуы гаҗәеп: алар йә кыйммәтле ташларны хәтерләтүче зәңгәр якутка әверелеп куералар, йә кинәт язгы күк йөзедәй яктырып, фирәзәгә әйләнәләр. Телсезләр сыман артыннан ияргән нукерларын да, шатланып-көлешеп баручы бәйрәмчә киенгән кешеләрне дә оныткандай, Ибраһим ханзадә, гарәп чабышкысының тигез адымнарына йокымсырый төшеп, татлы хатирәләренә чумды.

Нурсолтанның көтмәгәндә килеп чыгуын белгәч, ул үзен сараеның хатын-кызлар ягына куалаган теге каһәрле кышкы иртә мизгелләрен кабат-кабат исенә төшерде. Хан варисының хатыны солтанның бөтен ниятләрен бутарга мөмкин, ә моңа юл куярга ярамый иде. Ул барыбер соңгарак калды, Нурсолтан кыз туганы ятагына аңардан алдарак кереп өлгергән булып чыкты, әмма бу инде Шаһназны коткара алмый иде. Ибраһим яшь хатынының авыр газап эчендә ничек бәргәләнгәнен дәшми-тынмый карап торды, әмма аңарда кызгану да, килеп чыккан хәлгә үкенү хисе дә юк иде. Башындагы бары тик бер уй гына тынгылык бирмәде: Шаһназ көтмәгәндә килеп чыккан туганы белән сөйләшеп өлгерә алганмы, сөйләшсә – ни әйткән. Ә бер мизгелдән Ибраһим бөтен борчуларын, сагаеп калуларын онытты. Бу – Нурсолтан аңа каршы торып баскач булды. Килеп туган хәл дә боза алмаган искиткеч чибәрлектән Ибраһим телсез калды. Аннары

хатын, аңын җуеп, аның кулларына авып төште. Солтан бөтен нечкәлекләренә хәтле хәтерли: кәнәфигә илтеп салганда, аның иреннәре никадәр якын булуын да, нәфис муенындагы зәңгәрсу тамырның ничек типкәнен дә. Аһ, кыюлыгы җитеп, аңа иреннәре белән сыена алган булсачы, яшь хатын тәнենеңнәфислеген тоеп, хуш исен сулап, аның күкрәгендә тыпырчынган нәни йөрәген тынычландырыр иде, бәлки...

Шул мизгелләрдә араларында нинди упкын ятканын онытты ул. Аның җене сөймәгән абыйсының «малы» икәнлеген дә, икесеннән берничә адымда гына Нурсолтанның яраткан туганы – Ибраһим үлемгә хөкем иткән хатынның әҗәл белән көрәшеп ятуын да... Әгәр, хакыйкать фаш булып, Шаһназ аны үзенең үлемендә гаепләп өлгерсә?!

Шул көнне үк ул Шаһназ ишеге төбендә саклап торган нукердан сорау алды. Тугрылыклы яугир, Шаһназның сыңар сүз әйтә алмаслык хәлдә булуын расласа да, бу әле Ибраһимны бөтенләй үк тынычландырмады. Аны Нурсолтанның, туганының үлеменнән башлап, тәхеткә юл ярып маташуына хәтле бөтен дөреслекне белгән кебек, йөзенә бәреп әйткән гаепләү сүзләре борчыды. Ул бит, Хәлилне аннан өскәрәк куеп та, бик мәрхәмәтсез фикерен яшермәде. Бу хатынның күзләре Ибраһимның Хәлилдән никадәр көчлерәк икәнен күрми торган булып чыкты. Әмма ул моны раслаячак әле! Нурсолтан шулчакта аның чын ир-ат икәнлеген күрергә тиеш, чөнки ихтыярсыз һәм чирләшкә Хәлилгә энекәшен куып җитәргә, ай-һай, ерак. Килер ул көн: аның күгенә дә кояш чыгар, Казан Иленең тәхетенә, Аллаһ боерса, ул утырыр һәм шулчакта Нурсолтан аның хатыны булыр. Язмышыннан уза алмас, шәт. Ханымның күзләрен ачып, дөреслекне күрсәтер Ибраһим, аңардан да шәбрәк ханның булмавына ышандырыр. Хәлилгәме соң аның белән тиңләшергә! Ә хәзергә бик сак булу тиешле, Нурсолтанның нинди нигезгә таянып, авыр гаепләр ташлавын һәм хәзер аңа нинди мөнәсәбәттә булуын ачыклыйсы бар.

Хан варисының хәләле, кайгырып, елап, берничә ай буе сарайның хатын-кызлар ягыннан чыкмады. Әмма бүген, солтанга җиткергәннәренчә, Нәүрузга багышланган мәҗлестә аның да катнашуын шарт итеп куйганнар. Димәк, бу бәйрәмдә Нурсолтан белән күрешү һәм күңелдә әлегәчә көйрәп торган соңгы шикләрне яндырып бетерү мөмкинлеге туачак. Шуңа күрә ул, кала читендәге Казан казакларының төп көчләре яшәп торган авылны калдырып, бәйрәмгә ашыкты.

Ибраһим солтан, гади сугышчылар арасында үзенә ихтирам яуларга тырышып, инде ничә ай алар белән бергә яшәде. Ул аннан тәмам тынычланып, казаклар аның кул астында теләсә нинди орышларга барачак, дигән ныклы ышаныч белән кайтты. Казан тәхетенә таба юлындагы тагын бер мөһим адым иде бу.

Кичке мәҗлескә Ибраһим солтан ялгызы гына килде. Аның хатыны Фатыймасолтан инде ханшада кунакта иде. Ханның өлкән хатыны Сәрби ханша Фатыймасолтанны, Нурсолтанның ачуын китерү өчен, юри алдан ук дәшеп алды. Киленен бигүк яратып бетермәү генә түгел, кайчакта, улының һәм иренең игътибарын үзенә генә җәлеп итә, дип, аңардан ачыктан-ачык көнләшә иде ул. Менә хәзер дә Мәҗлес залында Ибраһимны үз яныннан җибәрми, ә Нурсолтанны бөтенләй күрмәмешкә салыша. Бәйрәмдә катнашучы ханымнар моны шунда ук сизеп алдылар. Калфак очларын бер-берсенә тидерә язып, гайбәт капчыклары, бик җанланып, төрле вак-төякләренә хәтле чәйнәп, үзара шыбырдаша башлады.

Нурсолтан бусагада ук, кемгә дә якынрак килергә базмыйча, икеләнеп туктап калды. Ул Сәрби ханша җитәкләгән байбикәләрнең үзеннән читләшкән салкын карашын шунда ук сизгән иде инде. Арадагы иң өлкән ханым – тәхет варисының анасы – Фатыймасолтанның колагына нәрсәдер пышылдап алды, тегесе, ханшаның мактавыннан бик канәгать калып булса кирәк, кызарынды-бүртенде. Сарай идарәчесе

Аккүбәкнең көчле тавыш белән игълан итүенә карамастан, хатыннарның икесе дә Нурсолтан ягына борылып карамады. Гомердә булмаганча, Нурсолтан үзенең ялгызлыгын тойды, бу минутларда аның хәлен аңларлык бердәнбер кеше – Хәлил янына барып сыенасы килде. Ләкин солтан карачы бәк белән бик мавыгып сөйләшә иде, шуңа күрә аларның сүзен бүлдерергә яхшысынмады. Аның китүе качу булып аңлашылмасын өчен, аркасын турайтып һәм ашыкмаска тырышып, ул Мәҗлес залыннан бакчага таба киереп ачылган ишеккә юнәлде. Саф җил күзеннән бәреп чыккан яшьләрне киптерде һәм ул, үзенең көчсезлеген берәү дә күрмәгәне өчен, Аллаһка мең рәхмәтләр укыды. Сәрби ханшаның, күзләреннән усал очкыннар чәчеп, күпме үт сытып, агу салып киленен озатып калган сүзләрен ул ишетмәде:

– Бу нугай өстерәлчегә үзе турында артык югары фикердә бугай. Ул ирләр белән үзе теләгәнчә бөтерелеп була дип саный. Минем улымның башын тәмам әйләндерде, хәзер тегесе, бу бикә белән киңәшмичә, бер адым да ясый алмый. Фатыймасолтан кадерлем, күз алдына китерә аласызмы, хәтта безнең хакимебез Мәхмүд хан да аның белән генә киңәшә! Йа Аллаһ, бердәнбер өстенлеге күрекле чырае булган ул кызчыктан ничек киңәш сорамак кирәк?!

– Ай, мөхтәрәмә ханым, мин Сезне бик яхшы аңлыйм, – дип, юка ашъяулык почмагын бөгә-бөгә пышылдады Фатыймасолтан. – Күрәсең, киленегез, мәрхүмә туганы Шаһназ кебек үк, оятсыз-битсездер. Анысы бит ирләр яныннан тыныч кына узып та китә алмый иде. Сез аның ни өчен бакчада берүзе йөрергә яратканын белсәгез икән.

– Йа Аллаһ, мөмкин эшмени бу?

Симез гәүдәле Сәрби ханшаның кызыксынудан мае кайнады, аны тирә-юнендә күпме чит колаклар тыңлап торуы гына тыеп калды.

– Әйдәгез, фонтан тирәсеннән урап узыйк әле, Сезгә билгеле булган нәрсәләрнең барысын да беләсем килә.

– Мин ул хәтле күпне белмим, – дип, түземсезләнеп пышылдады Фатыйма. – Хезмәтче хатыннарның берсе Шаһназның сакчылар белән ничек уйнаш итүен генә күреп калган. Шөкер, Аллаһ ул затсызга, шуннан артыграгын кыланырга рөхсәт итмичә, тиешле җәзасын биреп, иремне мыскыл итүгә юл куймаган әле!

– Сез мине сагыш вә кайгы чоңгылына төшердегез, Фатыймасолтан, Тимер морзабәкнең кызлары шундый гөнаһлы гамәлләргә барырга сәләтле, дип, кем уйлаган?! Хәзер инде мин улыма нинди хатын насыйп булуын аңладым. Юкка гына беренче көненнән үк җаным тартмаган икән! Шаһназ солтанбикәгә килгәндә, ашказаны чире теге дөньяга вакытында алып китеп өлгергән әле, югыйсә, бер киленнәре зиначы дип кенә фаш итсәләр дә, хан гаиләсенә нинди оят корымы ягылыр иде!

Ханшаның йөрәген, аның үз фикеренчә, гадел ачу уты көйдерде, ә Фатыймасолтан ул утка бары тик май гына өстәде.

– Алар икесе дә зинадан туган кызлар ич. Алма агачыннан ерак төшми. Киленегезгә карата кырысрак булыгыз.

– Ай! Иртәгә үк улым белән сөйләшәм, ә үзем аңардан күземне алмый күзәтәчәкмен! Менә әйтегез миңа, Фатыймасолтан җаным, бөтен итагатьле ханымнар залда чагында, ул кайда булырга мөмкин? Мин аның, ояты качкан туганы кебек үк, ялгызы гына бакчага чыгып киткәнен абайлап калдым! Ә бәлки, ул анда берәр ят ир белән очрашадыр? Йа Аллаһ, башыбызга бәла-каза сала күрмә!

Сәрби ханша үзенең дөреслектән бик ерак булмаганлыгын күз алдына да китерә алмады. Нурсолтан бу минутларда бакча буйлап берьялгызы йөри, ә аңа каршы инде кибә башлаган сукмаклардан Ибраһим солтан атлый иде. ■

ТАТАР АВЫЛЫ:
үткәне һәм бүгенгесе

*ТР ФАнең Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институтында Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә үткәрелгән **«Урта Идел буеның татарлар тупланып яшәгән төбәкләрендә татар авылы: үткәне һәм бүгенгесе»** дип исемләнгән «түгәрәк өстәл»дә яңгыраган чыгышларны сезнең игътибарга тәкъдим иткән идек[1]. Республикабызда төбәкчелек юнәлешендә эшләүче төп институтның авылларны өйрәнү юнәлешендәге план-максатлары нидән гыйбарәт? Бу сорауга җавап итеп, әлеге «түгәрәк өстәл»не оештыруда башлап йөргән галимнәрнең чыгышы белән таныштырабыз.*

БУЛАТ ХӘМИДУЛЛИН: «Эшнең күләме гаять зур!»

2015-2016 елларда «Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации» исемле фәнни белешмә Татарстан Республикасының «Татар халкының милли үзенчәлекләрен саклау» дигән дәүләт программасы кысаларында төзелде. Җыентыкны төзегән вакытта татарлар яши торган торак пунктларның тарихы, мәдәнияте һәм икътисады турында мәгълүмат җитәрлек булмау зур комачаулык тудырды. 2017 елның башына Россия Федерациясендә 4 меңнән артык татарлар һәм татар белән бергә башка милләт вәкилләре дә яши торган авыл барлыгы хисапланды. Шуларның 2 меңе Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан. Хәзерге көндә бу торак пунктларда яшәүче халыкның гомуми хәле, көнкүреше комплекслы өйрәнелмәгән, максатчан рәвештә тарих һәм мәдәният, авылның үсеш үзенчәлекләре тирәнтен тикшерелмәгән. Мин бу очракта теге яки бу авылның тарихы турында тәфсилләп язылган аерым китапларны мисалга китереп тормыйм.

Хәзерге көндә эшнең күләме гаять зур! Авыллар тарихын комплекслы фәнни өйрәнгәндә нинди проблемалар барлыгын ачыклар өчен, без иң әүвәл Урта Идел буе авыллары тарихын тикшерү эшенә алындык. Бу төбәккә, Татарстаннан кала, Пенза, Самара һәм Ульяновск өлкәләре керә. Әлеге фәнни-тикшерү проектын өч ел эчендә тәмамларбыз, дип өметләнгән идек. Әмма, кызганыч ки, дәүләт программасында моны эшләү өчен нибары бер ел вакыт бирелде һәм берьеллык кына финанс тәгаенләнде. Шуңа да карамастан, без фәнни белешмә төзү эшеннән баш тартмадык, аны билгеләнгән срокка башкарып чыгарбыз, дип өметләнәм.

«Татарская деревня в местах компактного проживания татар в Среднем Поволжье: история и современность» дигән фәнни белешмәне басмага әзерләү барышында, ягъни 2017 елның ун аенда басманың фәнни концепциясе эшләнде һәм муниципаль районнарга, Пенза, Самара һәм Ульяновск өлкәләре архивларына йөздән артык сорау-мөрәҗәгать җибәрелде.

Хәзерге көнгә белешмә өчен материаллар әзер диярлек. Ул үз эченә Пенза, Самара һәм Ульяновск өлкәсендәге татарлар нигез салган һәм халкының 20 проценттан артыгын милләттәшләребез тәшкил иткән авылларны колачлый. Мәкаләләрдә торак пунктның тарихы өйрәнелде, статистик мәгълүмат тәкъдим ителде һәм хәзерге хәле

[1] Татар авылы: үткәне һәм бүгенгесе // Безнең мирас. – 2017. – №2. – Б.3-7.



турында да язылды. «Регионы...» китабындагы кебек үк, мәкаләләрнең күләме һәм эчтәлеге төрле. Моның сәбәбе исә теге яки бу авылның тарихы начар өйрәнелгәнлегенә яки аларга бәйле чыганаклар булмауга һәм 2-3 көнлек экспедицияләр оештыруга, архив хезмәте өчен түләүгә финансның чикләнгәнлегенә бәйле.

Шуны да искәртергә кирәк: без алда телгә алган өлкәләрдә татар иҗтимагый оешмалары гаять актив эшли. Алар тарафыннан авыллар тарихын өйрәнү, татар халкын, аның милли гореф-гадәтләрен пропагандалау буенча зур эш башкарыла. Мәсәлән, «Татары Симбирского-Ульяновского края» исемле энциклопедик белешмәне төзү безнең институт хезмәткәрләренең методик ярдәме белән башкарылды. «Татарская энциклопедия Пензенской области» дигән саллы басмада 284 татар авылы, 312 татар морзасының нәселе, моннан тыш, урыслашкан, кайчандыр бабалары татар булган дворян-кенәзләр турында да мәгълүмат, мишәр татарларының гореф-гадәтләре, традицион мәдәниятенә нисбәтле мәкаләләр тупланган. «Татары Самарского края: историко-этнографические и социально-экономические очерки» – самара татарларының археологиясен, этнографиясен, дини вазгыятен, милләттәшләребезнең төбәк икътисадындагы ролен, авыллар тарихын һәм шәһәрләрдәге татарларның көнкүрешен тасвир кылган энциклопедик басма. Китапта Самараның, нигез салынган дип саналган рәсми дата – 1586 елга кадәр үк, татар шәһәре булганлыгы бәян кылынган, бу факт тарихи дәлилләр белән исбатланган. Әлбәттә, алда әйтелгән хезмәтләр безнең эшебезне күпкә җиңеләйтте. Әлеге китапларның авторларына, аны чыгаруда ярдәм күрсәткән кешеләргә институт хезмәткәрләре исеменнән рәхмәтемне һәм чиксез ихтирамымны белдерәм!

ЛАРИСА ГАЙНЕТДИНОВА:
«Авыл халкының тарихи-мәдәни мирасы гаять бай»

Безнең институтта 2015 елдан бирле өч томлы «Татарстан Республикасының торак пунктлары» энциклопедиясен төзү эше бара. Әлеге вакыт аралыгында шактый зур эш башкарылды. Әмма авыллар энциклопедиясен язу ике елда гына эшләнә, дип

һич кенә дә уйларга ярамый, чөнки төбәкне өйрәнү институтта 20 ел дәвамында максатчан рәвештә оештырыла. Шуны да әйтергә кирәк: бу эшне кыска вакыт аралыгында гына башкарып чыгу мөмкин дә түгел. Энциклопедиягә керәчәк мәкаләләр саны – 3 меңнән артык (2015 елда Татарстанда 3077 торак пункт хисапланган). Һәр том бер мең чамасы авыл, шәһәр һәм бистә турындагы мәгълүматны колачлый.

Хәзерге вакытта без басманың концепциясен эшләдек, укучыга эзләү җиңел булсын өчен, районнарга бүлү рәвешендә авылларның исемлеген алфавит тәртибендә тездек. Концепция буенча энциклопедиянең беренче томы – 14 район, 1056 авыл, 7 шәһәр һәм 7 шәһәр тибындагы поселокның тарихы һәм хәзерге хәле турында. Без торак пунктларны халыкның милли составы буенча аеруны максат итеп куймадык. Китапка Татарстан Республикасының барлык торак пунктлары да керәчәк, әмма шул ук вакытта һәр авыл яки шәһәрдә яшәүче халыкның милли составы күрсәтеләчәк. Милли составка килгәндә, шуны әйтә алам: беренче томда 600ләп татар авылы турында язылачак. Аны гади белешмә рәвешендә генә түгел, ә иллюстратив (30-40 проценты визуаль материалдан гыйбарәт) энциклопедия рәвешендә эшләү мөмкинлеге булу гаять уңай күренеш, дип әйтер идем. Бу хәзерге вакытта материалны, тексттан бигрәк, визуаль формада кабул итәргә күнеккән яшь буын өчен кирәк булыр, дип уйлыйм.

Энциклопедия белешмә рәвешендә төзеләчәк, шунлыктан, анда теге яки бу төбәк тарихындагы барлык мәсьәләләргә дә ачыклык кертелми. Барыннан да бигрәк, без төбәкне өйрәнүчеләргә, галимнәргә киләчәктә фәнни-тикшерү эшләрен алып бару өчен нигез бирәбез, ягъни җәмәгатьчелеккә билгеле бер авыл тарихының өйрәнелү дәрәҗәсен күрсәтәбез.

Әлбәттә, авыллар турындагы бу китапны төзегәндә алты томлы «Татар энциклопедиясе»нә язылган материаллар нигез итеп алынды. Бер үк вакытта соңгы ике елда гаять җитди фәнни-эзләнү эше башкардык: районнарга чыктык, архив һәм китапханәләрдә эшләдек, сораштырулар үткәргән вакытта барлык авыл җирлекләренең рәисләре белән дә танышып чыктык, төбәкне өйрәнүче җирле белгечләр белән очраштык, алар язган китап һәм мәкаләләрне укыдык. Әмма бер кыенлык бар: авыл һәм районнарда булган әдәбият Казан китапханәләрендә юк диярлек. Без бу китапларның, акча җитмәү сәбәпле, бик кечкенә генә тиражда, 50-100 данә генә басылып чыгуын яхшы беләбез, шуңа да инде алар галимнәргә, институт һәм киң җәмәгатьчелеккә барып ирешми. Беренче мәртәбә, дип әйтергә кирәк, без үз басмабызда археология материалларыннан файдаландык. Язма чыганаклар буенча, авылларга нигез салынган дата XVI-XVIII гасыр белән чикләнә, шуннан да тирән төшү мөмкин түгел иде. Археология материалларын өйрәнеп, без элек тарихы XVI, XVII һәм XVIII йөздән башлана, дип саналган кайбер торак пунктларның нигезендә Алтын Урда, Болгар, ә хәтта аннан да борынгырак дәвердә нигездә салынган авыл яки шәһәр булганлыгын ачыкладык. Болар безнең тарихыбызны тагын да баета, аңа кызыклы фактлар өсти.

Районнарда йөреп, без шуны аңладык: авыл халкының тарихи-мәдәни мирасы, рухи дөньясы гаять бай һәм алар шәһәр кешесенә билгесез. Әлеге мирасны таныту максатыннан, 2015 елда авыл мәгариф туризмын үстерү турындагы фикеребезне әйткән идек, әмма ул яклау тапмады. Авыл туризмын нәкъ менә татарлар күпләп яши торган милли җирлекләребездә, аерым алганда, Арча һәм Әтнә районнарында оештырырга кирәк. Бу ферма-мегафермаларны күрсәтү формасында түгел, ә авылның, аның халкының үзенә, Шиһабетдин Мәрҗани, Габдулла Тукайлар туган яки яшәгән урыннарга экскурсия рәвешендә оештырылырга тиеш. Шөкер, читтән килгән туристларга күрсәтерлек татар авыллары Татарстанның һәм Россиянең башка төбәкләрендә дә бар. ■

Безнең мирас №3 март 2018

«Бүз егет» белән «Таһир-Зөһрә»не язучы кем булган?

Гали Рәхим

Безнең әдәбият тарихыбызның тикшерелмәгәнлеге, аның төрле почмакларының караңгылыгы искитәрлек дәрәҗәдә. Әйтик, заманыбызда 50 еллар гына элек яшәгән язучыларыбыз турында кулыбызда мәгълүмат шулкадәр сай була, әйтерсең алар моннан 500 ел элек яшәгәннәр. Чынлап та без үз-үзебезне, үз мәдәниятебезне, тарихыбызны белмибез, өйрәтергә тырышмавыбыз коточкыч дәрәҗәдә бара.

Мин ышанам, әгәр дә безнең әдәбият тарихчыларыбыз хәзерге көннән үк башлап зур көч сарыф итеп, ашыгып, чараларын күреп, яңару дәвере әдәбиятыбызның эшчеләре турында биография материаллары җыйнарга керешмәсәләр, тиз көннән алары да байтагының коры әсәрләрен генә тотып калачаклар. Киләчәктәге әдәбият тарихчыларына аларның кем, нинди кеше булуы турында табышмаклар табарга, археология казылмалары ясарга туры киләчәк. Берничә ун елдан соң киләчәк тикшерүчеләр моның өчен безгә ләгънәт укыячаклар.

Мисаллар артыннан ерак йөгерәсе юк. Күбебезнең әле яшь вакытта гасырдашы булган **Каюм Насыйри**ның тәрҗемәи хәлен безгә 1922 елда гына ярты-йорты материал, күп ялгышлар белән юктан бар итәргә туры килде.


قصۀ بوز يكت

بوكتاب باصمه‌سنه رخصت بيرلدى ٢٠ نچى آغوست
١٨٧٧ نچى يلده

بوكتاب قزان اونيويرستيتى‌ننك طبع خانه‌سنده باصمه
اولنمشدر قزان اويازى توبان قورصا آولى‌ننك
شمس الدين حسين اوعلى خراجتى ايلان ١٨٧٨ نچى
يلده اوچونچى مرتبه

Кыйссаи бүз егет китабы / Казан өязе Түбән Курса авылының Шәмсетдин Хөсәен углы хираҗәте илә. – Казан: университетның табгыханәсе, 1878 ел

Кандалый турында шулай ук һич мәгълүмат юк иде. Шөкер булсын, үткән ел берәү, бу турыда бик кызыклы материаллар җыеп, «Безнең юл»да бастырып чыгарды. Юкса без үзебезнең «Феодализм дәвере татар әдәбияты тарихы»н язганда, Кандалыйның тәрҗемәи хәле турында «Фәвакиһел-җөләса»дагы: «Мәрхүм Габделҗаббар шагыйрь адәм имеш. 1850дә вафаттыр», – дигән ярты юл мәгълүмат белән канәгатьләнергә мәҗбүр булган идек. Борынгы дәвернең башка әдипләре турында хәл шуннан күп алда түгел иде.

Алыйк, мәсәлән, әлеге дә без крестьян массасының иң яратып укыган әдәби әсәрләреннән мәшһүр «Бүз егет» һәм «Таһир-Зөһрә» кыйссаларын язган **Әхмәд Уразаев**ны. Без «Әдәбият тарихы»н язган вакытларда әле бу кешенең тәрҗемәи хәле караңгы, караңгы гына түгел, бөтенләй юк иде.

Әхмәд Уразаевның кемлеге турында безнең мәгълүматыбыз «Таһир илә Зөһрә» китабының ахырындагы шушы берничә юлдан гыйбарәт иде: «Тасниф кыйлдым *(яз-*

дым) фәкыйрь мелла Әхмәд мелла Мөхәммәдзариф углы Уразаев әл-Кызылҗари әл-Кормаши. Сәнәи 1879, карьяи Күшәрдә...»

«Әдәбият тарихы»ның беренче басмасы (1922) белән икенче басмасы (1925) арасында мин шул яктагы кайбер танышларыма хатлар язып, Күшәр авылында Әхмәд Уразаев дигән мулланың булу-булмавы турында сораштырып карасам да, моннан бер нәтиҗә дә чыкмаган иде. Икенче басманың 262 нче битендә мин түбәндәге сүзләрне яздым: «Димәк, аларны язган кеше Әхмәд Уразаев исемле бер татар мулласы, ул Кормаш авылында туып, Күшәр авылында имам булган булырга кирәк». Аннан соң түбәндә, сызык астында: «Ләкин бу Күшәр кайдагы авылдыр, мәгълүм түгел. Арча кантонындагы Күшәрдә Әхмәд Уразаев исемле мулланы белүче табылмады», – дим.

Үткән җәйне миңа Арча кантонында, Мәңгәр авылында үткәрергә туры килде. Күшәр Мәңгәрдән алты гына чакрым ераклыкта. Шушы хәлдән файдаланып, мин Күшәргә махсус барып, «Бүз егет»ләрнең мөхәррире турында тикшерендем. Тикшеренүем нәтиҗәле булып чыкты. Моның нәтиҗәсендә мин Әхмәд Уразаевның эзенә бастым. Күшәрнең карт мулласы Габдрахман хәзрәт Яушев Әхмәд Уразаевны яшь вакытында күреп белгән кеше булып чыкты. Тик аннан алган мәгълүматны бераз төгәллисе генә бар иде. Көз көне Казанга кайткач, Уразаев турында мәгълүмат алу өчен тагын бер кеше табылды: аның ерак кардәшләреннән бер егет Казан югары мәктәпләренең берсендә укый икән. Көнчыгыш педагогический институттагы шәкертләрдән берсенең ярдәме белән Минзәлә кантоны Чирү *(Чуриево)* авылының мәзине Әхмәдлатыйф Уразаевка хат яздырып, Әхмәд Уразаев турында табыла алган кадәр мәгълүматны кулга төшердем. Шуның аркасында Әхмәд Уразаевның кем булганы, нәселе, нәсәбе һәм, тулы булмаса да, тәрҗемәи хәле ачылды.

Әхмәд Уразаевның бабасы Мөхәммәдсадыйк Уразаев Минзәлә кантоны Иске Кормаш авылында мулла булган[1]. Аның улы Мөхәммәдзариф казакъ арасына, Звериноголовски[2] шәһәренә барып мулла булган һәм шунда урнашып калган, улы Әхмәд шунда дөньяга килгән. Анасы, Габдрахман хәзрәтнең әйтүенчә, казакъ кызы яки казакъ нәселеннән булырга кирәк, чөнки Әхмәднең йөзендә казакъ симасы аермачык беленә икән.

Зариф мулла улы Әхмәдне Кызылҗар (Петропавел) шәһәрендәге Габделбари ахун мәдрәсәсенә укырга җибәргән. Әхмәд Уразаевның үзен «Кызылҗари» дип атавы менә шуннан. **Габделбари ахун Яушев**[3] төп Казан ягы Күшәр авылыныкы булып, Күшәрнең **Габбас хәзрәт**нең[4] улы икән. Ул Бохарага барып укып кайтканнан соң, Кызылҗарга мулла булган, ләкин Кызылҗарда зур мәдрәсә булмаган. Шуңа күрә Габделбари ахун үзенең улы Габделваһабны[5] Кышкарга укырга җибәргән, аңар иптәш итеп Әхмәд Уразаевны ияртеп җибәреп, үз хисабыннан аны да Кышкарда укыткан.

Бу вакыт Кышкарда мәшһүр мулла **Исмәгыйль Үтәмешев**нең[6] дәрес әйткән заманы икән. Ике иптәше, 1874-1875 нче еллар тирәсендә Кышкарга килеп, 6-7 еллар чамасы укыганнар. Юл ерак, җәй көннәрендә, каникул вакытларында алар Кызылҗарга кайтмый, бары тик якындагы Күшәр авылына кайтып, **Габделваһаб мәхзүм**нең ата-

[1] Бу мәгълүматны бирүче – Чирү мәзине Латыйф Уразаевның бабасы Әхмәдшаһ мулла безнең әдипнең бабасы Мөхәммәдсадыйк белән бертуган икән *(авт. иск.)*.
[2] Звериноголовски – хәзер Курган өлкәсенең Звериноголовск районы үзәге. Биредә атаклы татар драматургы һәм язучысы Абдулла Әхмәт (1905-1976) тә туган.
[3] Габделбари бине Габбас әл-Күшәри (1814-1894) – Бохарада белем ала, 1852 елдан Петропавловск шәһәренең икенче мәчете имамы.
[4] Габбас бине Габдерәшид әл-Күшәри (1763-1853) – Күшәр авылы имамы. Каргалыда белем алган.
[5] Габделваһаб бине Габделбари әл-Күшәри (1859-1924) – Спас өязендәге – Тигәнәле, Казан өязендәге Кышкар мәдрәсәләрендә, аннары Бохарада белем ала. 1888 елдан – Петропавловскта әтисе урынына имам.
[6] Исмәгыйль Муса улы Үтәмешев (1887 елда вафат) – 1844 елда Бохарадан белем эстәп кайта. Кышкар авылында имам-хатыйп һәм мөдәррис.

сы белән бер туганнан туганы **Галибшаһ хәзрәт Яушев**та кунак булып яталар икән. Кышкарга килгән вакытта Әхмәд 16-17 яшьләр чамасындагы бер егет икән.

Күшәрнең Габдрахман мулла аны яхшы хәтерли, ләкин ул вакытта әле яшьрәк булганга (хәзер аңа 60 яшьләр тирәсе) Әхмәд Уразаев белән мөнәсбәттә була алмаган. Әмма аның әйтүенчә, Күшәрдә соңгы елга кадәр исән булган бер сукыр карт Әхмәднең мәдрәсәдә иптәшләреннән һәм иң якын дусларыннан булып, яшь вакытта көне-төне аның белән бергә булган икән. Габдрахман мулла әйтә: «Әхмәдне шуннан да яхшырак белгән кеше булмас инде. Ул аның бөтен тормышын, холкын, табигатен әнәсеннән-җебенә чаклы беләдер иде», – ди. Ләкин, үкенечкә каршы, бу кеше мин Күшәргә барырдан бер генә ай элек үлеп куйган. Күрәмсез, һәр соңга калынган ай әдәбият тарихыбызны өйрәнүне еракләштыра икән. Тарихыбызның җанлы шаһидлары көн саен берәм-берәм теге дөньяга сәфәр кыла торалар...


قصهء طاهر

كتاب باصمه سنه رخصت بيرلدى ١٢ نچى اوكتابر ١٨٧٨ نچى يلده

كتاب قزان اونيويرسيتيتى ننك طبع خانه سنده باصمه اولنمشدر
بان قورصا آولينينك شمس الدين حسين اوغلى ننك خراجتى
ايلان ايكنچى مرتبه ١٨٧٨ نچى يلده ***

Кыйссаи Таһир / Казан өязе Түбән Курса авылының Шәмсетдин Хөсәен углы хираҗәте илә. – Казан: университетның табгыханәсе, 1878 ел

Габдрахман мулланың сөйләвенчә, Әхмәд Уразаев кечкенә генә буйлы, ябык кына, ак чырайлы, сакал-мыексыз бер егет булган. Үзе бераз гына казакъ чырайлы, шешмәрәк кабаклы икән. Шәкерт арасында аны «Казакъ Әхмәд» дип йөргәннәр. Һәртөрле кыйсса китаплары укырга һәм язарга бик һәвәсле иде, ди. Нинди китаплар язганын белми. Әгәр без «Бүз егет»нең 1876 нчы елда басылуын, «Таһир-Зөһрә»нең 1879 нчыда язылуын хәтергә алсак, аның бу әсәрләрен Кышкарда укыган дәвердә язганлыгын һәм басарга җибәргәнлеген күрәбез. «Таһир-Зөһрә» китабының ахырындагы сүзләрдән дә без аның Күшәр авылында язылганын беләбез. Димәк, ул аны каникул вакытында, Күшәргә Галиб муллалар йортына кайтып, ял итеп яткан вакытларда язган. Латыйф Уразаев та үзенең хатында: «Китап чыгарды, диләр. «Таһир-Зөһрә» китабын яшь вакытымда алып укыганым бар. Безнең нәселдән Әхмәд мулла Уразаев дигән кеше язганы ачык хәтердә», – дип яза. Һәрхәлдә, бу китапларны язганда әле ул мулла булмаган, шәкерт кенә булган. Үзен «Мулла Әхмәд» дип атавы зуррак күренү өчен булырга кирәк.

Уку ягына килгәндә, ул тырыш, фәһемле шәкерт булган. «Сөлләм», «Тәзһиб»ләр укыган. 6-7 ел Кышкарда укыганнан соң, ул үз иленә кайтып киткән. Төп авылы Кормашка кайтканы булмаган. Кайтып китүе 1879-1880 нче еллар тирәсендә булырга кирәк. Кызылҗарга кайткач, Әхмәд Уразаев берничә ел казакъ арасына чыгып муллалык кылып йөргән. Указ алганлыгы мәгълүм түгел. Өйләнгәнен-өйләнмәгәнен дә белмибез. Тик ул озак яшәмәгән. Яшьләтә үлгән. Үлүе, Габдрахман мулланың әйтүенә күрә, 25-30 яшьләр арасында булырга тиеш.

Шул ук Габдрахман мулланың сөйләвенчә, басма «Бүз егет» китабы чыкканга кадәр халык арасында кульязма «Бүз егет» китаплары укылып йөргән. Ихтимал, Уразаев шулардан алып-алып язган. ■

Әхмәд Уразаев-Кормаши турындагы мәкаләгә өстәмә итеп, Гали Рәхим хәзерге Әтнә районының Күшәр авылы турында да саллы мәгълүмат биргән. Авыл тарихын, Яушевларны өйрәнүчеләргә бәлки файдалы чыганак булыр, дип, аны да сезнең игътибарга тәкъдим итәбез.

Күшәр морзалары

Гали Рәхим

Күшәр авылы – Арча кантонында, Әтнә волостенда 1500 чамасы халыклы бер мәхәлләле авыл. Күшәр тирә-якта бай авыллардан санала. Революциягә чаклы анда читкә китеп сату белән шөгыльләнүчеләр күп булган. Хәзер Күшәрнең байлыгы – җиренең күплегендә һәм яхшылыгында. Күшәр авылы, татардагы сыйныфлар тарихы күз карашыннан, бик кызыклы авыл. Бу авылның халкы һаман да феодализм дәверендәге сыйнфый бүленү һәм аерымлыкларның калдыгын саклап килә. Күшәрдәге халык дүрт груһка *(төркемгә)* бүленә: 1) кенәзләр – болар берничә генә йорт; 2) морзалар – йөздән артык йорт; 3) коллар – уннан артык йорт; 4) калганнары яшьләр – болары соңыннан читтән килгән кешеләр (Әйшә авылыннан). Менә бу группалар хәзерге көндә һәммәсе гади крестьяннар. Ләкин, бер авылда торсалар да, аларның басулары аерым-аерым булып, аерым мизан *(үлчәү)* белән бүленгән. Һәрбер группа үзләренең нинди нәселдән килгәнен аермачык белә. «Без – кенәзләр», «Без – морзалар», дип яки «Без коллар нәселеннән киләбез», дип сөйлиләр. Мондагы морзалар һәммәсе бер нәселдән киләләр, һәммәсенең фамилияләре Яушев. Болар электән алай күп булмаганнардыр, соңыннан үрчи-ишәйгәннәр булырга кирәк. Җирләре дә шуңар күрә вакланып бетеп, тора-бара алар гади крестьянга әйләнеп киткәннәр. Хәзердә дә әле аларның җирләре башкаларга караганда җан башына артыграк тия. Гомумән, күшәрләрнең җирләре шәп булуының сәбәбе дә анда электә морза һәм кенәз җирләре булуында. Колларга килсәк, аларның саннарының азлыгы күзгә бәрелә. Ихтимал, бу коллар гади крепостной крестьяннар булмыйча, шундагы кенәз һәм морзаларның дворовыйлары гына булганнардыр. Иң элек Мәрҗанинең «Мөстәфадел әхбар...»ында (I кыйсем, 24 бит) дәреҗ ителеп *(басылып)*, шуннан алынып, соңгы заман татар тарихи әдәбиятында, татардагы колбиләүчелеккә мисал йөзеннән кат-кат китерелгән мәшһүр бер документтагы кол сату мәсьәләсенең дә Күшәр белән бәйләнгәнлеген искә төшереп узабыз.

Бу документ буенча Казанның бер йомышлы татары үзенә мирас булыпмы, ничектер, тигән колларын һәм җирләрен Казанның бер сәүдәгәренә сата. Документта шушылай әйтелә: *«Тарих мең дә йите йөздә сиксәндә сигезенче елда гыйнварның сигезенче көнендә Казанның Иске Бистәнең йомышлы кешесе мин,* ***Йосыф Динмөхәммәд углы****, сатып үземнең хиссама (өлешемә) тигән колларымны Казанның Иске Бистәсенең* ***Исмәгыйль Апанай Хафиз углы****на*[7] *йөз сум хак берлә саттым. Ошбу колларым Алат юлында Арча округында Күшәр авылында йорт берлә торгучылар... вә дәхи шул Күшәр авылында били торган җирләрем һәм печәнлегем барчасы Исмәгыйль агайгадыр».*

Менә бу документтан без XVIII йөздә феодализм корылышының какшавы аркасында татар феодаллары җирләренең яңа баш күтәреп килә торган татар сәүдә капиталы ияләренә күчүен күрәбез. Күшәр морзаларының җирләре һәм крестьяннары, әлбәттә, Күшәрнең үзендә генә булмаган, тирә-якта да булган. Мәсәлән, Мәрҗани шул ук Мокшы исемле татар авылының да халкы Күшәр морзаларының крестьяннары булганлыгын сөйли. Мокшы крестьяннары әле Мәрҗани заманында Күшәр морзалары кулында

[7] Исмәгыйль Апанаев (1715-1794) – сәүдәгәр. 1782 елдан Татар Ратушасы башлыгы.

булып, алынып-сатылып йөртелгәннәр, ләкин бер кыйсеме *(өлеше)* инде башкалар кулына күчкән булган. Күшәр муллалары да Морза Яушевлар нәселеннән. Алар җиде буыннан бирле өзлексез шунда мулла булып килгәннәр. Димәк, рухани власть икътисади власть белән бер нәселдә берләшкән булган. Болардан 1853тә 92 яшендә үлгән Габбас мулла галим һәм шуның белән бергә дәрвиш табигатьле һәм тере анекдот диярлек[8] бер кеше булган. Ул, Каргалыда укып кайтканнан соң, Күшәрдә 4-5 өйле зур мәдрәсә ачып, шәкерт җыеп, 40 еллар дәрес әйткән, ләкин үзе үлгәч, мәдрәсәсе таркалган. Шуннан соң Күшәрдә зур мәдрәсә булмаган. Габбас мулла турында «Мөстәфадел әхбар...»ның II нче кыйсемендә байтак озын һәм кызыклы мәгълүмат бар. Миңа Күшәр турында һәм Әхмәд Уразаев турында мәгълүмат биргән карт мулла Габдрахман Яушев (Габбас мулла аның атасының бабасы була) заманасында ягының тәрәккыйчы муллаларыннан булган. Ул: «Безнең якта иң әүвәл башлап «Тәрҗеман» яздыручы мин булдым», – дип ифтихар итеп *(горурланып)* сөйли.

«Безнең юл» журналы. – 1928 ел. – №5. – Б.31-32.

Күшәр авылы зиратында Габбас мулла Габдеррәшид улына, аның хатыннары Мөхибҗамал Сәйфулла кызына һәм Хәмидә Байморад кызына куелган таш

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) әл-мәрхүм әл-мөкәррәм
2) мулла Габбас Габд-
3) -еррәшид мулла у-
4) -гылы 91 нче яшьдә
5) дарел-фәнадин дар-
6) -ел-бәкайә рихләт
7) әйләде 1854
8) елда
(уйма язулы):
9) илә рухиһи
10) Лилләһил-фатиха
11) бу җиһан ханәсе кәрвансарай
12) көн би-көн күчәр кидәр шаһ-у гидай
13) каф бәр каф хөкем идәрсәң чарани
14) гакыйбәтдер зәминдә ула җани

Арткы ягында (күпертмә язулы):
1) әл-мәрхүм әл-мөкәррәм
2) Габбас мулла хәләле
3) Мөхибҗамал Сәйфулла
4) кызы вафат 58 нче
5) яшьдә 1849 елда
6) әл-мәүтү кәфә вагыйзән

Сул ягында (күпертмә язулы):
1) икенче хәләле Хәмидә Байморад кызы вафат 60 яшьдә 1854 нче елда кянәт гыйндәл-җәббарән

Үлчәмнәре: 148 х 25 х 14 см.

СҮЗЛЕКЧӘ:

әл-мәүтү кәфә вагыйзән – үлем – зирәк укытучы
гакыйбәт – ахыр чиктә
дарел-бәка – мәңгелек дөнья
дарел-фәна – фани (вакытлы) дөнья
зәмин – туфрак
Лилләһил-фатиха – Аллаһ ризалыгы өчен мәрхүм рухына «Фатиха» сүрәсен укы!
мөкәррәм – кадерле, хөрмәтле
рихләт әйләде – күчте
хәләле – хатыны
шаһ-у гидай – патша һәм фәкыйрь

Ташъязманы ***Раиф Мәрданов*** *һәм* ***Ирек Һадиев*** *укыды.* ■

[8] Габбас хәзрәт белән булган күңелле хәлләр турында Шиһабетдин Мәрҗани язып калдырган.

Солтанайның солтаны

Гөлҗиһан Мәсәгутова, Аида Габдукаева

Мул сулы Тол елгасы күршедәге Чернушка районының Аксаз сазлыгыннан башланып, Урал тауларының итәге буйлап Барда районы аша үтеп, Оса шәһәре янында Чулман елгасына коя. Толның сул як яры үзәненә борынгы авыл – Солтанай урнашкан. Элек-электән авыл халкы игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнгән. Тол буе халкы әүвәлге заманнан иркен яшәгән, белем-мәгърифәткә омтылган.

МИЛЛИОНЕР ХӘЗРӘТ

1832 елда Солтанай авылында урта хәлле Әрманша хәзрәт Мансуров гаиләсендә Мөхәммәтгата исемле бала дөньяга килә. Шәкерт, авылның атаклы Ширван хәзрәт мәдрәсәсендә[1] белем алганнан соң, укуын Төркиядә дәвам итә. Аннан эшкә керешә: исәбе – мал-мөлкәт туплап, ныклы нигез кору. Энергиясе, көч-куәте ташып торган ике метрлы егет солтаны, үз алдына куйган максатка ирешү өчен, сәүдә кәсебенә алына, көнетөне эшли, тәүлегенә нибары дүрт сәгать ял итә һәм, чыннан да, тырышлыгы аркасында, тиз арада зур байлык туплый.

Әлбәттә, Мөхәммәтгатаның тиз генә баеп китүе замандашларын гаҗәпләндергән һәм бу турыда төрле риваятьләр барлыкка килгән. Шуларның берсе турында гына сөйлим. Имеш, бер көнне Мөхәммәтгата хәзрәт авылга терәлеп үк торган Калатау исемле тауга менгән. Менгәч тә, тау өстендәге түгәрәк күлдә ялгыз үрдәк йөзеп йөри икән. Аучы кеше үрдәк язмышы хакында уйлап тормый инде: аны атып ала. Бөтен җире дә ялтырап торган бу үрдәк гади генә кош булмый, аннан алтын сибелә икән. Менә шул үрдәк Мөхәммәтгатаның бик тиз баеп китүенә сәбәпче булган, имеш.

Мөхәммәтгата туган авылында, күрше-тирәдәге Сараш, Бикбарда, Күчтәнтидә берберартлы ачылган кибетләрендә уңышлы гына сәүдә итә. Соңрак, эшен тагын да киңрәк җәелдерә: Пермь, Эрбет, Красноуфимск, Бөре, Күчтәнти, Солтанай, Сараш, Бикбарда авылларындагы кибетләр «Мөхәмәтгата Мансуров һәм К°» сәүдә йортына карый башлый. Ширкәткә Оса өязендәге ике пар тегермәне дә керә. Мөхәммәтгата Солтанайдан 65 чакрым ераклыктагы Оса шәһәрендә, аннары Эрбеттә чәй үлчәп бүлү фабрикаларын булдыра, махсус кибетләр ача. Туган авылы Солтанайда да ак он тегермәне, сусла

---

[1] Аның шәкертләре арасында сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның бабасы Зиннәтулла Әмиров (1829-1910) та булган. Ул, Солтанай мәдрәсәсен тәмамлап, Уфа губернасының Аргаяш кантонындагы Гашир авылында балалар укыткан, Казан ягындагы Кышкар мәдрәсәсендә белем эстәгәннән соң, якындагы Өчиле авылында мулла булып төпләнеп калган.

җитештерү заводы, тире иләү фабрикасы калкып чыга. Кибетләренә товарны Идел һәм Чулман буйлап төрле шәһәрләрдән, нигездә, Әстерханнан үзенең шәхси пароходы белән китертә. Эшкуар хәзрәтнең бер тегермәнендә генә дә 800ләп кеше эшләгән, елга буена затлы, нык йортлар төзелеп, тулы бер урам хасил булган.

Аның улы Касыйм Мансуров та гаять эшлекле егет булып чыга. Ул 1906 елда икмәк продуктларын эшкәртә һәм сата торган сәүдә-сәнәгать ширкәтен оештыра. Ширкәт милегенә Мансуровның Оса өязе Сараш волосте Башап һәм Тол елгалары буенда урнашкан су, вальцовка тегермәннәре һәм заводы да керә. Ширкәтнең төп капиталы булган 150000 сум 500әр сумнан 300 пайга бүленә.

МӘДРӘСӘИ «МАНСУРИЯ»

Мөхәммәтгатаның Солтанайда үз акчасына салдырган мәчет манарасына куелган ай алтыннан булып, ул еракт ан ук балкып торган. Укымышлы эшкуар, сәүдә хезмәте күрсәтү, төбәк халкын эш белән тәэмин итү өстенә, балаларның аң-белемен ачуга да әһәмият бирә: 1897 елда мәчеттән ерак түгел, күпер аша гына мәдрәсә дә салдыра. Анда белем алу өчен якын авыллардан, өлкәнең күп өяз-шәһәрләреннән дә шәкертләр килгән.

Мәдрәсәдә уку-укыту системасы, дәресләр җәдвәле Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе үрнәгендә төзелгән. Дини дәресләрдән тыш, татар теле, алгебра, геометрия, физика, химия, география, биология, логика һәм тарих укытылган. Гата хәзрәтнең Казан имамы, «Мөхәммәдия»нең мөдәррисе Галимҗан хәзрәт Баруди белән элемтәсе яхшы булганлыгы мәгълүм.

1905 елгы революциядән соң, мәдрәсәнең абруе Урал буе, Казан, Уфа, Сембер, Саратов, Пенза губернасы татарлары арасында тагын да үсә. Бирегә чит төбәкләрдән килгән шәкертләр ике катлы тулай торакта яшәгән. Мәдрәсәдән мәчеткә йөрү җайлыуңайлы булсын, аяк киемнәре пычранмасын өчен, Мөхәммәтгата урамга махсус тротуар салдырган.

Мөхәммәтгата булачак муллалардан имтиханны һәрвакыт үзе алган. Әлеге мәдрәсәдә 500дән артык шәкерт укыган. Ул XX гасыр башына 16 класслы затлы гыйлем йортына әверелә. Һәр шәкерт елына 2 сум түләп укыган һәм шуның өстенә, кышка утын китергән. Шәкертләр гадәттә идәнгә утырып белем алган, ятак та идән булган. Атнаның һәр пәнҗешәмбесендә тәртип бозучылар, аеруча, биш вакыт намазны калдыручылар хөкемгә тартылган. Аларны камчы яки таяк белән «сыйлаганнар», идән юдыртканнар, бәдрәф чистарттырганнар. Шәкертләр чиратлап кизү торган.

1912-1913 елларда Солтанай мәдрәсәсе каршында рус класслары да ачылган. Рус теле мөгаллимнәре балалар белән дүрт ел шөгыльләнгән. Ике рус классы булып, берсендә – Солтан Мөхетдинов, икенчесендә атаклы шагыйрь Сәгыйть Сөнчәләй укыткан. Бертуган Сөнчәләйләрнең булачак драматург Риза Ишморат укыган Сараш авылындагы рус-татар мәктәбендә дә укытуы билгеле. Р.Ишморт Рәис Габдукаевка язган хатында бу хакта: *«Мин Шәриф һәм Сәгыйть Сөнчәләй абыйларны атнасына өч мәртәбә Солтанай мәдрәсәсенә илтеп куя идем. Алар анда да укытучы вазыйфасын башкардылар. Сәгыйть Сөнчәләйнең Солтанайда рус теле укытуы исемдә калды. Гата хәзрәтне бер генә күрдем. Сәгыйть Сөнчәләйне Сараштан Солтанайга алып барганда гына. Ул яхшы ук стильдә киенгән иде»*, – дип искә ала. Шәйхулла Тулвинский исә: *«Сөнчәләйнең Солтанайга килүе зур әһәмияткә ия. Шәкертләр арасында яңа фикер таралу активлашты. Тормыштагы сыйнфый каршылыклар, уку-укыту процессын яңарту турында сүз алып барды»*, – дип язып калдырган.

Оса өязе земство депутаты буларак, М.Мансуров 1898 елда Осада җир участогы ала һәм өяздә бердәнбер зур таш мәчет салдыра.

Мөхәммәтгата Мансуровның шәхси әйберләре. Пермь крае, Барда районы, Солтанай авылы мәктәбе

КЫЗЛАРГА ДА ГЫЙЛЕМ ФАРЫЗ

Мөхәммәтгата хәзрәт турында сөйләгәндә, үзе яшәгән йортка каршы 1910 елда төзеткән кызлар мәдрәсәсен дә искә алырга кирәк. Дөрес, кайбер мәгълүматларга караганда, бу мәдрәсәне хәзрәтнең улы Мәгъсум хаҗи ачкан, дигән фикер дә бар. Кызларга дәресләрне хәзрәтнең хатыны Шәмсехәят һәм Гайшә абыстайлар укыткан. Шулай ук булачак язучы, шул заманда ук Оренбургта чыга торган «Шура» журналында беренче шигырьләрен бастырырга өлгергән Кәрим Әмири дә биредә укыткан, дип сөйлиләр. Районның атаклы шәхесләре – Касыймә Казанбаева, Кәримә Ягъфарова, Хәмдия Габдунаевалар исә шунда белем алган затлы, зыялы кешеләр иде. Кызлар мәдрәсәсендә уку сигез ел булган.

Моннан тыш, авылның башка укымышлы-зыялы ханымнары да кыз балаларны үз өйләренә алып сабак биргән. Мәсәлән, Җәүдә Кариевның хатыны кызларны үз йорты янында махсус төзелгән кечкенә генә йортта укыткан. Кызганыч, бу абыстайның исемен өлкәннәр хәтерләми.

М.Мансуров турында пьеса язган драматург Рәдиф Сәгъди (сулда) һәм миллионер хәзрәтнең тормыш юлын өйрәнүчеләр - Ихсан Урыстимеров белән Гөлҗиһан Мәсәгутова. Солтанай авылының мәктәп ишегалды. 2017 ел

«ЙОЛДЫЗ» ГАЗЕТАСЫ «МАНСУРИЯ» МӘДРӘСӘСЕ ТУРЫНДА

Казан каласында Әхмәдһади Максуди наширлегендә басылып, дөньяга таралган «Йолдыз» газетасының 1916 елгы 1583 нче санында Шәйхуллаһ Тулбин мәдрәсәи «Мансурия» турында менә ниләр язган: *«Уса өязенең Солтанай карьясендә (авылында) «Мансурия» мәдрәсәсе – якынча 25 елдан бирле дәвам итеп килгән бер мәдрәсәдер. Бу мәдрәсәнең дикъкатьне иң җәлеп иткән җире – бинасының гаять мөкәммәл булып, хифзы сыйххәткә (сәламәтлекне саклау) тәмам муафыйк эшләнүедер. Мәдрәсә өч бинадан гыйбарәт булып, беренчесе – буе вә аркылысы унөчәр аршин зурлыктагы бер бүлмә – башлангыч сыйныфларга махсустыр. Икенчесе – аннан зуррак астлы-өстле сигез бүлмәләрдер. Өченчесе – буе илле, аркылысы егерме аршин зурлыкта булып, уртада коридор, коридорның һәр ягында бишәр бүлмә һәм мәдрәсәнең бер башында гаять зур бер залы бардыр. Мәдрәсәнең ашханә, тәһарәтханә кеби нәрсәләре дә бик тәртипле булып, чәйгә вә тәһарәткә кайнар су һәрвакытта әзердер.*

Мәдрәсә ихатасында бер мунчасы да булып, атнага ике мәртәбә ягыла, теләгән шәкертләргә нәүбәт белән керергә рөхсәттер. Мәдрәсәне җылыту, юу, себерү кеби эшләрнең һәммәсе хезмәтчеләр тарафыннан эшләнеп, шәкертләргә укудан башка һичбер мәшәкать йөкләтелми. Мәдрәсәдә бер кыйраәтханә дә булып, анда һәртөрле тарихи вә әдәби китаплар күп кенә булуы өстенә, татар газета вә журналларының һәммәсе алынадыр. Кыйраәтханәгә кереп укыр өчен шәкертләрдән кыш буена фәкать егерме биш тиен, авыл халкыннан ике өлеш алынадыр. Бу мәдрәсәдә һәр елны 300дән күбрәк шәкерт җыелып, уку тәртибе – ибтидаи, рөшди, игъдади, гали сыйныфларга бүленеп, сигез мөгаллим вә ике мөдәррис тарафыннан идарә кыйлынмактадыр.

Быел картларга махсус кичке сыйныфлар да ачылып, 40-50 яшьлек картлар бер-ике айда ук яхшы гына «Мөгаллим әүвәл» таный башладылар. Әлеге бичаралар шулкадәр җиңел ысул белән тиз заман язу таныта торган китаплар була торып, бу көнгә кадәр язу белми йөрүләренә үкенеп, шушы рәвешле кыш буе укысак, яхшы гына танып яза белеп чыгабыз, дип, сөенә-сөенә укыйлар.

Бу мәдрәсәнең матди җәһәтен мәдрәсәнең төзүчесе хаҗи Мөхәммәтгата хәзрәт Мансуров җәнаплары тәрбия кыладыр. Мәзкүр хәзрәт дәүләте кулында вакытында мәдрәсәнең бар чыгымнарын авырсынмаенча үз кесәсеннән тота иде, бу елларда да һаман, кулында дәүләте калмаса да, гаять иҗтиһадлыгы аркасында дуст-иш арасыннан

иганә җыеп, шулкадәр зур чыгымлы мәдрәсәнең матди җәһәтен һич косурсыз (кимчелексез) тәэмин итеп киләдер.

Мәзкүр хәзрәт шул ук Солтанай авылына 1912 нче елда бик гүзәл бер кызлар мәктәбе дә салдырып, анда һәр елны читтән мөгаллимә китереп, күп кенә кыз балаларны укыттырадыр.

Мәзкүр хәзрәт шул мәктәп илә мәдрәсәнең билгеле бер вакыфы яки ышанычлы бер килер җире юклыгын исәпләп, шуларның киләчәк көндә дә дәвамына берәр ярдәм булмасмы, дип, үткән сәнә мәктәп-мәдрәсә файдасына бер җәмәгать кибете ачарга карар кылып, һәр паен 5 сумнан һиммәт иярәренә билет сата башлаган иде. Кайбер һиммәтле (тырыш) байлардан берәр бай унар, егермешәр билет алганлыктан, пай тиз заман ике йөздән артып, меңнән артыграк сумма белән быел ноябрь башларында Солтанай карьясенә җәмәгать кибете ачылды».

Аңлашыла ки, бу чорда Мөхәммәтгата мәдрәсәсе иң алдынгы уку йортларының берсе булган. Тагын шунысын да искәртергә тиешбез: 1914 елда Мөхәммәтгата хәзрәт бөлгенлеккә төшә, аның кайбер мал-мөлкәте аукционда сатыла, әмма моның белән генә атаклы хәйриячене дан-дәрәҗәсе, аңа булган ихтирам кимеми. Мәкаләдән күренгәнчә, ул мәдрәсәнең матди хәлен кайгырту өчен башка юллар эзли.

МӨХӘММӘТГАТА – ДЕПУТАТ ҺӘМ ГЕНЕРАЛ

Тирән белемле, рус һәм гарәп телләрен камил белгән, төбәк руханилар башлыгы, үз халкына төрле яклап хезмәт иткән, аның мәнфәгатен хакимият органнарында да яклаган Мөхәммәтгата Мансуров, 1906 елның 16-21 августында Түбән Новгородта үткән III Бөтенроссия мөселман съездында дини комиссия әгъзасы булган, 1912-1917 елларда IV Дәүләт Думасына депутат булып та сайланган. Рәсми чыганакларда, Николай патша аңа генерал чинын биргән, дигән мәгълүмат та бар. Борынгылар сөйләвенә караганда, ул үзенең зур хакимияткә ия икәнлеген раслаучы жетонга да ия булган икән. Җыелышларда бәхәс туса, ул аны өстәлгә куйган, моннан соң беркем дә бәхәсне дәвам итәргә җөрьәт итмәгән. Гомумән, туган җирендә һәм чит-ят шәһәрләрдә Мөхәммәтгата Мансуровның әйткән сүзе үтемле булган.

КҮЛГӘ ИҢГӘН КИТАПХАНӘ

Мөхәммәтгата хәзрәтнең китапханәсе турында аерым әйтергә кирәк. Гаять зур, шәһәр халкын да көнләштерерлек, чын мәгънәсендә гыйлем мәгарәсе була ул. Китапханә шәкертләрне уку әсбаплары белән тулысынча тәэмин иткән, анда Россиянең төрле шәһәрләрендә, гарәп илләрендә нәшер ителгән китап һәм газета-журналлар укырга мөмкин булган. Казаннан да әдәби китапларны бик күпләп алдырганнар. Әмма китапханәнең язмышы фаҗигале тәмамлана. Илдә хакимият башына большевиклар килеп, алар тарафыннан янаулар башлангач, китапларның күпчелеге махсус эшләнгән тартмаларга тутырыла, читләре сумала белән сыланып, күлгә батырыла.

ХАЛЫК ӘЙТСӘ – ХАК ӘЙТӘ

Туган халкы өчен игелекле эшләрне күп башкарган Мөхәммәтгатага якыннары искиткеч зур хөрмәт күрсәткән. Авылларда аның килүе зур бәйрәм тантанасына әверелгән. Җәен Мөхәммәтгатаны авыл халкы урам-ишегалларын себереп, кыш булса, карларын көрәп, ачык йөз, якты чырай белән каршы алган. Мөхәммәтгата хәзрәт катнашында үткән җомга намазларында халык мәчеткә сыймаган, ишегалларына кадәр намаз уку мәйданына әверелгән.

Мөхәммәтгата Мансуров музеенда саклана торган кулъязма китап. Солтанай авылы

Мөхәммәтгата хәзрәт авылдашлары белән һәрчак киңәшеп яшәгән, аларның сүзенә колак салган. Әйтик, авылда су тегермәне төзү турындагы планны да ул авылдашлары белән бергә тикшерә. Мөхәммәтгата хәзрәт ул тегермәнен Толның Хисмәт тау итәгендә төземәкче була, әмма авылдашлары, су басу куркынычын исәпкә алып, тегермәнне агымның түбәнрәк өлешенә күчерергә киңәш итә. Мөхәммәтгата хәзрәт авылдашлары киңәшенә колак сала һәм тегермәнне Башап белән Тол кушылган урында төзетә.

ХЕЗМӘТЧЕ КАВЫЙ

Мөхәммәтгатаның тагын бер изге эше турында язмыйча ярамас. Ул гаять киң күңелле кеше, гади халыкның хәленә керә белгән, ятимнәрне аталарча кайгыртучанлыгы белән халык күңелен яулаган. Хәзрәт үз йортының ишегалдында ятимнәр һәм ярдәмгә мохтаҗлар өчен йорт төзеткән. Биредә яшәүчеләрне ул үз хисабына ашатып-эчерткән, киендергән һәм укыткан. Укып чыкканнан соң, эш белән дә тәэмин иткән.

Исама ага Уразаев «Исемдә калганнар» дигән язмасында менә ниләр яза: *«Минем әтием Әрҗән авылында дөньяга килә. Әтиемә яшь ярым булганда әти-әнисе үлеп китә. Әрҗән авылының мулласы Сәмигулла әтиемне алты яшенә кадәр тәрбияләп үстерә, аннан Кавыйны Солтанайның мөхтәрәм кешесе Мөхәммәтгатага тәрбиягә тапшыра. Кавый тырыш, хезмәт сөючән бала була. Мөхәммәтгата хәзрәт Кавыйны мәдрәсәдә укыта, шул ук вакытта Кавый аңа хезмәт тә итә. Тулай торакта яшәүчеләр өчен ул су кайната яки кубовщик хезмәтен үти. Мәдрәсәне тәмамлагач, Кавый, хәзрәтнең йорты янындагы таш кибетендә сатучы хезмәтен үти. Солдатка алынып, биш ел хезмәт итә. Хезмәт срогы тәмам булуга, ул Солтанайга кайта һәм яңадан Мөхәммәтгата хәзрәт янында хезмәт итә башлый. Хәзрәт дөнья күреп кайткан Кавыйга сатучы, товар склады мөдире, ак он заводы управляющие вазыйфаларын ышанып тапшыра. Егетне үзендә хезмәт иткән һәм тәрбияләнгән Минҗамал исемле кызга өйләндерә, ләкин аның гомере кыска була. 1917 елда Кавый Сәгыйдә Хисамый кызына өйләнә. Илдәге революция ялкыны Солтанайны да читләп үтми. Хәзрәткә куркыныч яный. Менә шул көннәрдә хәзрәт, Кавый белән исәп-хисап ясап, аңа Күперле Башап авылыннан бер йорт бирә. Кавый хатыны белән Күперле Башапка килеп урнаша. Гражданнар сугышыннан соң, Кавый Сараш волосте канцеляриясендә тегермәннәр буенча инспектор вазыйфасын үти. Күперле Башапта беренче колхоз оештыручы һәм аның беренче председателе дә булып тора ул. Халык арасыннан колхозга каршы торучылар Кавый турында: «Колхоз*

тамырына балта чабарга йөри», – дип донос ясыйлар. 1930 елда Кавыйны гаиләсе белән кулга алалар һәм Первоуральск шәһәренә сөрәләр. Кавыйның гаиләсе 8 кешедән тора – 4 малай, 2 кыз, хатыны һәм үзе. Первоуральск шәһәренә сөрелгән кешеләр кирпеч заводы төзи, 5х7 метрлы бүлмәдә 4 гаилә яши, һәр гаиләдә 6-7 бала. Бүлмә кысан, һава җитми, санитария шартлары начар, ике катлы нарларда йоклыйлар. Шул шартларда яшәргә һәм эшләргә кирәк. Халык арасында тиф авыруы башлана. Кавыйны һәм ике улын бу үлем алып китә, аларны Первоуральск зиратында җирлиләр. Балалары Мөнибә, Зыя, Исама, Сәмига исән кала». Хәзрәтнең уң кулы булган ятим, тырыш һәм тугры хезмәтче Кавыйның язмышы шулай тәмамлана.

БАШАПТАГЫ ОҖМАХ ЙОРТЫ

Бөтен Урта Уралның белемгә сусаган егетләрен үзенә тартып торган Солтанай мәдрәсәсен, Мөхәммәтгата хәзрәтнең төзек, җыйнак хуҗалыгын (ике катлы, калай түбәле, акка буялган йортын, абзар-сарайларын), шулай ук Оса, Мәкәрҗә, Пермьдәге йортларын искә алганда, Солтанай кешеләре бу тырыш һәм ярдәмчел затның Башаптагы дача-бакчасын аеруча яратып сөйли. *«Оҗмах иде ул. Ап-ак койма белән уратып алынган. Йорт – түгәрәк күл уртасында, шунда ук алма бакчасы да бар, күлдә Чулманнан китереп җибәрелгән балык, аккошлар... Күл өстендәге асылмалы күпердә аллы-гөлле чәчәкләр үсеп утыра. Искиткеч хозурлык. Гражданнар сугышы елларында бөтенесе юкка чыкты: мәдрәсәсен, тегермәнен ут төртеп яндырдылар. Балыклы күл дә кибеп корыды»,* – дип ачынып сөйли авылдашлар. Мөхәммәтгатаның Оса шәһәрендәге ике катлы йорты әле дә тора, әмма аның кәрнизеннән «Гата Мансуров» дигән сүз генә юкка чыккан.

КАҺӘРЛӘНГӘН ОНЫК

Мөхәммәтгата хәзрәт турында сөйләгәндә, аның берничә мәртәбә хаҗ кылуын да әйтергә кирәк. Ул, халыкка дини һәм дөньяви белем бирүне оештыручы гына түгел, үзе дә фарыз гамәлләрне үтәп яшәгән, ата-бабаларыбыз традицияләренә, гореф-гадәтләренә тугрылык саклаган, бозучыларга исә кискен каршы чыккан. Мөхәммәтгатаның биографиясендә бүгенге буын кешеләренең аң-акылы төшенмәслек бер факт та мәгълүм.

Хәзрәтнең оныгы Әмин Мансуров, Гражданнар сугышында кызыллар ягында катнаша, өяз комиссары була, Алласызлар сафына, күнегелгән тормышны җимерүчеләр ягына баса. Кызыллар белән китеп өлгермәгән Әмин Мансуровның үле гәүдәсен тереләрдән дә ныграк җәберлиләр: Тол аръягына чыгарып ташлыйлар, әмма дуслары аның җәсәден төнлә авыл зиратында җирли. Мөхәммәтгата Мансуров оныгын яңадан казып алдырта һәм елга аръягына чыгарып күмдертә. Иманлы, гомер буе дингә тугры хәзрәтнең карары катгый: «Дәһриләргә мөэмин-мөселман зиратында урын булырга тиеш түгел! Туган-тумачага, хәтта бала-оныкларга да ташлама юк!» Хәер, ул чакта моңа гаҗәпләнерлек тә булмагандыр. Әйтик, тормыштан үз теләкләре белән китүчеләрне, асылынып үлүчеләрне дә гомуми зиратка күммәгәннәр, алар өчен икенче зират булган. Тик бу зиратның кайда булганлыгын картлар, ни өчендер, хәтерләми.

ГОМЕР АЗАГЫ

Мөхәммәтгата хәзрәтнең дә гомере аяныч тәмамланган. Революция көннәрендә тирә-юньгә ямь-нур сибеп торучы мәчетнең алтын ае киселә. Ай, киселеп төшүгә, сазга батырып юк ителә. Шул ук көннәрдә мәдрәсәне дә яндыралар. Ак он заводын сүтеп, Бардага алып китәләр, аның аскы катына – клуб, ә өстендә төрле дәүләт оешмала-

ры урнаша. Ятимнәр йорты да күчерелә, хәзер анда Нәҗмевафа апа Кариева яши.

Хәзрәтне Солтанай авылына килеп кергән латыш укчылары кулга ала һәм, тире дуплый торган зур казанга бастырып, Сараш авылының базар мәйданына, халык алдына хөкемгә алып килә. Хөкем ике көн бара, бик күп халык җыела, халык хәзрәтне исән калдыруны таләп итә. Кешелеклелек, намуслылык, мәрхәмәтлелек җиңеп чыга – Мөхәммәтгатаны халыкка эшләгән игелекләре коткарып кала. Байлык-мөлкәте тар-мар ителгән хәзрәтне бер асравы үз тәрбиясенә ала. Мөхәммәтгата аның кулында 1924 елда дөнья куя. Хәзрәтне соңгы юлга озатырга күрше авыллардан һәм районнардан бик күп кеше килә. Мөдәррис, имам-хатыйп, хәйрияче, депутат, генерал, данлыклы миллионер, сәүдәгәр һәм күпләрнең остазы, хаҗи Мөхәммәтгата Мансуровның тормыш юлы шулай тәмамлана.

Мөхәммәтгата Мансуровның кабер ташы

ШӘКЕРТЛӘР

Мөхәммәтгата хәзрәт мәдрәсәсен тәмамлаучыларның күбесе зыялы, кешелекле, хезмәт сөючән, намуслы булган. Язучы-шагыйрьләр Кәрим Әмири, Шәйхулла Тулвинский, Нурулла Ягъфәров (Нурулла Сандугач), мәгърифәтче Рәхимҗан Атнабаев – аның укучылары. Шунда ук аның булдыклы уллары – Касыйм, Мәгъсүм һәм Миргалим да белем ала. Соңрак алар да әтиләре кебек үк эшкуар һәм дин эшлеклесе булып җитлегә. Күп шәкертләр Совет хакимиятен оештыруда башлап йөргән. Мәсәлән, Хөснулла Кариев, Мөгатасим Казанбаев, Гыйлемулла Кузяшевлар Сараш авылында Совет власте урнаштырган, Мөхәммәт Габдукаев исә Солтанайда беренче авыл советын төзүче.

Мөхәммәтгата хәзрәтнең йорты революциядән соң белем-мәгариф учагы булып торган, анда совет мәктәбе эшләгән. Төп йорт һәм ишегалдындагы биналар класс итеп җайланган, мәктәп балаларга дүртьеллык белем биргән. Укытучылар, гадәттә, хәзрәт мәктәп-мәдрәсәсен тәмамлаган шәкертләр, Оса шәһәрендәге татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерли торган курсларда белем яңартып, советча укыта башлаган. Менә алар: Гарәфи Туктамышев, Фазыл Әминов, Зәкия Нәбиева, Мөхәррәм Хәйдәров, Касыймә Казанбаева, Гаптелҗан Казанбаев, Мирзый Габдукаев, Мөхәммәтҗан Габдукаев, Габдрәхим Имәнгулов. Шулар арасыннан абыйлы-энеле Мирзый һәм Мөхәммәтҗан Габдукаевлар, Фазыл Әминов, Нәҗмехан Нәбиев – репрессия корбаннары. ■

ФАРАЗ

Асылында ни, Русия?

Риваль Хафизов

Варягларны чакыру. Виктор Васнецов рәсеме. 1909 ел

Бу эшкә без бихисап тарих китаплары укып та байтак сорауларга җавап таба алмагач тотындык. Эшебезнең ни дәрәҗәдә җиренә җиткерелеп башкарылуын Сезгә хөкем итәсе, хөрмәтле укучы! Борынгы фәйләсуфнең әйткәннәрен истән җуймыйк: хакыйкать бәхәстә туа. Безнең карашлар яисә эзләнү алымнары һәм юллары тарих белеменең традицион кануннарын исәпкә алып бетермәскә мөмкин. Ләкин, уйлап карасаң, бу – өстенлек түгелме икән? Үзешчән тарихчы яшь-җилкенчәкне тәрбияләп «чыныккан» һәм үз тәгълиматларының какшамас булуына инанган профессурадан күп мәртәбә азат һәм мөстәкыйль ләбаса...

Ошбу мәкаләне, тарихи хезмәттән битәр, тарихи-публицистик язма буларак кабул итүегезне сорыйбыз.

1

Мөгаен, сүзне Новгород архиепископы, Мәскәү митрополиты Макарийдан башларга кирәктер. Әле Явыз Иван, явызланып өлгермичә, сабый гына булганда, әлеге дин әһеле илдә сакланган барлык урыс һәм тәрҗемә язмаларны җыеп алырга боера, аны «эшкәртә һәм системалаштыра» башлый. Ләкин чыганакларны шулкадәр үзгәртеп-бозып бетерә ки, бу язмаларны укыгач, ана үз баласын да таный алмас иде.

Үзгәреш кичергән бихисап этнонимнарның кайберләренә тукталып үтик. «Слово о полку Игореве» әсәрендә ***баш әнәк*** (*баш ана эт* мәгънәсендә) ыруы (чагыштырыгыз: ***башкурд*** – *баш бүре*) ***печенег*** *(бәҗәнәк)* рәвешен алган, ә ***аккош*** мәгънәсен белдергән ***көяз ак*** һәм ***купшы ак*** (*казакъ* һәм *кыпчак*) ыруларының атамалары аллегорик *кошлар-аккошларга* әверелгән (Игорь шишәге белән су чумырып эчкәндә алар ***Дон (Тын)*** елгасы артында очып йөргән, имеш).

Нәкъ шул рәвешле төрки ***кызмак*** *(кызучан, тиз кабынып китүчән)* сүзеннән легендар ***Кожемяка*** хасил була: янәсе, бәҗәнәк ханы урыс гаскәре алдына баһадирын чыгарып бастыргач, Владимир кенәз муен тамырын кашыган – бәй, аның моңа тиң сугышчысы юк икән бит! Шулвакыт бер карт тире изгәндә ***(мял кожу)*** кулын кискән төпчек улына сугышырга тәкъдим иткән...

Урыс тарихында андый үзгәрешләр бихисап.

Мәсәлән, свев халкының ***хәрәкәттәге ыру алае (дружинасы)*** *(ruhrig, sine hus, thru voring)* гыйбарәсе могҗизалы рәвештә бертуган варяглар исеменә – ***Рюрик, Синеус*** һәм ***Труворга*** әйләнә. Хәер, ***тәңкә*** – *деньгага*, ***вак акча*** *векшага* әйләнгән кебек.

Тарих белеменең этимология өлкәсенә караган төп сорауларга җавап бирә алмавы төбендә, билгеле, бик гади сәбәп ята: православ-славян шовинизмы нигезендә төзелгән яңа дәүләткә ничек тә «татарлык»тан арыну кирәк була... Шуңа да, бүген теге яисә бу атамаларга гомумтөрки тел аша мөрәҗәгать итеп карау җитә – мәсьәлә үзеннән-үзе чишелә дә куя.

2

Борынгы Кавказны өйрәнеп, 1978 елда «Ранние тюрки на Северном Кавказе» исемле китап чыгарган Н.А.Федоров белән Г.С.Федоровлар бу төбәктә киң таралган *ут ягу урыны* – ***отжага***ны төрки тамырлы итеп карау яклы түгел. Алар фикеренчә, бу очракта сүзтезмә мәгънәсез бер гыйбарәгә әверелер иде: йә, ***ут җака (утлы яка)*** ни дигән сүз инде ул? Шул ук вакытта, әлеге әфәнделәр, беренчедән, мондый корылманың, төрки халыкларга хас булганча, чыбыктан үрелеп, балчык белән ныгытылуын искәртә; икенчедән, төрки милләт вәкиле бу сүздә үзеннән-үзе ***ут җага (ут яга)*** тезмәсен һәм аннан үзгәреш кичереп ясалган ***учак*** сүзен ишетә (бусы, үз чиратында, ***очаг*** рәвешендә урыс теленә дә күчкән).

Кызганыч, Кавказны өйрәнгән галимнәр төрки телдән калган җирле топонимнарга һәм биредә төркиләр яшәвен раслаган археологик казылмаларга таянып тормаган. Югыйсә, витязьнең *барс* (урыс тәрҗемәләрендә – *юлбарыс*) тиресен киюен дә аның фәкать ***Урарту (үр арты)***, ягъни борынгы ***Барсилия*** хуҗалары *(Барс уллары)* мантиясенябынуы белән бик җиңел аңлата алырлар иде. (Шота Руставелли үзе дә әсәрнең фарсы хикәятеннән «күчерелүен» искәртә).

Бу җәһәттән аргонавтларның алтын сарык йоны эзләп нәкъ менә Кавказга баруын искә төшерик. Алтын йонны ***Ээт (эт?)*** исемле мифик зат саклаган. Шулардан чыгып фикер йөртсәң, ***Осе-***

«Мамай явы турында хикәят» исемле борынгы урыс әсәреннән миниатюра. XV йөз

тия сүзе дә төрки мәгънә белдерергә мөмкин: ***өс эт ия***, икенче төрле әйткәндә, ***менге*** (атланып йөри торган) ***этләр иле***!

Кавказ тарихы **Угарит** шәһәрен дә белә әле. Аның мәгънәсен без җиңел генә ***югары эт*** (шул ук *менге эт*) дип аңлата алабыз. Өстәвенә, бу туфракта гомер кичергән төп каһарманнарның исемнәре дә игътибарга лаек: **Анат** *(ана эт)*, **Карат** *(кара эт)*, **Акхат** *(ак эт)*.

Шушы урында Платонның *атлантлар* белән *этрусклар* сугышы турындагы язмасын искә төшерү мәслихәт. ***Этруск – эт үр өске***, шул ук *менге эт* мәгънәсендә булып чыга түгелме соң?

3

Ромул белән Рем мәгърур Рум каласын төзегәннән соң да төркиләрнең ***үгез*** һәм ***ат, барс*** һәм ***елан, дуңгыз, аккош, бәрән*** ыруларының (шәрык календаре буенча, алар, мөгаен, унике булгандыр) Европага үтеп керүе дәвам итә һәм *минотаврлар, кентаврлар, гидралар* рәвешендә җирле мифологиядә урын ала: әйтик, Геракл ***арыслан*** белән ***үгез***не үтерә, ***болан***ны буйсындыра, Стимфалия ***кошларын*** юкка чыгара, ***кабан дуңгызы***н җиңә, Авгийның ***ат*** сараен тазарта...

Гомерның Одиссее *«үгезләр һәм бәрәннәр илендә була, андагы бер ыру нурлы илаһ чыккан урында яши, икенчеләре – ул баткан урында»*...

Днепр буе ***бәрән*** ыруының биләмәсе булса (Барань, Киев (*куй* сүзеннән), Козельск, Козлов, Козловка һ.б. шәһәр атамаларын хәтердә яңартыйк), ***Дон (Тын)*** буйлары – ***эт*** ыруы биләмәләре булган: әле Төрки каһанлык чорында да нәмәгълүм ***эт-байрак***лар ***Идел-Әтилдә (эт ыруы елгасында)*** төрек гаскәрен тар-мар итеп ташлый. Монголлар тарафыннан ***нугайлар*** дип аталган ыру, хәтерләсәгез, кенәз Андрей Курбский тарафыннан ***Кырым этләре*** дип сүгелә.

Ләкин тарих һәрвакыт үзенчә гамәл кыла һәм үз юлы буйлап үсә-үзгәрә: көчсезләнгән ыруны ә дигәнче көчлерәк ыру буйсындыра, кысрыклый. Бу хәл антик мифологиягә нигез салынган елларда да, аннан соңгы чорларда да күзәтелә: Һиндстан белән Алмания арасындагы ***Скифия***не (әлегәчә сыерны изге хайван санаган Һиндстанда бу атама – ***Сакстан***, ә *мөгезле баш киемен* яраткан Алманиядә ***Саксония*** рәвешендә сакланган) тоткан сакларны ***(йолдыз маңгайлы үгезләрне)*** һуннар (***атлар***; кытай телендә ***гун – хәрәкәт*** дигәнне аңлата, уйгырларның борынгы бабалары турында кытай чыганакларында болай язылган: ***алар тояклы һәм җәяү йөрергә ярата***) алыштыра. Аннары һуннар урынына ***тур*** (ягъни ***кыргый үгез***) ыруы – ***төрек-угызлар*** килә. Төрекләрне ***этләр*** җиңә, ***этләр***не – ***көяз ак***лар һәм ***купшы ак***лар, ә ***казакъ-кыпчак***ны исә монголлар тез чүктерә.

Җөмләдән, борынгы риваять буенча, монголларның *анасы* – ***болан***, *атасы* ***бүре*** булган дигән ышану яши.

4

Төркиләрнең тотем фәлсәфәсеннән кала, этноним барлыкка килүнең тагын бер чыганагы бар, ул да булса – торак урыны. Монда без, нигездә ***ары*** мәгънәсен белдергән ***ар*** кушымчасын еш куллануны күрәбез.

Шеңҗан-Уйгыр автономияле районының (Кытай Халык Җөмһүрияте) башкаласы Өремче шәһәрендә *аръякны* бүген дә ***суар (сувар)*** дип атыйлар.

Балкарлар, ягъни малкарлар, ***Малка елгасы ары*** яшәгәнгә күрә, шундый атама йөртергә мөмкин. ***Табасаран – тау ас ары ан, авар – тау ары.***

Мишәр – мишә ары, ягъни урман артында яшәүче ыру. Чыннан да, Кыргый кыр ягыннан караганда, Мещера җирлеге Тула, Брянск, мордва урманнары артында (ягъ-

ни, алардан ***ары***) урнашкан. Казанга яу чабуны сурәтләгәндә кенәз Андрей Курбский, Рязань һәм Мещера җирләрен узгач, өч көн буе мордва урманнары аша чыгу турында яза. Җөмләдән, бу юлдан үз вакытында ***Куликово кыры***на (чыганак телдә, мөгаен, ***Куйлык кыры*** тиештер) Дмитрий Донской узган була инде.

Андрей Курбский. Павел Рыженко рәсеме. 2009 ел

Бөек Болгар иле, көнчыгыштан көнбатышка таба күз ташлаганда, *Болак ары* булып чыга. Борынгылар *Идел-Әтилне* төньяк диңгезләр белән Каспий арасындагы ермак (болак) итеп күргән.

Бөек Болгарның төн ягында фин-угыр җирләре – ***Кара ил*** яткан, шуннан ***Карелия*** барлыкка килгән. Бу җирләргә болгарлар да, варяглар да күз төшергәләгән. Ибне Фадлан Идел буйлап килгән ***арос***ларның (бу сүз, гадәттә, ялгышып, ***рус***лар дип укыла, гәрчә сүз үзе ***ары өс***, урысчалап әйтсәк, ***дальневерховские*** дигәнне аңлата һәм Скандинавия тауларында яшәүчеләргә карата кулланыла; бәлки ***Норвегия*** атамасын да белдерәдер әле – славяннарның ***надверхье*** сүзе белән чагыштырып карагыз) җарияләр һәм җәнлек тиресе сатуына, гаскәр башлыкларының җәсәден утка тапшыру күренешенә шаһит була.

Урта Азия ягыннан караганда ***Тартария*** дала артында – ***Тахта ары*** урнаша. Кәрван юлы ***Тар*** (Сырдәрья кушылдыгы) һәм ***Тарим*** елгасы тарлавыгы аша узгач, мосафирларның күз алдында коточкыч мәгърурлыгы белән ***Тартария*** (урыс язма һәйкәлләрендә – ***Тартарары***) калыккан, ***Тарим*** тигезлегенең иң зур өлеше – Такла-Макан чүле, һич арттырмыйча, борынгы китапларда язылган Җир асты – үлеләр патшалыгын хәтерләткән.

Кытай географлары Тартариядә яшәүчеләрне өч төркемгә бүлә: ***ак татарлар, кара татарлар*** һәм ***кыргый татарлар*** (Чыңгызханны ахыргы төркемгә кертәләр). Билгеле, Татарстан галимнәре үз халкын «ак» һәм «матур» итеп күрсәтү яклы. Ләкин игътибарга алу зарур – үзбәкләр, мәсәлән, бүген дә дөньяның төрле ягын төрле төс белән билгели: аларча, көньяк – ***ак як***, төньяк – ***кара як***. Төрки телдә ***кыргый*** сүзе исә, төп мәгънәдән тыш, ***далада***, ***кырда яшәүче*** дигән мәгънә дә белдерә. Шул рәвешле фикер йөртсәң, ***ак татарлар*** дигәне – көньяк уйгырлар, ***кара татарлар*** дигәне – алтайлар һәм тува халкы, ә урта дала – монголлар биләмәсе булып чыга.

Ярты дөньяны яулаганчы, *татар монголлары*ның әүвәл *татар уйгырларын* һәм *татар туваларын* буйсындыруы табигый.

5

Үгәдәй хан 1241 елда үлгәннән соң, Монгол дәүләтенең башкаласы булган Каракорымда тәхет өчен низаг туа, ул арада гаскәрбашы Батый (Бату) Әдрән диңгезгәчә яу чабып, ниһаять, ***Олы Тын Урдага*** (соңрак ул урыс чыганакларында хаталы рәвештә ***Алтын*** дип күрсәтелә башлый, гәрчә атаманың килеп чыгышы турыдан-туры ***Дон (Тын)*** елгасы белән бәйле булса да) нигез сала.

Ләкин Батый, чыннан да, Җучи ханның улы, Чыңгыз ханның оныгымы соң? Бу хакта бездә шик бар. Килешмәвебезне кистереп әйтергә базмасак та, ***бәрәннәр*** ыруының

«Кыргый кырның, гадирәк әйткәндә, Украинаның гомуми планы». Француз хәрби инженеры һәм картографы Гийом Левассёр де Боплан эше (картада көньякның өстә, төньякның аста урнашуына игътибар итегез). 1648 ел

башлыгы ***Бәти (Батый)*** үз вакытында тәрбиягә алынган бала булырга мөмкин, дип фаразларга урын калдырабыз.

Мәҗүси исемнәргә системалы рәвештә күз ташлау Кавказны буйсындырган Кучук исемендә ***көчек*** сүзен укырга мөмкинлек бирә. Төрки телне белгән кеше өчен башка мисалларның мәгънәсен чамалау да бернинди авырлык тудырмый: һуннар җитәкчесе ***Атилла*** – *атлы*, *ат ыруыннан*; Алмыш ханның этисе ***Җылкы*** – *елкы*. Казакъ ыруларының берсен җитәкләгән ***Алаша***, гомумән, тәрҗемәгә яисә өстәмә шәрехләүгә мохтаҗ түгел. Мамайның *(маэмай)* ***эт*** ыруыннан булуы күренеп тора. ***Үзбәк*** хан исемен ***Угызбәк***, ягъни *угызлар бәге* дип укырга мөмкин.

6

Татарстан Җөмһүрияте башкаласы – ***Казан*** шәһәре этимологиясе турында да байтак фаразлар яши. Шуларның иң гадие: ***каз*** өлешен тамыр итеп аласың да, атаманың мәгънәсен ***каз каласы*** дип аңлатасың. Астына учак якмыйча су кайнаткан ***казан*** хакындагы риваятьне дә һәркемнең ишеткәне бардыр.

Әмма!..

Лев Гумилев ***Касансай*** елгасы (Сырдәрья кушылдыгы) үз чорында төрки дөнья белән Урта Азия арасында чик булып торган, дип яза. Әрмәнстандагы ***Касах*** елгасы да шул ук вазыйфаны үтәгән. Өстәвенә, безнең игътибарны бер антик хәбәр дә җәлеп итә: борынгы греклар Кара диңгез янында ниндидер «кунакчыл һәм дустанә булмаган» тагын бер диңгез барлыгын күрсәткән. Сүз, һичшиксез, ***Каспий*** хакында барырга охшый. Чөнки, төрки телдәге ***кас*** сүзе ***дус*** сүзенең капма-каршы, антонимик мәгънәсен белдерә (та-

Казан күренеше. Алман сәяхәтчесе, географы, тарихчысы Адам Олеария гравюрасы. XVII йөз

мырдаш сүзләрне күздән кичерик: *кас, касд, касмак, каста, кәс, кәсафәт, хәсис, хәсрәт).*

Борынгы әкиятләргә кергән ***Каф*** тавы да дала белән ике арада табигый чик булып торган.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, безнеңчә, ***Казан*** сүзе *чик урыны* мәгънәсен белдергән һәм чуашлар тарафыннан ***Кашан***, ә марилар тарафыннан ***Ком-Ола*** дип аталган (*ком* һәм *Кама* сүзе мари телендә *кырый* дигәнне аңлата).

7

«Слово о полку Игореве» әсәрен яклаучы В.Чивилихин «Память» исемле эссе-романында болай дип яза: *«Илебезнең бик күп әдәбиятчысы, тарихчысы, тел белгече, ватан тарихын һәм сүз иҗатын сөючесе әлеге әсәрнең авторын ачыкларга теләп күп көч түкте, әмма бу тырышлыклар һичнинди уңыш китермәде»*. Бүген андый тикшерүчеләрнең саны өч меңнән артып китте, диләр.

Академик Д.С.Лихачев «Изборник» исемле борынгы урыс әдәбияты үрнәкләре җыелмасына керештә: *«Борынгы урыс язучылары – аерым торган биналарның мигъмарлары түгел»*, – дип язган иде. Янәсе, алар бер соклангыч ансамбль булып җыелган цикллар, әсәрләр, нөсхәләр иҗат иткән.

Ләкин академик ялгыша. Без бу әсәрләргә «Мәскәү – өченче Рум» идеясенә җанытәне белән ышанган, шуны гамәлгә ашырырга омтылган һәм «адашкан җаннарны тугры дингә кайтарган» митрополит Макарийның кул тыгуын күрәбез, чөнки: *«Игелек җимеше китермәгән һәр агачны чабып алып учакка ташлау мәгъкуль»* (Матвейдан: 7-19).

Аның каравы, Д.С.Лихачев бер мәсьәләдә, һичшиксез, хаклы: *«Үсеш-үзгәрештә булган милли үзаңга тарихи үзбилгеләнү тиеш, аны булдыру өчен җирле чынбарлык мәсьәләләрен ачуга багышланган вәгазьләр һәм публицистик язмалар булдыру кирәк, шул очракта гына теге яисә бу халык гаҗәеп дөнья тарихында үз урынын табарга мөмкин»*.

1999 ел ■

Безнең мирас №3 март 2018

«Сәнәкчеләр» фаҗигасе

Гасимә Мостафина-Рәфыйкова

Якын туганнарым белән бер йортта, күрше подъездда яшәүче, һәркемгә ярдәм кулы сузарга әзер торган шәфкать туташы Фатыйма ханым үзендә дәү әнисенең – гыйбрәтле озын тормыш юлы үткән, яшьлегендә җан тетрәндергеч вакыйгаларга юлыккан Татарстанның атказанган укытучысы ***Гасимә Хәсәнша кызы Мостафина-Рәфыйкова****ның (23.03.1900-02.06.1997) кулъязмалары – истәлекләр дәфтәре саклануы турында хәбәр итте. Тарихка «Сәнәкчеләр» хәрәкәте» – восстаниесе (1919-1920 еллар) булып кереп калган бу фаҗигале вакыйгалар мине дә битараф калдырмады. Ул коточкыч вакыйгаларны үз башыннан кичергән Гасимә Хәсәнша кызының истәлекләрен «Безнең мирас» журналы укучыларына гыйбрәт итеп тәкъдим итәм.*

Рафинат Сәлахов

1919 елның сентябрендә эти мине Бөгелмә өязендәге Бәкер-Иштирәк авылына илтеп куйды. Биредә мәктәп ачу күздә тотыла һәм мин анда балалар укытырга тиеш илем. Торырга Закирова фамилияле хатын йортына урнаштым. Мәктәп бер катлы агач йорттан гыйбарәт иде. Кызлар җыеп, аларны укыта башладым. Ә малайларны исә, авылның икенче очында, Фатыйх Туйкин исемле 35 яшьлек егет укыта башлады.

Февраль ае башланды. Беркөнне миңа хәрби комиссариатның чакыру кәгазен китерделәр. Анда: «Сез Кызыл Армиягә ярдәм итү атналыгына алынасыз. Кичекмәстән килеп җитегез», – дип язылган иде.

Югалып калдым. Укучыларымны җыйдым да барысын да сөйләп бирдем. Бергә кайгырыштык, елаштык. «Сезне Фатыйх ага укытачак», – дип, аларны тынычландырырга тырыштым, тик кызлар елаудан туктамады. Мине авыл советыннан килгән олау алып китте.

Мин киткәннән соң, укучыларым таралыша. Ул көннәрдә кулаклар баш күтәрә. Фатыйх Туйкинны, тирес өеменә бастырып, атып үтерәләр. Шуннан соң Бәкердә мәктәпләр булмый.

Повестка килер алдыннан, Әлмәттән әтиемнең авыр хәлдә булуы турында хәбәр алдым. Бу хәбәрне китергән Мөхәммәди абзый чанасына утырып, Әлмәткә юл тоттым. Әтинең хәле авыр иде, табиблар да, дарулар да юк. Ул, сөйләшә алмаса да, кайтуыма сөенде. Әти икенче көнне вафат булды. Аны озатырга авылдашлар җыелды, җирләдек.

Чыршылы авылына килдек. Ул вакытка чакырылган башка укытучылар да анда иде. Концертка әзерләндек, репетиция ясадык.

Концерт Чыршылы мәктәбе бинасында узды. Шул көннән соң мине «кара күзле җырчы кыз» дип йөртә башладылар.

Без, Чыршылыда гына түгел, тирә-күрше авылларда да концерт һәм спектакльләр куйдык. Алардан җыелган акча Кызыл Армиягә җибәрелде.

Илдә Гражданнар сугышы бара. Чыршылы тирәсендәге авыллардан кулаклар котырткан халыкның баш күтәрергә җыенуы турындагы хәбәрләр килә. Тик шуңа карамастан, район җитәкчелеге һәм хәрби комиссариат безне Чыршылыдан ерак түгел генә урнашкан керәшен авылы Аналыкка концерт куярга җибәрде.

Анда безне беркем дә каршы алмады. «Халык йорты»ның ишегендә йозак эленеп тора иде. Шулай аптырап басып торганда бер кеше пәйда булды. «Туганнар! – диде ул. – Тизрәк китегез. Сезне бирегә юри китергәннәр. Әби авылыннан тиздән монда «сәнәкчеләр» киләчәк, ә безнекеләр мәчеттә җыелды. Тегеләр килүгә, безнекеләр дә аларга кушылачак. Сезне үтерәчәкләр!» Бу сүзләрне ишетүгә, без – хатын-кызлар елый башладык. Мөсәгыйт исә кесәсеннән наган чыгарып: «Киттек! Минем арттан!» – дип, алга ыргылды. Февраль суыгында 12 чакрым юл үтеп, Чыршылы авылы читенә җиткәч, еракта куып килүчеләрнең куркыныч кычкыру тавышларын ишеттек. Авылга керүгә, төрле якка сибелдек. Үзем фатирда торган Нуриәхмәт абзыйның ишеген шакыдым. Ул, ишекне ачмыйча: «Теләсәң кая кит, коммунистка, сине кертеп, үләсем килми!» – дип кычкырды.

Нуриәхмәт абзыйның йорты урамның аргы очында, агачлар арасында иде. Мин елга ярындагы мунчаны искә төшердем. Кар көртен ерып барып, мунча ишеген ачтым һәм ләүкә астына яшерендем. «Таң атканчы кая барыйм соң, – дип уйлап куйдым мин. – Көн яктыруга, эзләремнән килеп табачаклар». Шулчак мунча янында хатын-кыз тавышы ишетелде: «Гасимә! Сеңлем, син мондамы? Чык. Нуриәхмәт абый, анда утырмасын, бандитлар, табып, мәсхәрә итәрләр, ди. Чык аннан». Димәк, бу кешеләр барысын да алдан белеп торганнар.

Әлеге хатынның сүзләренә ышанмасам да, чыгарга мәҗбүр булдым. Урам аша үтеп, аларның ишегалдына кергәч, ул мине абзар янындагы салам эскертенә алып килде дә: «Бу саламга яшерен. Мин сине өстән беркем дә күрмәслек итеп каплармын. Әгәр тапсалар, мин яшергәнне әйтмә...», – диде. Һәм ул, мине салам белән каплап, каядыр юкка чыкты.

Төн узды, ахры, салам аша кояш нурлары үтеп керә башлады. Күз яшьләрем, киемемдә катып, энҗе кебек ялтырый. Мин аларны, уч табаным белән сөртеп, битемә ышкыйм. Шулчак эскерт янында хатын-кыз тавышы ишетәм. Нуриәхмәт абыйның күршесендә 17 яшьлек сукыр улы белән яшәүче карчык икән. «Гасимә кызым, бу мин – Нуриәхмәтнең күршесе, – ди ул. – Нуриәхмәт белән сөйләштек тә сине минем идән астына яшерергә булдык. Чык, кызым, курыкма, урамда кешеләр күренми әле. Менә бу абзар артыннан минем абзарга узарбыз. Беркем дә белмәс. Киттек, кызым, курыкма».

Әби артыннан барып, сарык абзарына кердем. Шуннан соң кәҗәләр токкан абзарны узып, ишегалдына чыктык һәм өй янына килдек. Әби ишекне шакыды. Озын буйлы сукыр малай, ишекне ачып, безне өйгә уздырды. Әби улына: «Менә, улым, бу – теге матур җырлый торган укытучы кыз. Аны идән астына яшерик әле, беркем дә белмәс. Нуриәхмәт белән шулай килештек», – диде.

Минем өстә иске шинель поставыннан тегелгән пальто. Әби аны салдырды да улына: «Яшер!» – дип боерды. Аннары миңа ипи кисәге белән сөтле чынаяк сузды: «Аша-эч, кызым». Сөтне эчтем, ә ипи тамагымнан үтмәде.

Әби, идән асты тактасын күтәреп, миңа аска төшәргә, ә улына бүлем такталарын алырга кушты. Сукыр малай бүлем такталарын куптаргач, берничә сырма сузды һәм аларны шунда җәяргә боерды. Малай бөтенесен дә эшләгәч, миңа шунда кереп ятарга кушты. Шул аралыкка кереп яткач, малай такталарны яңадан урынына кадаклады.

Көн узды, ахрысы. Идән такталары арасындагы ярыклардан лампа уты яктысы сирпелә. Менә идән астына сукыр малай төште. Ул, такталарны кубарып, миңа: «Чык, апа, әни өйгә чакыра», – диде. Аралыктан чыктым, әмма баса алмыйм, аякларым тыңламый. Берничә минуттан, ниһаять, өскә мендем. Әби, мине кочып: «Әй, кызым, син бит кемнеңдер кадерле баласы, алар нинди хәлгә төшүеңне беләләрме икән?» – дип, такмаклап елый башлады. Аннан маңгаемнан үбеп: «Әнә, чоланга чиләк куйдым, шунда чыгып юын», – диде һәм миңа сулы комган сузды.

Ул кушканча эшләгәч, сәке кырыена утырып, ипи кисәге белән бер чынаяк чәй эчтем. Шуннан соң әби миңа яңадан идән астына төшәргә кушты. Сукыр малай, мине каплап, такталарны яңадан кадаклады. Бу юлы инде «төрмә»мә тәүлек буена яптылар.

Сукыр малай, икенче көнне урамнан кергәч, идәнгә ятып, миңа яңалыклар сөйләде:

– Военкомат янына сәнәк һәм чалгылар күтәргән күп кеше җыелды. Анда бер абзый: «Теге урыс кызы әле исән булып чыкты. Икенче берәүне алып килгәч, селкенеп куйды. Мин аңа тагын бер пуля утырттым», – диде.

Бу, билгеле, урыс теле укытучысы Зоя Зверкова иде. Икенчесе исә – китапханә мөдире иптәш Гамбәров. Сукыр малай бу турыда ишеткәч котым алынуын аңладымы икән?..

Нәрсә өчен? Халыкка белем яктылыгы илткән кыз һәм улларны җәзалаган бу явызлар кемнәр?!

Төн җитте. Сукыр малай мине «кабер»дән чыгарды. Әби миңа кайнар чәй белән ипи кисәге бирде. Кайнар чәйне эчтем, ә ипине бер генә каба алдым, ул бугазда терәлде. Әби, күзләремә карап, күз яшьләре аша миңа: «Кызым, миңа ачуланма инде. Иптәшләреңне – Гайшә исемле укытучыны, балалар бакчасында эшләгән Зифаны, күлмәк шкафында яшеренеп яткан җиреннән тартып чыгарган укытучы Маһруйны өтермәнгә озаттылар. Китапханә мөдире Мөсәгыйтне һәм аның хатынын, тотып алып, аттылар һәм тирес өеменә ташладылар. Син генә калгансың, диләр. Улым: «Әйдәгез, авылдагы бөтен йортларны актарып чыгыйк, мөгаен, теге сукыр малайлы карчыктадыр...», – дигәннәрен ишетеп калган. Хуш, кызым, рәнҗемә миңа!» – дип, өй ишеген ачты. Мине салкын февраль төнендә урамда калдырып, артымнан ишекне бикләп куйды.

Зәңгәр күктә йолдызлар җемелди. Нининдидер йолдыз минем туганнарым өстендә балкыйдыр! Салкын ишегалдында нишләргә миңа, кая барырга?! Авылда тынлык, кешеләр йоклыйлар. Бер ишегалдында келәт күрәм, ишегендә йозак юк. Ларларның берсенә арыш салынган. Аңа кереп, арышка күмелергә тырышам. Юк, арыш аз, мине капларлык түгел. Аннан чыгып, койма буена килдем. Урамда җан әсәре юк. Шунда кылт итеп исемә төште: таш мәктәптән ерак түгел генә Әлмәттә яшәгәндәге күршем – көмеш остасы Нурлыбанат ире Шамил белән тора бит. Кайчандыр ул миңа: «Безгә дә кер, мин монда яшим», – дип әйткән иде. Бу минем яралы күңелемдә өмет уятты. Койма буйларына сыенып, аларның капкасына җиттем. Алгы як ишекне сак кына шакыдым. Ишекне Нурлыбанат апа үзе ачты.

– Әй, Гасимә җаным, төн уртасында... – дип тәкрарлады ул.

– Апа, туганым, мин... коткара күр, – дип ялвардым.

– Кер, кер, Шамил Куакбашка баш күтәрүчеләр җыенына китте, тиздән кайтыр инде, – диде ул. – Кер, җылын, менә идәнгә ятып тор.

Шул сүзләр белән ул почмак як идәненә сырма җәеп, мендәр куйды. Аннары өстемә нининдидер авыр ирләр пальтосы япты.

Җылынырга да өлгермәдем, ишек шакыдылар.

– Менә Шамил дә кайтты, – диде Нурлыбанат апа. Ул иренә чишенергә булышканда, Шамил абый, идәндә яткан кешене шәйләп алып:

– Кем ул? – дип сорады. Нурлыбанат апа калтыранган тавыш белән җавап бирергә дә өлгермәде, ул: – Бу нәрсә тагын, тапкан кая качарга! Хәзер без шул турыда сөйләштек, активистларны үтермәскә булдык. Аны хәзер үк чыгарып җибәр, кая тели, шунда китсен. Теләсә, әнә иптәшләре янына өтерменгә барсын, – диде.

Торып, ишеккә юнәлдем. Ишек артымнан шапылдап ябылды. Яңадан төн уртасында урамда февраль салкынында калдым. Башыма бер уй килде: моннан ерак түгел генә авыл зираты. Шунда барып, үземә кул салырга кирәк. Палачлар кулына эләккәнче, шулай үлүең җиңелрәк булыр.

Таң сызыла башлады. Кабер ташы өстендә утырам. Елар идем дә күз яшьләрем калмады. Күлмәк итәгеннән берничә мәртәбә аерырга тырышып карадым, кыска кисәкләр генә ертыла...

Шулчак таш мәктәп каравылчысы һәм җыештыручысы Кәшшаф бабайны искә төшердем. Ул мине бик ярата, һәрчак җырлавымны сорый иде. Аның йорты зираттан ерак түгел. Әгәр кеше йөри башлаганчы барып җитсәм, куалап чыгармаслар. Почмак яктан сукыр лампа яктысы сирпелә бугай. Бөтен көчемне җыеп, үлемнән качып, урам аша шул йортка юнәлдем. Ишегалдына кереп, ишекне бик сак кына шакыдым. Ишеккә хатын-кыз килеп, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

– Кем анда? – дип сорады.

– Бу мин – Гасимә...

Ишек шунда ук ачылды. Яшь килен ипи пешерер өчен камыр баса икән.

– Кер, кер, апа, уз. Әнә мич башына менеп җылын. Әти булмаганда җылынырсың да абзарда яшеренерсең. Төнлә синең арттан чыгармын, – дип вәгъдә итте ул.

Кәшшаф бабай иртәнге намазга торганчы, мич башында утырдым. Бабайның карчыгы юк иде. Каенатасы торганчы, килене мине ташламады. Яхшы гына җылындым. Һәм менә ул: «Әти инде тора, Гасимә апа, Сез әлегә чыгыгыз, төнлә мин Сезне яңадан чакырырмын», – диде һәм ишекне ачып, мине чыгарды.

Ишегалдына чыкканда, урамда инде якты һәм кешеләр тавышы ишетелә иде. Амбарлар ягына узып, берәрсенең чормасына менәргә уйладым. Нииндидер баскыч табып, печәнлеккә мендем. Тәнемә каяндыр көч килүен тойдым. Күрәсең, исән калуыма өмет уянгандыр. Мин кергән амбар Кәшшаф бабайның күршесенеке – Хафиз абыйныкы булса кирәк. Ике арада бернинди киртә дә, койма да юк. Печәнлектә салам көлтәләре өелгән иде. Мин салам көлтәләре арасына яшеренергә тырышканда баскычтан ниндидер хатын-кыз сыерларга ашатыр өчен салам көлтәсе алырга менде. Мине күреп, ул кычкыра башлады: «Ә, коммунистка! Менә кайда яшеренгәнсең икән?! Хәзер төшәм дә әйтәм», – дип, аска ыргылды. Өч минут та узмагандыр, өскә ике ир күтәрелде. Сүгенә-сүгенә, алар мине аска сөйрәде. Ирләрнең берсе Хафиз абый иде. Ул мине яхшы белә: мәктәптә спектакльләр куйганда, безгә бераз булышкалаган иде. Ялгышканмын икән. Әлеге ирләр мине штабка китерде. Баш күтәрүчеләр башлыгы, кулымда бернинди кәгазь кисәге юклыгын күрсә дә, миннән документлар таләп итте. Аннары ул мине алып килүчеләргә: «Тегеләре янына илтегез!» – дип боерды. Сакчыларымның берсе, аркама сәнәк терәп: «Атла!» – дип кычкырды. Ярымүле хәлдә алар күрсәткән якка атладым. Менә Чыршылы башкарма комитеты бинасы, аның бер почмагында өтермән. Элек авылда төрле җинаятьчеләрне яба торган бинаны яки җәзалау бүлмәсен шулай атап йөрткәннәр. Сакта торган сәнәкле кеше өтерменгә илтүче капканы ачты. Озата килүчеләр мине шунда уздырып, аркама сәнәк сабы белән төрттеләр.

Анда бөрешеп утырган Гайшә, Зифа һәм Маһруй апа, мине күрүгә сикереп тордылар да, кочаклап, үксеп елый башладылар. Ә мин исә ярымүле хәлдә катып калдым. Елый алмадым. Ишек төбендәге сәнәкле сакчы, әшәке сүгенеп:

– Улавыгызны туктатыгыз, сезне бүген барыбер теге дөньяга озатачаклар! – дип җикеренде.

Без инде уйларлык хәлдә түгел, бер-беребезгә елышып утырабыз. Өтерманне тәрәзәдән кояш яктырта. Аның аша урамнан үтеп йөргән кешеләрне күрәбез. Шулчак ишекне саклаучы сәнәкле ир:

– Әнә киләләр, – диде.

Кем килә? Анысын аңламадык.

Сәнәк тоткан ике ир, бусага аша атлап кергәнче үк:

– Торыгыз, киттек! – дип кычкырды.

Бөрешеп утырган җиребездән тордык. Бер-беребезгә карашып алдык. Сөйләшерлек халәттә түгел идек.

Урамга алып чыккач, алдан, арттан һәм яннан дүрт сәнәкле ир озатуында, дүрт укытучы алга атладык. Кая барабыз? Шулчак каяндыр берничә хатын-кыз килеп чыкты. Алар безгә төкерә һәм:

– Оятсызлар, күрмәгәнегезне күрсәтерләр әле! – дип кычкыра башладылар. Ул хатыннар безне шулай таш мәктәпкә кадәр озата барды.

Мәктәп салкын, чөнки укулар юк, укытучылар кайсы-кая качып беткән. Идән уртасына бер өем салам аударылган. Безне салкын мәктәпкә бикләп, каравылларга ишек төбенә бер сәнәкле сакчы калдырып, китеп бардылар.

Көн уртасы. Мәктәп янына сәнәкле берничә ир килеп, кулларын ярсып болгап, безне кычкырып каһәрли башлады. Без аларны ишетмибез, кемнәр икәнен һәм кайдан килеп чыгуларын белмибез. Җәфаланып-интегеп ярымүле хәлгә килгәнгә, вакыйгаларны аңлар хәлдә түгелбез.

Аларны сәнәкле башка ирләр куып җибәрде.

Көн кичкә авышты. Ашарга беркем дә китерми. Ишек төбендәге сакчы янына вакыт-вакыт сәнәкле ирләр килеп китә.

Төн урталары. Сәнәкле крестьяннар сакчыга мәктәп ишеген ачарга боерды. Ишек ачылып, безгә йомшак, ягымлы тавыш белән: «Киттек, туганнар! Без сезне хәзер моннан алып чыгабыз», – дип эндәшкәч, үтерергә алып баралар, дип уйлап, кычкырып елый башладык.

Урамга чыккач безне, пышылдап кына сөйләшеп, Чыршылы авылының иң караңгы почмагына – бер-берсенә кара-каршы салынган, әби белән бабай яшәгән агач йортларга алып килделәр һәм капкасын шакыдылар. Капканы бабай ачты һәм йортларның кеше яшәмәгәненә кердек. Элегрәк анда уллары белән киленнәре торган икән. Уллары Гражданнар сугышына киткәч, килен әти-әнисе янына әйләнеп кайткан.

Өй ягылмаган. Сәнәкле кешеләр, ике кешене яныбызда калдырып, китеп барды. Әби белән бабай кайнар чәй алып килде. Азрак тынычландык шикелле, як-якка карана, сөйләшә башладык.

Төн узды. Иртән сәнәкле кешеләрнең берсе, Гайшә янына килеп, язулы кәгазь кисәге бирде. Анда: «Гайшә, борчылмагыз, тыныч булыгыз. Мин, сезне коткару өчен, баш күтәрүчеләрнең коменданты булырга алындым. Кызыл Армия частьлары Чыршылыга якынлаша. Без дә сездән безне коткаруыгызны сораячакбыз. Хуш. Синең Кәшифең», – дип язылган иде. Язуны бирүче шунда ук китеп барды. Гайшә, сөенмәсә дә, язуны һәрберебезгә укырга бирде.

Безне бер урыннан икенче урынга кеше күзеннән яшерү өчен күчерүләрен шулай соң гына аңладык шул.

Көн дә узды. Үзгәрешләр юк. Икенче көнне тәрәзәне бер төркем сәнәкле егет сырып алды. Ишекне ачуны таләп итәләр, әмма безне саклаучылар ишеккә якын китермиләр. Бу бәхәс барган арада сәнәкле һәм чалгылы берничә ир килеп, кычкырыштылар да китеп бардылар. Бернәрсә дә аңлый алмыйбыз, бүлмә чатлыкларына посып, елыйбыз. Шунда сәнәкле бер ир килеп: «Кайсыгыз Гасимә? Киттек, сине комендантка чакыралар!..» – диде. Торып, куркудан катып калдым. Дусларым, соңгы мәртәбә саубуллашып, кочаклый, үбә башладылар. Капкадан чыкканда минем белән йортның хуҗалары – әби белән бабай да кочаклап хушлашты.

Алар калды, ә мин сакчы озатуында киттем. Ул мине таш мәктәп янындагы кечкенә агач йортның икенче катына алып менде. Әлеге йортка керер алдыннан чанага җигелгән атны шәйләп калдым.

Мине комендантка керттеләр. Ул сөйкемле йөзле уртача буйлы 25-30 яшьләрдәге кеше иде. Аның безне коткарыр өчен комендант булырга алынган Кәшиф икәнлеген бу вакытта мин белмәдем.

Әлеге кеше алдына килеп баскач, ул, артында басып торган абзыйга: «Габдулла абый, менә бу укытучы Әлмәт кызы икән, – дип эндәште. – Әлмәт авылыннан бер кеше килеп, штабка 60 кеше кул куйган язу тапшырды. Әлмәтлеләр аны үз карамакларына тапшыруны сорый. Менә ул кәгазь. Чанага утыртып, илтеп куй. Кулдан-кулга тапшырганга расписка алырсың.

Габдулла абый мине ишегалдына алып чыгып:

– Менә бу чанага утыр, сеңлем, – диде.

Чанадагы саламга утыргач, кузгалып киттек. Күңелгә җылы керде: мин үз авылыма, туганнарым янына кайтам бит.

Атыбыз юыртып китте.Чыршылыны чыкканда Куакбаш авылы ягыннан ату тавышлары ишетелде. Габдулла абый:

– Әнә Кызыл Армия килә, алар ата, – диде. Шунда ук дусларым турында уйлап куйдым.

Шулай барганда, чуашлар яшәгән Бадрак авылы ягыннан атка атланган сәнәкле кешеләр якынлашуын күрдек.

– Тизрәк чанага сузылып ят! – диде Габдулла абый һәм яткач, өстемә чыпта япты.

Атлылар безнең янга килеп җиткәч, ул:

– Әй, туганнар, тизрәк! Тиздән Чыршылыга кызыллар киләчәк, тизрәк булышыгыз. Менә үземнең авыру карчыгымны Бадракка илтергә телим… – диде.

Алар, атларына камчы белән сыдырып, Чыршылыга чаптырып киттеләр.

Атлылардан котылгач, Габдулла абзый, чыптаны ачып:

– Ну, кызым, язмышыңа рәхмәтле бул, котылдык бит… – диде.

Менә Бадракка якынлаштык. Кечкенә генә чуаш авылы. Аның белән янәшә Миндубай авылы, ерактарак, ун чакрымда – Әлмәт. Әлмәттә һәм Миндубайда тыныч, анда халык баш күтәрмәгән. Ә менә Бадрак чуашлары сәнәкчеләргә кушылган. Алар күрше авыллардан ярдәм көтәләр.

Бадрак авылы кырына җитәргә дә өлгермәдек, чанабыз янына җилкәсенә сәнәк салган карт чуаш килеп басып, атның тезгенен эләктереп алды да:

– Комендантка киттек! Нинди хатын-кыз бу? Коммунисткамы? – дип кычкырды.

Ахыры бар ■

Безнең мирас №3 март 2018

ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ?

Илфар Габдрахманов,
Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек мәктәбенең тарих укытучысы, «Туган як тарихын өйрәнү» түгәрәге җитәкчесе

Татар тарихына алтын хәрефләр белән язарлык милләттәшебез турында галимә Тәэминә Биктимерова 2005 елда «Сөембикә» журналының октябрь ае санында язып чыккан иде. Аның «Садретдин хәзрәт һәм Мәүдүдә абыстай кыйссасы» исемле язмасында сүз, Санкт-Петербург шәһәрендә яшәп, мәгърифәтчелек белән шөгыльләнгән зыялыларыбыз турында бара.

Мәүдүдә абыстай балалары белән

Садретдин хәзрәт улы Фәйзияздан белән

Кечкенәдән сукыр калган Садретдин үз тырышлыгы аркасында белем ала, Петербург мәчетендә имам-хатыйп һәм мөдәррис булып эшли башлый. 25 яше тулгач, ягъни 1888 елда өйләнергә карар кыла. Ул вакытта димләп өйләндерү гадәте булганлыктан, Садретдингә дә дуслары кәләш табып бирә. Кәләш дигәннәре Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы олысының Югары Тегермәнлек авылында яшәүче Мәүдүдә була. 18 яшьлек гади авыл кызының үзеннән олы һәм шулвакытта дөм сукыр булган Петербург мулласына кияүгә чыгуы – батырлыкка бер мисалдыр. Авылдан чыгып киткән вакытта Мәүдүдә ниләр уйлады икән? Әтисе Бәһаветдин Хәсәнов (монда шуны әйтергә кирәк: 1901 елда Югары Тегермәнлек авлында икенче мәчет ачылгач, анда мулла итеп, Мәүдүдәнең энесе Габделгазиз куела, ә мәчетне төзетүче кеше Санкт-Петербург сәүдәгәре Хисаметдин Байсаров була. Монда зур рольне Садретдин мулла да уйнарга мөмкин. Ул хатынының авылында мәчет төзетер өчен бай сәүдәгәрне тапкан булырга мөмкин) – авылның бердәнбер мәчетендә мәзин вазыйфасын башкарган кеше, баласын ирексезләп кияүгә бирмәгәндер, күрәмсең, кызына кире уйларга да мөмкинлек калдырган. Ләкин яхшы тәрбия алган кыз бала: «Егетнең күңел күзе күрсә, миңа шул җиткән», – дип җавап биргән, имеш. Миңа моны соңрак Мәүдүдә әбинең Казанда яшәүче оныгы, филология фәннәре кандидаты Зөлфә ханым Усманова җентекләп, әбисенең фотоларын күрсәтә-күрсәтә сөйләде.

Россия империясе башкаласында яши башлауга ук, яңа төзелгән гаилә, иркен фатирга чыгып, балаларга белем бирүне кайгырта башлый. Садретдин хәзрәт малайларны укыткан булса, Мәүдүдә кызларга сабак бирә. Алар ачкан уку йорты пансионат тибындагы мәдрәсә буларак эшчәнлек алып бара. Монда, дин дәресләре укытудан тыш, дөньяви фәннәргә дә игътибар бирелә. Шулар арасында математика, астрономия, медицина һ.б. да бар. Бу мәдрәсә соңрак бөтен Петербургка танылa, анда шәһәрдәге һәм күрше-тирә яклардан килгән күпләгән яшьләр гыйлем ала. Хәреф тану, язарга өйрәнү, фәннәр белән танышудан тыш, укытучы абый-апалары шәкертләрне татар халкының гореф-гадәтләрен сакларга өнди, әхлакый тәрбия бирә. Мәдрәсәдә укып чыккан кешеләр соңрак үзләренең остазларын онытмый, аларның хәлләрен белеп тора, алай гына да түгел, авыр 30 нчы елларда Садретдин хәзрәтне төрмә юлыннан саклап кала. Күп кенә хезмәтләр авторы, олуг педагог Садретдиннең зур урында эшләгән шәкертләре изгелекне онытмый, аның гаиләсенә даими булышып тора. «Ни чәчсәң, шуны урырсың», дигән татар мәкален искә төшерергә була бу урында. Садретдин мулла 1935 елда үлеп

китә. Бәхетле тормышта яшәгәндер, дип уйлыйсы килә әлеге мөхтәрәм милләттәшебез турында. Иң беренче чиратта, бу аның тормыш иптәше белән бәйле.

Садретдин һәм Мәүдүдә гаиләсендә 11 бала туа. Ни кызганыч, аларның 5 баласы үлә. Ике уллары һәм дүрт кызлары исән-сау үсеп җитә. (Мәүдүдә әбинең Фәйзияздан исемле баласы белән бәйле батырлыгы турында алдарак язып үтәрмен. Бу урында исә Мәүдүдәнең сеңлесе Маһитап турында языйм әле). Балалары тугач, Мәүдүдәгә авыргарак туры килә башлый. Тормыш мәгънәсе итеп балаларга белем бирүне сайлаган ханымның үз сабыйларын карарга вакыты азая. Шул сәбәпледер инде, ул авылдан сеңлесен чакырта. 40 яше тулганчы, Маһитап апасына булыша. Ул да олуг җанлы кеше булып чыга. Кем үзенең шәхси тормышы бәрабәренә мондый адымга бара ала, әйтегез?! Шуның өчендер инде, аны язмыш кимсетми. Соң булса да, ул тормыш иптәше таба, күренекле мәгърифәтче Фатыйх Халидинең энесе, Казанның Зәңгәр мәчете имамы Ибраһим Халидигә кияүгә чыга. 5 ятим балага үги ана булып килү – үзе тагы бер батырлык мисалы. Иренең балаларын да Маһитап үзенекеләрне тәрбияләгән кебек якын итеп карый. Шулар арасында соңрак СССРның халык артисты исемен алуга ирешкән күренекле артист Фоат Халитов та була.

Мәүдүдә әбинең батырлыгына тукталыйк әле. Әйткәнемчә, Садретдин белән Мәүдүдәнең Фәйзияздан исемле уллары була. Үз ата-аналарында белем алганнан соң, Фәйзияздан Истанбулга укырга китә. Әтисе, сукыр булуга карамастан, аны бу шәһәргә кадәр озата бара. Атасының үз баласында өмете бик зур була, аңа дәвамчысы итеп карый. Ләкин...

1914 елда I Бөтендөнья сугышы башлана. Фәйзияздан хәрби хезмәткә алына, аны сугышка озаталар. 1917 елда кайгылы хәбәр килә. Улының үлемен ишеткән ана малаеның гәүдәсен алып кайту нияте белән юлга җыена. Нинди уйлар белән чыгып киткәндер батыр Ана, анысы безгә билгесез.

Күпме юл үткәндер Мәүдүдә ханым, бусы да безгә мәгълүм түгел. Ничек итсә итә, фронтка барып җитә Ана. Улы хезмәт иткән берләшмәне, аның командирларын эзләп табу ничек авыр булгандыр аңа. Ә Фәйзиязданның каберен эзләп табу һәм аның гәүдәсен казып алып Петербургка алып кайтырга рөхсәт алу өчен ничек гозерләнеп сорарга мөмкин. Ничек булса да була, рөхсәт алына. Алай гына да түгел, Фәйзиязданның командирлары каберләрне казырга булышу өчен ана кешегә ике солдат та бирә. Каберләр алтау булып чыга. Һәм һәрберсе – туганнар каберлеге. Беренчесен ачып җибәрүгә үк, Мәүдүдә аңын югалта. Һушына килгәч, догаларын укып, кабер казуны дәвам итә. Бары тик соңгы, алтынчы каберне барлаганда гына, аягындагы миңе буенча улын табуга ирешә ана. Шуннан соң, Фәйзияздан гәүдәсен Петербургка хәтле ничек алып кайтырга, дигән сорау килеп баса. Гәүдә юлда кайтканда таркалмасын өчен, берсе – агачтан, икенчесе цинктан эшләнгән табут кирәк булып чыга. Аларны кайдан юнәткәндер батыр Ана – билгесез. Мәетне товар вагонына урнаштырганнан соң, ай буе Петербургка кайта Мәүдүдә ханым. Алай гына да түгел әле, улы Фәйзиязданны бөтен мөселман тәртипләре белән җирләүгә ирешә. Кайсы хатын хәзерге көндә шулай булдыра алыр икән?! Әлегәчә мондый хәл турында ишеткәнем дә, күргәнем дә юк.

Нинди генә авыр, гыйбрәтле тормыш юлы үтсә дә, сынмый батыр Ана. Озак еллар буе балалары белән яши, аларга оныкларын тәрбияләргә булыша. Оныгы Зөлфә ханым хәзерге көнгә кадәр әбисе турында горурланып сөйли. Горурланырлык та шул!

«Бу гыйбрәтле язмыш белән таныштыруның максаты нинди иде соң?» – дигән сорау туар. Иң беренче чиратта, без батыр милләттәшләребезне белергә тиеш. Хәзерге балаларга тиешле тәрбия бирәсебез килсә, без моны милләтебез тарихыннан алынган, үрнәк итеп куярлык шәхесләр мисалында эшләргә бурычлыбыз, дип уйлыйм. Милли

Гөлгамбәр ханым ире Исмәгыйль Усмановны I Бөтендөнья сугышына озаткандa төшкән фото

үзаңны үстерүдә, патриотик тәрбия сеңдерүдә үрнәк булырдай олуг затлары бик күп татар халкының. Шуларның берсе – Югары Тегермәнлек кызы Мәүдүдә абыстай. Һәрбер авылның мондый шәхесе бардыр, дип уйлыйм. Аларны эзләп табарга гына кирәк.

Әлеге гыйбрәтле язмыш мисалында, без гади татар авылы булган Югары Тегермәнлектә нинди шәхесләр тәрбияләнгәнен күреп торабыз. Ә бу нәселнең тарихы ничек тәмамлана соң? Шуны белү ниятеннән, мин әлеге мәкаләдә искә алынган, Хәсәновлар нәселен дәвам итүчеләрнең берсе – Казанда яшәүче Зөлфә ханым Усманова янына юнәлдем. Аның белән сөйләшүдән мин шушыларны белдем: Баһаветдиннең 3 улы һәм 3 кызы була. Беренче кызы, әйтеп үткәнебезчә, Мәүдүдә. Олы кызы Гөлгамбәр исемле була. Санкт-Петербург шәһәрендә Мөселман кызлар мәктәбен бетергәч, рус гимназиясенә укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң, әти-әнисенең мәктәбендә үзе дә рус һәм француз телләреннән белем бирә. Садретдин белән Мәүдүдә ачкан мәктәптә шулай ук чит телләр дә укытылган икән. 1913 елда Россия империясе башкаласында яшәп яткан Гөлгамбәр Казанга килен булып төшә – табиб Исмәгыйль Усмановка кияүгә

чыга. Аларның очрашуы Петербургның атаклы Мариинский театрында була. Собинов иҗатын яраткан Исмәгыйль башкалага опера карарга килә. Ул үзенең туганнан-туган апасы Мәрьямбануның кызлары Фатимат һәм Нәфисәт белән бергә килә. (Монда әйтеп китәргә кирәк: бу ике туташның әтиләре Мөхәммәтшәфыйк Шамил – атаклы чечен имамы Шамилнең улы, ягъни Исмәгыйльнең апасы атаклы Шамилнең улына кияүгә чыккан була.)

Операга Нәфисәтнең ахирәт дусты Гөлгамбәр дә килгән була. Менә шунда Исмәгыйльнең күзе төшә дә инде бу Петербург чибәренә. Соңрак ул аның үзенә кияүгә чыгуын сорый. Кыз, яшь аермасы 18 ел булса да, ризалык бирә һәм алар матур гына тормыш корып җибәрә. Бик бәхетле тормыш итәләр. Беренче балалары Рәдифә туган вакытта Исмәгыйль I Бөтендөнья сугышында була. Гөлгамбәр ханым, ике яшьлек сабыен күтәреп, ире янына ашкына, аның янына барып, шәфкать туташы булып эшли. Кызлары Рәдифә соңрак үзе дә табиб һөнәрен сайлый.

1917 елда туган икенче балалары Тәминдар Бөек Ватан сугышында һәлак була. Өченче балалары – Зөлфә ханым. Казан дәүләт университетын татар теле һәм әдәбияты белгечлеге буенча тәмамлый ул. Аспирантурада укый. Педагогия фәннәре кандидаты. Педагогия һәм мәдәният институтларында студентларга белем бирә. Ире Булат Гыйззәтуллин – үзе кебек үк филолог – узган гасырның 60-70 нче елларында Татарстан мәдәният министры була. Гөлгамбәр һәм Исмәгыйльнең төпчек балалары Назыймдар, химия-технология институтын тәмамлап, инженер булып эшли.

Исмәгыйль абый 1944 елга кадәр яши, ә Гөлгамбәр иреннән соң тагы 39 ел гомер итә.

Соңрак, XX гасыр ахырында «Сөембикә» журналында атаклы татар язучысы Гаяз Исхакыйның бер төркем татарлар белән төшкән фотосы басыла. Шулар арасында Зөлфә ханым үзенең әнисен дә таный, ягъни Гөлгамбәр бу бөек шәхес белән дә якыннан аралашкан булып чыга.

Сугыш башланган 1941 елда Гөлгамбәрнең әнисе Мәүдүдә дә үлеп китә. Мәүдүдә белән Садретдиннең (ул 1935 елда вафат була) тагы Гөлбәһиҗә исемле, янә Гөләндам һәм Гөлирам исемле игезәк кызлары була. Төпчек балалары Лотфелмөгыйн Бөек Ватан сугышы кырында ятып кала.

Бу – безнең авылда озак еллар буе мәзин булып торган Баһаветдиннең кызы Мәүдүдәнең язмышы, тарихы. Баһаветдиннең улы Габделгазиз, Советлар хакимияте урнашкач, гаиләсе белән Урта Азиягә китәргә мәҗбүр була. Икенче улы Габделхәким авылда кала. Аның бер улы Мөгыйн Бөек Ватан сугышыннан офицер дәрәҗәсе алып кайта, озак еллар буе авылда яшәп, кибеттә эшли. Икенче улы Рәшит Казанда гомер итә. Габделхәкимнең кызы Әминәтелниса авылда яши.

Хәзерге вакытта өчесе дә мәрхүм инде. Кызганыч ки, аларның нәселләрен дәвам иттерүчеләр дә юк. Баһаветдиннең өченче улы Габделхәй дә, читтә яшәп, шунда үлеп, шунда җирләнә. Язып үткәнемчә, Баһаветдиннең икенче кызы Маһитап, апасы кияүгә чыгып балалар тапкач, аңа булышу ниятеннән Санкт-Петербург шәһәренә килә. Соңрак, 40 яшендә татарның атаклы артисты Фоат Халитовның атасы Ибраһим муллага кияүгә чыга, ягъни Фоатның үги әнисе була. Баһаветдиннең өченче кызы исә Хәтимә исемле. Ул Заһир исемле дин әһеленә кияүгә чыга. Аларның Зәйтүнә исемле кызлары соңрак машинистка булып эшли, ике уллары Галимҗан һәм Әхмәтҗан очучы була, Шәрифҗан математика фәннәре докторы дәрәҗәсен алуга ирешә. ■

Безнең мирас №3 март 2018

Каюм Насыйри хатлары

Каюм Насыйри портреты. 2001 ел.
Зөфәр Гыймаев рәсеме

Мәдәни милләтләр, үзләре арасыннан чыккан бөек кешеләрне якынрак таныр өчен, анларның гомум өчен язган әсәрләрене генә тәдкыйк кыйлыб[1], канәгатьләнә алмыйлар. Анлар үзләренең даһиларының кулына кереп чыккан һәрбер кәгазь кисәгене тикшерәләр, хатларыны, көндәлек дәфтәрләрене актаралар, җыялар. Мөмкин кадәр үзләренең даһиларыны аңларга, аның тормышының гали фикерләренең серләрен чишәргә чалышалар[2], күп вакытта буңарга ирешәләр дә.

Шуның өчен Яурупа әдәбиятында ничә йөз битләр калынлыгында булып та, фәкать бер шагыйрь вә философның хатларындан вак-төяк кәгазьгә язылып ташланган язуларындан гыйбарәт булган әсәрләр очрату гаҗәб түгел.

Бу гына аз, анлар шул кулъязмалардан меңәр нөсхә булса да, гомумийә хас, шуның өчен генә салынган музейларда саклыйлар.

Бездә эшләр бераз башкачарак. Бу көнгәчә килеп киткән бер-өч «бөек кешеләремез»нең түгел хатлары, башка мөһимрәк әсәрләре дә дөнья йөзе күрә алмыйлар. Кайсылары дөнья йөзене күрсәләр дә, дөнья йөзе анларны күрә алмый[3].

Андый әсәрләрнең күбесе чормаларда, сандыкларда, китап шүрлекләрендә тузан арасында онытылып яталар.

Түбәндә укучыларга тәкъдим итәчәк хатларны да мин бер авылда чормада кәрзинкәдә таптым. Ул кәрзинкәдә Каюм Насыйриның каләме белән язылган хатлар күп булса да, мин анларыны, белмим, мөндәриҗәләре[4] бертөрлегә күрә, белмим, башка берәр сәбәптән – сигезен генә алдым. Анлар һәммәсе Насыйриның атасына язган хатлары, мөндәриҗәләре көндәге тормышка гаид[5] нәрсәләр. Насыйри ул хатларның һәммәсендә

---

[1] Тәдкыйк кылып – нечкәләп тикшереп.
[2] Чишәргә чалышалар – чишәргә тырышалар.
[3] Каюм Насыйри әсәрләре наширләренең сәләхиятсезлеге аркасында халык арасында кирәгенчә тарала алмыйлар. Анларның соры ташлары юньләб төзәтелмәгән, эчләре хәзерге вакытларда чыга торган ялтыраб тора торган китаблар арасында бөтенләй югалалар *(Ш.Алкин иск.)*.
[4] Мөндәриҗәләре – эчтәлекләре.
[5] Тормышка гаид – тормышка караган.





«Аң» журналының тәүге саны (№1, 1912 ел)

дә диярлек ашчы малай өйрәтүнең читенлегене, үзенең мадди кысынкылыгы, үзенең айга унөч сум жалуниясенең йитмәгәнлегене яза. Арасында Насыйриның халәт-рухына даир урынлары да очрый. Һәр ничек бу хатларда безне канәгатьләндерерлек нәрсә булмаса да, Насыйриның тәрҗемәи хәлене якынрак беләсе килә торган кешеләр өчен файдасы тияр өмиде белән, бу урында иске мөхәрриремезнең берәр хатын укучыларга тәкъдим итәмез.

Ш.Алкин

НАСЫЙРИНЫҢ ҮЗ ИМЛЯСЫ

1

Гыйззәтле әткәмез вә әнкәмезгә вә барчаңызга күб сәламләремез бәгъдендә[6], үземез сәламәтмез. Көнһ[7], малай чибәр генә торыб торадыр, ләкин озаклык булмаганда, ай саен малай өйрәтергә кирәк. Бөтен гомер малай өйрәтүдән бушамассың, малайсыз торырга өйрәнгән идем, килмәсә дә, яраган булыр иде. Мондан әлек дә шулай зарланыб, ягъни малай өйрәтү хосусында язган идем, гаҗәб, минем сүзем әсәр кыйлмай сезгә. Язасыз, запаслы булыб тор, диб. Кайдан запаслы булыйм. Биш йөз сум акчаны өч йөз алтмыш көнгә тәкъсим кылсаң[8] – ни каладыр. Бер ай ач тормак кирәк яки бурыч итмәк кирәк – икесе дә минем кулдан килә торган түгел. Белмәйсез, сезнең игътикад[9] әллә ничек, әллә гөман кыйласыз[10], җыелган акча бар диб. Ай саен бер тәңкә бирергә мөмкин (берәр сүз җыртылган) ...лы миңа ярамый билкөллиә[11] бөлеб калам. Малайны йибәрдеңез тигүн диб, ике тәңкә сорайлар. Бер тәңкәгә сөйләшеб алыб калдым. Әмма өйрәнсә, йибәрергә янә ярамый. Тора торган кеше торыр бер тәнкә булса да. Монда да табылачак иде елга биш тәңкәгә табарга мөмкин,

[6] Бәгъдендә – соңында.
[7] Көнһ – асылда.
[8] Тәкъсим кылсаң – бүлсәң.
[9] Игътикад – ышаныч.
[10] Гөман кыйласыз – уйлыйсыз.
[11] Билкөллиә – бөтенләй.



Кече Шырдан авылында (Яшел Үзән районы) К.Насыйри кайтып йөргән йорт. XX йөз башы

бәлки кимрәк иманасын түләсәң, малай күб, бу малайны мокыт диденкез сүз күб, никадәр күб булса да, минем сүзләр әсәрле түгел, сезнең игътикадыңызча, хәер Аллага табшырдык.

Каюм

1857.

2

Бик ыскушно, белмәймен мин, ничек дөньяны уздыргаларга кирәк. Гомер тизрәк бетсә иде. Бертөрле кеше булса, әллә-ни эшләр кылыр иде. Аллага шөкер, мин Әюб г.в.с.нең энесе, ягъни сабыр. Нух г.в.с.нең энесе булуб, Сөләйман пәйгамбәрнең энесе булсаң иде. Шул өч кешенең энесе булмасаң, дөньяда торырга бер дә ярамый.

Каюм

Аң. – 1912. – №1.

Ә. Хәсәни

«Аң» журналы нәшире Әхмәтгәрәй Хәсәни турында белешмә:

Әхмәтгәрәй Сибагатулла улы Хәсәни – татар нәшире, тәрҗемәче, меценат. 1883 елның 15 декабрендә хәзерге Әтнә районы Түбән Көек авылында, сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Ә.Хәсәни, хатыны Зәйнәп белән бергә, 1912-1918 елларда XX гасыр татар матбугатының иң яхшы, матур бизәлешле «Аң» журналын чыгара. Ә.Хәсәни – шәхес культы корбаны: аны Ак диңгез-Балтыйк каналы төзелешенә эшкә җибәрәләр. Әлеге төзелештән срогын тутырып кайтканда, юлда тиф белән авырып, 1934 елда вафат була. Свердловск (хәзерге Екатеринбург) шәһәрендә күмелә. Кабере билгесез.

Кереш сүз авторы Ш.Алкин турында белешмә:

Шәйхулла Сибгатулла улы Алкин – язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1893 елның 15 августында Казан губернасы Зөя өязе Иске Чәчкаб авылында крәстиән гаиләсендә дөньяга килә. Иҗат эшчәнлеге 1913 елларда башлана. «Ил» газетасында иҗтимагый эчтәлекле мәкаләләре белән катнаша. Балалар әдәбиятына нисбәтле әсәрләре «Ак юл» журналының 1914 елгы саннарында теркәлеп калган. 1922 елның 7 февралендә Галимҗан Ибраһимов «Татарстан хәбәрләре» газетасында Ш.Алкинның Оренбург шәһәрендә үз-үзен атып үтерүе турында хәбәр урнаштыра. ■

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН ҮРНӘКЛӘР

СӨРГЕН ШАГЫЙРЕ

Сәхифәне Ләбиб Лерон алып бара.

Калмык халык шагыйре (1969), СССР Дәүләт премиясе лауреаты (1976), Социалистик Хезмәт Каһарманы (1990) Давыт Көгелтдинов 1922 елның 13 мартында җитешле гаиләдә туа. 1931 елда Көгелтдиновлар гаиләсен Алтайга сөрәләр.

Тәүге шигыре басылганда булачак шагыйрьгә 12 яшь була. 18 яшендә Язучылар берлегенә кабул ителә. «Яшьлек шигырьләре» дигән беренче китабы 1940 елда дөнья күрә. Әлеге китапка совет язучысы Александр Фадеев уңай бәя бирә.

Калмык педагогия институтының икенче курсында укыган вакытта Кызыл Армия сафларына алына. Сугыш башланугa, фронтка китә. 1944 елның маенда фронттан чакыртып кайтартыла һәм депортациягә дучар ителгән халкы белән бергә туган иленнән Себергә сөрелә. Бийск шәһәренең автомобиль техникумында мөгаллимлек итә. 1945 елның апрелендә калмык халкын яклап ясаган чыгышы һәм шигырьләре өчен кулга алына, хөкем ителеп, Норильскига озатыла.

Д.Көгелтдинов 1956 елның ахырында гына газиз Ватанына кабат кайту бәхетенә ирешә.

2006 елның 17 июнендә вафат була һәм Элистаның Беренче зиратында җирләнә.

Давыт Көгелтдинов Габдулла Тукай турында

«...Тукай 27 яшендә үлә. Шушы кыска иҗат гомерендә аның шулкадәр теманы, глобаль проблемаларны колачлый алуына ышанасы килми хәтта.

Тукайның бөеклеге аның үз вакытында мәсьәләне күтәрә белүендә генә түгел, ә бәлки шул мәсьәләне үз вакытында чишә алуында да.

(Чыганак: Тукай... Дөнья халыклары Тукай турында / Төз. Р.Акъегет. – Казан: Татар. кит нәшр., 2006. – 222 б.)

Давыт Көгелтдинов шигырьләре

ЙӨРӘГЕМӘ

...Әгәр дә син бер мизгелгә
Халыктан йөз чөерсәң,
Һәрбер ялганга ышанып,
Бәйрәм итсәң, сөенсәң,
Ул чакта сине умырып
Күкрәгемнән алырмын,
Һәм ант итәм, курыкмыйча,
Көчекләргә салырмын.

КӨТӘМ СИНЕ

Көтәм сине...
Чатнама җил берөзлексез
Өтә битне...
Көтәм сине...
Кар шыгырдый –
Үчекләгән кебек мине...
Көтәм сине... Көтәм сине...
Көтәм сине...

Зәһәр суык,
Ап-ак бәсләр сибеп,
Керфекләрне
Боз итте күптән...
Сине көтәм...

Юк, суыктан калтыранмыйм –
Өшим, туңам, димим...
Бары
Син килмәссең, дигән уйдан
Дерелдимен...

ШАГЫЙРЬ ҮЛЕМЕ ХАКЫНДА

Шагыйрь үлеме хакында
Кайберәүләр язды:
«Китте шагыйрь... Күпме җыры
Тәмамланмый калды...»

Юк, бу һич тә алай түгел!
Дөрес түгел бер дә:
Болай язган кеше, әйе,
Моны каян белә?

«Китте... Тәмамланмый
калды...» –
Алай түгел, түгел!
Шагыйрь җырын тәмамлады
Соңгы көчен түгеп!

Китте, әйтеп китте сүзен
Бакый дөньяга ул.
Әйтәлмәгән икән, димәк,
Шагыйрь булмаган ул...

МИН КУРЫКМЫЙМ ҮЛЕМНӘН

Мин курыкмыйм үлемнән,
Үземне
Янә бер кат сынармын:
Кабат күрер өчен бу җиһанны,
Агач булып шытып чыгармын.

Бәлки кошка әверелермен дә
Мин сайрармын иртә-кичләрен...
Тик куркамын бары бернәрсәдән:
Дусны очратсам, нишләрмен?

Ничек аңа эндәшермен икән –
Кеше кебек сөйләшермен микән?!

Л.Лерон тәрҗемәсе. ■

Безнең мирас №3 март 2018

ТАТАР КАЙДА ДА ТАТАР...

Татар халкының телен, гореф-гадәтләрен, әдәби-мәдәни мирасын саклаучы һәм пропагандалаучы үзәкләр белән таныштыруны дәвам итәбез. Бу язмабыз Казан (Идел буе) федераль университетының Лев Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты составында эшләп килүче Габдулла Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология Югары мәктәбе турында. Без аның җитәкчесе, филология фәннәре докторы, профессор ***Әлфия Шәүкәт кызы Юсупова*** *белән очрашып, ул сөйләгәннәрне язып алдык.*

«ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ ДӘВАМ ИТЕП, ЗАМАНЧА ЭШЛИБЕЗ»

Г.Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология мәктәбенең төп максаты – татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле белгечләр әзерләү. Хәзерге көндә 700дән артык студент татар теле һәм әдәбияты буенча һөнәри белем ала. Болар арасында көндезге һәм читтән торып уку бүлекләрендә бакалавр, магистратура һәм

аспирантура программалары буенча укучылар да бар. Югары уку йорты укытучысы элек-электән, мөгаллимлек эше белән бергә, үз фәнни юнәлешен дә үстергән. Мәгълүм булганча, татар тел белеменең барлык нигез тармакларына да Казан дәүләт университеты һәм Казан педагогика институты укытучылары зур өлеш керткән. Хәзерге вакытта бу традицияне Казан федераль университеты галимнәре дәвам итә. Безнең институтта татар тел белеменә бәйле берничә фәнни мәктәп эшләп килә. Шуларның берсе – «Татар лингвокультурология фәнни мәктәбе». Җитәкчесе – филология фәннәре докторы, профессор Рәдиф Җамалетдинов. Аның шәкертләре татар менталитетының телдә чагылышы мәсьәләсен өйрәнә. Мәсәлән: татарның акылы телдә ничек чагылыш таба? Андагы галимнәр шул юнәлештә фәнни хезмәтләр яза. Икенчесе – «Татар ономастикасы фәнни мәктәбе». Аңа атаклы галим Гомәр Саттаров нигез салды. Хәзерге көндә ул университетта эшләмәсә дә, аның эшен укучысы, татар тел белеме кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы, профессор Гөлшат Галиуллина дәвам итә. Бу юнәлештә Гөлфия Һадиева һәм Халисә Кузьминаларның да хезмәте күп. Алар җитәкчелегендә күп санлы студентлар фәнни эшләр яза. «Тел тарихы мәктәбе»нең чишмә башында Латыйф Җәләйләр торса да, соңрак бу юнәлешне университет профессорлары Вахит ага Хаков, Фәһимә апа Хисамовалар җитәкли. Хәзерге вакытта аларның эшен Фәнүзә Нуриева һәм аның күп санлы шәкертләре дәвам итә. Дүртенче фәнни юнәлеш – «Татар лингвометодика мәктәбе». Флера Сафиуллина мәктәбе – татар теленең барлык юнәлешләрен дә диярлек колачлаган гыйлем дәрьясы. Хәзерге заман кадагына суга торган төп проблема – татар телен яңа методика белән башка милләт балаларына яки татарча белмәгән ул һәм кызларыбызга өйрәтү. Без, Флера апа Сафиуллина методикасына нигезләнеп, аны Европа үрнәгендә яңартып, яңа концепцияләр, программалар, дәреслекләр, кулланмалар язабыз. Бу мәктәптә мөхтәрәм галимәбезнең шәкертләре хезмәт куя.

Г.Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология мәктәбенең укытучылары, традицион фәнни юнәлешләрне дәвам итеп, эшне заманча фән һәм яңа методик югарылыкта алып бара. Укытучыларыбыз язган фәнни хезмәтләр, монография, дәреслекләр даими басыла. Быел гына «Татар теленең этномәдәни сүзлеге»нең өченче томы басылып чыкты. Бу – лингвокультурология мәктәбенең бер казанышы. Бик кызыклы сүзлек һәм андагы һәр тел материалы инглиз теленә дә тәрҗемә ителде.

Әдәбият белеме юнәлешендә Хатыйп Миңнегулов, Фоат Галимуллин, Флера Сәйфуллина, Ләйлә Минһаҗева, Таһир Гыйләҗев һәм Миләүшә Хәбетдиноваларның фәнни мәкаләләре һәрдаим чыгып тора. **Аларның бер өлеше «Безнең мирас» журналында да басылып килде.**

«ТАТАР ГАЛИМНӘРЕ БЕЛӘН БӨТЕН ТӨРКИ ДӨНЬЯДА КЫЗЫКСЫНУ ЗУР»

Телләрне үстерү һәм саклау юнәлешендә ел саен берничә халыкара конференция үткәрәбез. Узган елның октябрь аенда «Телләр һәм мәдәниятләр халыкара саммиты»узды. Анда туган телләрне саклау мәсьәләсе күтәрелде. Февраль аенда «Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар» исемле студентлар һәм аспирантларның IX нчы Халыкара фәнни-гамәли конеференциясе узачак.

Бу елның апрель аенда булачак конференция «Дөнья тюркологиясе һәм Казан университеты» дип атала. Аның кысаларында хәзерге заман тюркология фәнендәге алдынгы технология һәм фикерләр, традицион мәсьәләләр, аларга яңача караш тикшереләчәк. Фәнни чараның тагын бер үзенчәлекле һәм бик тә кирәкле ягы: 2018 елда юбилей даталары булган мөхтәрәм галимнәребезнең тормыш юлы, иҗаты һәм фәнни эшчәнлеге турында аерым секцияләр дә эшләячәк. Быел мөхтәрәм остазларыбыз Хатип Госманның

туууына – 110, Ибраһим Нуруллинның тууына – 95, Алмазия Нуриеваның тууына 90 ел, исән булса, Флера Сафиуллинага 80 яшь тулган булыр иде. Безнең арабызда армыйталмый фәнгә хезмәт итүче галимнәребез – озак еллар пединститут ректоры булган, татар тел гыйлеменең аксакалы Мирфатыйх Зәкиевкә – 90, шулай ук әлеге пединститутны җитәкләгән Рүзәл Йосыпов белән Алабуга педагогия институтының ректоры булып эшләгән Тәлгать Галиуллинга 80 яшь тула. Конференциянең аерым секцияләре шушы галимнәребезнең фәнни эшчәнлеген тулысынча колачлар, дип өметләнәбез. Шунысы шатландыра: татар галимнәренең фәнни-гамәли эшчәнлеге белән бөтен төрки дөньяда кызыксыну зур.

Безгә Төркиянең кайбер югары уку йортларыннан да уртак конференцияләр уздыру турында эшлекле тәкъдимнәр белән чыгалар. Гамәлгә аша калса, киләчәктә бер конференция төрки сәнгать, тарих һәм фольклор мәсьәләләренә багышланачак. Алдарак әйтеп үтелгән конференцияләрдә татар галимнәре генә түгел, Төркия һәм башка төрки дәүләтләрдән килгән галимнәр дә үзләренең фәнни казанышлары белән уртаклашыр, дип уйлыйм. Мондый халыкара чаралар уздыру Габдулла Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбенең дөньякүләм дәрәҗәсе турында сөйли.

Соңгы елларда Югары мәктәп укытучылары тарафыннан Каюм Насыйри институты, Татар теле буенча халыкара сертификация үзәге, татар теленә өйрәтүнең «Ана теле» онлайн-мәктәбе, кызыксынучылар өчен бушлай һәм түләүле татар теле курслары, «Ашыгыч лингвистик ярдәм» проектлары уңышлы эшли. Өч телдә заманча фәнни стандартларга җавап биргән «Tatarica» фәнни журналы даими басыла. Журналның халыкара редакция шурасы составына бар төрки дөньяга танылган югары академик репутацияле галимнәр керде. Бу чараларның күбесе Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында башкарыла.

«БЕЗ ҺӘР ҖӘҺӘТТӘН ЭШКӘ КЕРЕШЕРГӘ ӘЗЕР»

Үткән елның май аенда татар телен укытуның яңа концепциясе эшләнеп кабул ителгән иде. Анда телне туган тел һәм дәүләт теле буларак укыту каралган. Татар телен белмәгәннәр өчен Европа үрнәгендә баскычлап укыту ысулын тәкъдим иттек: А1, А2 һәм В1, В2 дәрәҗәләре. 9 классны тәмамлаганда рус телле бала В1 дәрәҗәсендә белем алып, татар телендә иркен аралаша белергә тиеш. В2 дәрәҗәсе исә татар мәктәпләрендә укучы балалар өчен. Әмма узган ел азагындагы милли телләрне укыту белән бәйле вазгыять безнең бу концепциягә үзгәрешләр кертә, чөнки мәктәпләрдә татар телен укыту сәгатьләре шактый кимеде. Алга таба министрлык тарафыннан телне укыту буенча расланган күрсәтмә булса, дәреслекләр төзү, укытучыларның белемен күтәрү юнәлешендә, методик яктан, гомумән, без һәр җәһәттән эшкә керешергә әзер.

«ЧИТ ИЛ СТУДЕНТЛАРЫ ТАТАР ТЕЛЕНӘ КАРАШНЫ КИҢӘЙТӘ»

Габдулла Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбенә чит илләрдән һәм Башкортстан, Чуашстан, Мари-Эль республикаларыннан, Оренбург өлкәсеннән дә килеп укучы студентларыбыз бар. Чит илдән килгәннәр өчен бик кызыклы магистратура программасы эшли. Ул «Мәдәниятара багланышларда төрки телләр» дип атала. Бу программа буенча укырга Казакъстан, Үзбәкстан,Төркия һәм Кытайдан ел саен киләләр.

Бөтендөнья татар конгрессы белән оештырган уртак проект – Кытайда яшәүче

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм КФУның Л.Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов.

татарларның балаларына Татарстан югары уку йортында белем алу мөмкинлеге. Хәзерге вакытта әлеге программа кысасында унлап студент, магистр, аспирант татар теле һәм әдәбияты юнәлешендә гыйлем эсти, өч студент дизайн-сәнгать юнәлешендә укый. Элегерәк тәмамлап чыккан студентларыбыз да бар*.

Бу студентларның Казанга килеп укуы шуның белән дә әһәмиятле: алар безнең, Татарстан студентларының татар теленә карашын киңәйтә. Студентларыбыз татар теленең чит илләрдә дә кирәк икәнлегенә инана.

«ХЫЯЛЫМ – ФИНЛЯНДИЯ ТАТАРЛАРЫ ТУРЫНДА КИТАП ЯЗУ»

Кытай студентлары белән аралаша башлагач, үзем дә кытай татарларының теле, фольклоры белән кызыксындым. Биш КФУ мөгаллиме шунда фәнни экспедиция оештырып, Өремче, Голҗа татарлары белән очрашып, фольклор һәм тел материаллары туплап кайттык. Шуның нигезендә 2014 елда «Кытайда яшәүче татарлар: тел һәм фольклор» дигән китап та чыгардык. Әмма кытайдагы татарларның тел һәм фольклор мирасы бер китап белән генә чикләнергә тиеш түгел. Ике йөз ел буе Кытайда яшәп, алар XXI гасырга кадәр милли үзенчәлекләрне, телне саклап калган икән, бу халык берничә том китапка лаек. Анда милли вазгыять шактый үзенчәлекле. Финляндиядән аермалы буларак, Төркия белән Кытайда татар телен саклап калуы шактый авыр. Төркиядә шул ук төрки тел, ә Кытайда уйгырлар күпләп яши һәм ассимиляция процессы тизрәк барырга тиеш кебек. Финляндиядә, урамга чыккач, тел башка, ул анда «консервланган», милли үзенчәлекләрне дә саклавы җиңелрәк. Кытай татарлары белән аралаша торгач, аларның теле уйгырлашкан сыман тоела. Әмма тел тарихын белгән кеше яхшы аңлый:

[1] 2015 елда редакциябездә «Кытай татарлары: мәдәният, тарих һәм хәзерге заман» дип исемләнгән «түгәрәк өстәл» оештырган идек. Аның тулы тексты һәм аудиоязмасы белән http://beznenmiras.ru сайтында танышырга мөмкин.

без татар теленә гарәп-фарсыдан, урыс яки Европадан алган алынмаларның аларда борынгы төрки, архаик формасы саклана.

Традиция буенча, фольклор экспедицияләрен оештыру дәвам итә. Аннан алып кайткан материаллар нигезендә, 2015 елда «Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары» исемле китап дөнья күрде. Анда Мордовия Республикасының Ләмберә һәм Пенза өлкәсенең Каменка районнарында яшәүче татар-мишәрләрнең гореф-гадәтләрен, халык иҗатын, тормыш-көнкүрешен чагылдырган материаллар һәм шул төбәкләрне өйрәнгән фәнни мәкаләләр җыелмасы бирелде. 2016 елда «Чуашстан Республикасы татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары» исемле фәнни хезмәт басылып чыкты.

Мәшһүр галимебез Фәрит ага Йосыпов Себерне – Курган һәм Новосибирск өлкәләрен, бараба татарларын өйрәнү белән шөгыльләнде. Аның хезмәтләрен «Безнең мирас»ны укучылар яхшы беләдер, дип уйлыйм.

Хыялым – Финляндиягә барып, андагы милләттәшләребезнең телен өйрәнеп, зур фәнни хезмәт язу. Дөрес, фин татарлары теле буенча Язгөлем Әхмәтованың саллы китабы бар, әмма ул 1990 еллар башында язылган. Бу вакыттагы тел белән хәзергесе арасында аз булса да аерма бар, белүегезчә, беренчедән, тел даими үсеп-үзгәреп тора, икенчедән, XXI гасырдагы техник мөмкинлекләребез күпкә зуррак. Фин татарлары үзләре дә моның белән бик кызыксына. Кытай татарлары турында китап чыккач, башка диаспора вәкилләре дә, безнең турыда китап языгыз әле, дип мөрәҗәгать итте. Киләчәктә бу проектлар гамәлгә ашар, әмма болар өчен финанс мөмкинлеге кирәк. Кытай татарлары турындагы китабыбыз исә, Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнехановның матди ярдәме белән басылып чыккан иде.

«ӘЛЛҮКИ» – УНИВЕРСИТЕТНЫҢ ГОРУРЛЫГЫ

Югары мәктәп нигезендә «Мизгел» студентлар театры эшли. Аны озак еллар ТРның халык, РФнең атказанган артисты Марсель Җаббаров җитәкләде. Бүген аның эшен үзебезнең укытучылар дәвам итә. Филолог кызлардан гына торган «Яшьлек» бию ансамблебез бар. Аны татар тел гыйлеме кафедрасы доценты Дамир Хәйдәр улы Хөснетдинов җитәкли. Дамирә Гайнетдинова җитәкчелегендә хореограф кызлардан торган «Казаным» ансамбле республикабыз һәм Россия күләмендә зур уңышларга иреште. «Ал Зәйнәбем», «Бәйрәм» вокаль ансамбльләре яхшы гына чыгышлар ясый. Дөрес, КВН командасы соңгы елларда сүлпәнәйде, әмма ул яңа көчләр белән үсеп китәр, дип өметләнәм.

«Әллүки»– университетның горурлыгы. 1944 елдан килгән бай тарихлы әдәби берләшмәгә иҗади яшьләр бүген дә килә. Аны язучы, татар тел белеме кафедрасы доценты Халисә Ширмән җитәкли. Татар әдәбияты мәйданына чыккан яшь язучыларыбызның 90 проценты – «Әллүки»дән үсеп чыккан егет һәм кызлар: Йолдыз Миңнуллина, Ленар Шәех, Эльвира Һадиева, Рөстәм Галиуллин, Рүзәл Мөхәммәтшин, Лилия Гыйбадуллина... Болар – безнең талантлы укучыларыбыз.

PS. Әлфия Шәүкәт кызы, милләттәшләребез һәм төрки кардәшләребезгә мөрәҗәгать итеп, Габдулла Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология Югары мәктәбенә укырга чакыра. Белгечлекләр: бакалавриат юнәлеше – «Татар теле, әдәбияты һәм чит тел (инглиз, төрек)». Филология юнәлеше – «Татар теле, әдәбияты һәм журналистика». Магистратура – «Татар теле, әдәбияты: заманча теория һәм технологияләр», «Мәдәниятара бәйләнешләрдә төрки телләр: әдәбият һәм мәдәният».

*Текстны журналга **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №3 март 2018

БЕЗНЕҢ ЗАМАН КАҺАРМАНЫ

Рабит Батулла

Мин гашыйкмын авыл иртәсендә
Көтү чыккач куптан тавышка;
Дулкынланам: казлар канат какса,
Атлар чапкан чакта ярышта.
Вахит Галиев

Иске Комазан – күп урамлы, ике мәхәлләле (ике мәчетле), мәктәпле авыл. Олы Урам, Мырзалар очы, Югары оч һәм тагын берничә кыска урам Иске Комазан авылын тәшкил итә.

Авыл яныннан гына олы юл уза, ташлы юл: элгәре елларда авылга кергәндә дә, чыкканда да юлчыларны кара багана каршы ала, озатып кала торган була. Гыйсъянчы татар авылларының күбесе кара баганалы булган, дип сөйлиләр, бу авылга кергәндә сак булыгыз, монда бик усал кешеләр яши: үрәтникләр, становойлар, зимләмирләр бу авылга керсә, исән чыга алмаган, эзләрен дә таба алмаганнар. Кансыз, гаделсез, залим зимләмирне кем үтергәнен дә белгән халык, ләкин дәшмәгән. Кешеләр бер-берсен сатмаган.

Мәчетләрне жимерү ***шаукымы чорында*** да Иске Комазандагы халык мәчет манараларын кистермичә саклап калган.

Манара саклауны оештыручы кеше безнең язмабыз каһарманы Вахитның атасы Миңлевәли Галиев булыр. Пулемёттан шатыр-шотыр атып, мәчетләрне җимерер өчен үзләре белән алып килгән берничә урыс мужигын калдырып, алласызлар китеп бара. Мужиклар, манараны кайсы якка аударырга, дип торганда, атаклы балта остасы Миңлевәли Галиев үзенең алмаз йөзле балтасын алып чыгып, манараны кисәргә җыенган кяферләр янына килеп, сабыр гына әйтә:

– Знакумнар! Балтам минем бик үткен! Бу балта белән мин бик күп кешеләрне тораклы иттем, шушы изге балтамны бер дә канга буйыйсым килми бит, җегетләр! Аннан соң безнең авыл бит кара баганалы, монда юкка чыккан кешенең йонын да таба алмыйлар! – ди.

Манара кисәргә теләүчеләр, пычкыларын да алырга онытып, Иске Комазаннан чыгып кача.

ЗИМАГУР НӘҖИП КЫЙССАСЫ

Зимагур булып йөргәндә
Ниләр генә күрмәдем;
Караңгы төн, ява яңгыр,
Өстемдә бер күлмәгем.
Зимагурлар җыры

Иске Комазанда «Мырзалар» дигән бер урам бар. Чыннан да, бу урам да төзекматур, монда да көр тормышлы хуҗалар яши. Заманчалары белән рәттән, моннан кырык-илле ел әүвәл салынган йортлар да еш күренә.

Урамның бу очындарак кызыл кирпечтән салынган ике катлы борынгы бер бина бар. Бу – ташландык өй, тәрәзәләре юк, түшәмнәре-идәннәре череп, туфракка әверелгән, таш дивардагы ярыкларда алабута үсә, тик шулай да бу бинаның кайчандыр бай йорты булганын чамалап була. Тикмәгә генә ул урамны «Мырзалар очы» дип йөртмиләрдер. Бу бинаның хуҗасын, ишле гаиләсе белән, кулак буларак, Себергә сөргәннәрдер.

– Юк! – диде Вахит Галиев. – Бу Нәҗип исемле авыл көтүчесенең йорты иде... Зимагур Нәҗип Шәфиков корган йорт бу...

...Егерменче йөздә туган Нәҗип Шәфиков сабый чакта әнисез кала. Атасы яшь хатынга, ырымчыга өйләнә. Үги ана Нәҗипкә бик кырыс, хәтта рәхимсез дә була. Ун яше җиткәч, Нәҗип байларга көтүчелеккә яллана. Бичара малай һәр эшләгән акчасын тиененә чаклы үги анасына кайтарып бирә. Ләкин үги ана тагын да кырыслана бара. Нәҗип бичара, кыерсытуларга чыдый алмыйча, авылдашларына ияреп, 17 яшендә шахтага китә. Өч ел күмер чабып акча туплагач, ул авылга Сабан туена, өйләнергә кайта. Авыл бае Гасыймның иң гүзәл кызы Гайшәне сората Нәҗип. Үги ана, Нәҗипнең ниятен белгәч, мыскыллап көлә:

– Зимагур Нәҗипкә бирерме икән Гасыйм бай алмаз кебек чибәр кызын? – ди.

Ходаның хикмәте, Гасыйм бай риза була бит. Зөфаф кичәсе килеп җитә. Үги ана көнләшүеннән шартлый яза һәм әйтә:

– Нәҗип, синең күлмәгең туйга ятышмый, мин сиңа менә туй бүләге итеп, шушы яңа күлмәкне әзерләдем! – ди.

Нәҗип шул күлмәкне кия. Никах укылганнан соң, кыз куенына керәм дигәндә, Нәҗипнең йөрәге шашып кага башлый, тәне кызыша, ул, эссегә чыдый алмыйча, күлмәген ерткалап ата һәм күлмәккә тегелгән сихер янчыгын күрә. Бу хикмәт турында икесе дә беркемгә бер сүз әйтми.

– Сихерче үги ана белән яшәп булмас! – дип, Нәҗип, аерым йорт салып, башка чыга һәм хатыны Гайшәбикәне шул йортта калдырып, тагын шахтага китеп бара.

Акча эшләп, хатыны янына кайта, каенатасы ярдәме белән кибет ачып җибәрә, бик мул тормышта яши башлый болар, мохтаҗларга ярдәм итәләр. Комазанда Мырза урамында ике катлы шушы кирпеч йортны җиткезеп керәләр. Ләкин 1930 елның феврале килеп җитә, кызыллар боларның бар малын талап, Нәҗипне кулга алалар. Дүрт баласы белән Гайшәбикәне дә Себергә аткарырга карар кылалар.

Иртәгә каторгага сөреләчәкләрен белеп, Гайшәнең Түбән Козгынчы авылындагы җизнәсе, ат җигеп, төнлә Комазанга килә, чанасына чыбылдык җәеп, дүрт баланы, балдызы Гайшәне алып, авылдан чыгып кача. Һәм аларны Тулада шахтада эшләүче дуслары янына хәтле алып китә. Гайшәнең ире Нәҗип шулай эзсез югала. Гайшә Каимә исемле кызын, Тимерхан исемле улын ялгызы үстерә.

– Бу йорт калхуз идарәсе булып та, урман хуҗалыгы кантуры, клуб, китапханә, ипи пешерү өе һәм склад булып та торды, – ди Вахит Галиев. – Гомере буе советлардан куркып яшәгән Гайшә әби йөз яшен тутырырга өч ай ярым калгач кына дөнья куйды... Соңыннан мәгълүм булды: 1930 елның 22 феврале көнне кулга алынгач, Нәҗипне Казанга алып китәләр, 30 мартта «өчлек суды» аны атарга хөкем чыгара. Шул елның 19 августында суд карары җиренә җиткезелә. Кабере билгесез. Ләкин Гайшә әби дә, кызы Каимә дә, улы – сугыш ветераны Тимерхан да аталарының язмышын белмичә китте, авыр туфраклары җиңел булсын!

Зимагур шахтёр, гади җир кешесе, намуслы Нәҗип һәм аның хатыны гүзәл Гайшәбикәне Комазан халкы әле дә онытмый! Урыннары җәннәттә булсын! Амин!

БӘЛӘКӘЙ КОМАНДИР

Мин гомерем буена хөсетле, мохтаҗларга ярдәмсезләрне, тәкәбберләрне сөймәдем.

Вахит Галиев

Менә шушы авылда 1927 елда безнең каһарманыбыз Вахит Вәли углы Галиев җиһанга аваз сала. *Вәли* – губернатор, җитәкче, оештыручы, олы урында утыручы дигәнне аңлата торган сүз. *Вахит* бердәнбер, ялгыз, уникаль дигән мәгънәдә килә. Гали – олы, бөек дигән сүз. Димәк ки, татарчага тәрҗемә итсәк, каһарманыбызның исеме ~ Олы Җитәкченең Углы Бердәнбер Бөек кеше – Вәли углы Вахит Галиев, губернаторның уникаль углы дигән мәгънәгә ия сүз. Җитәкче урыннарда утырганда аңа «Вахит Вәлиевич» дип мөрәҗәгать итәчәкләр.

Иске Комазан авылының урамы башыннан таш юл уза, дидек. Таш юл булса да, Комазанны чыкканда яңгыр-буран көннәрне олауларга – бичара атларга, машиналарга йөрүе җәһәннәм газабы була, юл газабы – гүр газабына әверелә торган иде. Тайгак үрне менә алмыйча, машиналар уылдый-уылдый иза чигә, чылбыр бәйләнгән машиналарның

көпчәкләре юлга җәелгән ташларны кубарып, балчык измәсенә арткы тәгәрмәчләре кереп бата.

– И-и, бичаракайлар! – диде Вахитның анасы Маһибәдәр. – Кичәдән бирле интегә инде бу шуфирләр тауны менә алмыйча.

Яңгыр кичтән үк туктаган иде инде, әмма аяк асты пычрак. Мәктәп баласы Вахит әнисенең ни әйтергә теләгәнен бик тиз аңлап алды. Сабый дәшмичә генә өйдән чыкты, аннан капка төбендә бераз басып торды. Аңа бу вакытта сигез генә яшь иде әле. Яланаяк саз ерып, ул Мырзалар урамына таба китте. Гөрләвекле уйнаучы малайларга әйтте:

– Әй, ялантәпиләр! Команда кирәк: син – Олы урам малайларын, син – Тау асты урамыннан малайларны җыеп, Үр янына алып кил!

Нигә, ни өчен, дип сорап тору юк! Рас, Вахит әмер бирә икән, әмерне сүзсез үтәргә кирәк!

Егермеләп малай машиналар баткан урынга җыелды, кайсысы такта, кайсысы көрәк алып килгән. Бичара шофёрлар малайларны елмаеп каршы алды. Егерме малай, башка шофёрлар белән бергә әле алга, әле артка атындыра-атындыра, бер машинаны үр башына менгезде. Аннан башкаларына да ярдәм иттеләр. Бу шулай гадәткә кереп калды. Машина батып, улаган тавыш ишетелә икән, Иске Комазан малайлары Вахит командир җитәкчелегендә баткан машиналарны этеп чыгара торган булып китте.

ТАҺИР БЕЛӘН ЗӨҺРӘ

Сугыш алдыннан Иске Комазанда Вахитлар каршысына ук яңа мәктәп салып куйдылар: мәктәп мөдире Хәмит абый бик күзәтүчән кеше, ул тиктормас Вахит Галиевнең баткан машиналарга ярдәм оештыруыннан хәбәрдар. Башлангыч сыйныфтан ук бик яхшы укыганга күрә, мәктәп ачылу тантанасында, беренче кыңгыраудан соң, мәктәп ишегеннән иң беренче Вахитны күтәреп алып кергән иде ул.

Йөзләп бала бу вакыйганың шаһиты иде. Кызыгучылар да, көнләшүчеләр дә булды, шиксез. Мәктәп мөдире Хәмит абый үз кочагында кечкенә Вахитны күтәреп мәктәпкә алып керсен әле!

Әмма иллеләп кыз арасында бу вакыйганы аеруча горурланып, җентекле күзәтеп торучы нәни кыз берәү генә иде – Наилә! Мәктәп мөдире Хәмит абый әйтерсең лә Наиләнең үзен күтәреп мәктәпкә алып керде. Наилә белән Вахит беренче сыйныфта, бер парта арасында утыра иде. Хәмит абый Вахитны идәнгә бастырды, Вахит янында Наилә пәйда булды, аларның куллары тоташты. Беркем дә Вахит белән Наиләнең җитәкләшеп мәктәпкә баруына, җитәкләшеп мәктәптән кайтуына игътибар итми иде. Гел бергә булганга, Таһир белән Зөһрә исемнәре аларга яңа кушамат булып ябышты. Икесенең дә бу кушаматка бер дә исләре китми. Алар бу эшне шулай булырга тиеш кебек кабул итте.

Алдан ук әйтеп куйыйк: чыннан да Вахит белән Наилә гомеркәйләре буе гел бергә, аерылгысыз булып яшәде. Аларга катлаулы да, читен дә, бәхетле дә, озын да гомер бирде Аллаһы Тәгалә. Алар әле бүген дә исән, алар әле бүген дә бергә, алар тугыз баланың ата-анасы булды. Газиз кызлары һәм уллары табиб, укытучы, югары белемле хезмәткәр булып үсте, аларның 53 оныгы һәм торыны бар. Бер уллары гына иртәрәк вафат булды, калганнары сау-сәламәт, барысы да бәхетле гаилә корды, шөкер.

70 ел аерылгысыз никахта. Кемгә эләккән бу бәхет?!

КЫЗЛАР

(Вахит Галиевнең үз авызыннан)

Беркемнең дә җаны таштан түгел,
Иркә-назга мохтаҗ күңелләр.
Вахит Галиев

Үсә-үсә үсмер булып өлгердек. Миңнурый Гыйләҗиева авыл советы секретаре булып эшли башлады. Үткен иде ул. Хәтерлим, аулак өйдә бервакыт минем алга килеп утырган булып, битемнән чәп итеп үбеп алды. Ләкин шул кичне мин Гәззәбануны озата бардым. Миңнурый аулак өйдә үзе килеп үпте, Гәззабану исә, капка төбенә кайтып җиткәч, миңа үптермәде. Керде дә китте. Ачуым чыкты. Мин ул вакытта шигырь яза башлаган идем инде. Капка аша гына тегеңәр бер шигырь «ыргыттым». Кызларга алай ук кискен әйтергә кирәк булмагандыр инде... Син сөймәсәң, мин дә сөймим... фәлән-фәсмәтән... Еллар узгач, Гәззәбану килендәшенә бу турыда сөйләгән... Бервакыт Сирай Мәләүләрендә аулак өй, мин Гайшә исемле кызны озатып куйдым, Миңнурый бик көнләште. Армиягә китәм, сугышка китәбез, дип сөрән салып, гармунга җырлап, урам әйләнәбез бит инде. Мине Миңнурый озатты. Ләкин мин армиядән бер генә кызга да хат язмадым. Бары тик Наилә белән генә хат алыштык... Наиләне апалары, җизнәсе шахтага алып китте, өс-баш карау өчен... Без Наилә белән авылда чакта беркайчан да «мин сине яратам, сөям» кебек сүзләр әйтешмәдек. Ул шахтада, мин армиядә чакта хат алышканда без инде «мәхәббәт, яратам» кебек сүзләрне мул яза идек.

«Әни миңа: китмә, диде,
Үзем киттем карышып;
Ярты юлны барыр идем,
Кырыена ябышып.

Сандугачым, әйтеп сайра,
Кайсы талга кунасың,
Күзем йомсам, күз алдымда
Торган кебек буласын!» – дип, Наиләм җырлар язган, мин әле шушы җырны бүген дә жырлап йөрим. Шуннан Наиләмә багышлап мин дә шигырь чыгардым да Суслонгердан хат язып салдым:

«Йөрәк өзгеч ачы җил сызгыра,
Тели тәнгә үтеп керергә.
Кара бураннарда мин көрт ерам,
Бер мизгелгә сине күрергә».

Дәвамы бар

Редакциядән: *Мөхтәрәм авторыбыз, каләмдәшебез* **Роберт Мөхлис** улы **Батуллин***га (Рабит Батуллага) 26 мартта 80 яшь тула. Аны гомер бәйрәме белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары телибез!* ■

Безнең мирас №3 март 2018

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

ТОМСК ГУБЕРНАСЫНДА ЯСАЧНАЙ ТАТАРЛАР[1]

«Ясачнай татарлар» исеме белән билгеле җирле төркиләр, нәсел-ырулары бер үк булсалар да, хәзерге вакытта дин ягыннан өчкә аерылганнар. Халыкның күпчелеге – мөселман, бер өлеше – христиан, калганнары мәҗүсилектә, ягъни шаманлыкта калган. Боларның мәҗүсиләре җир һәм малмөлкәт буенча төп хуҗа булып торалар, башкаларга кыргый, залим кавемнәргә караган кебек карыйлар.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

[1] *Ясачнай (татарлар)* – рус телендәге «ясачные татары» сүзеннән үзгәртелгән *(тәрж. иск.)*.

Бу халыкның тарихы бик караңгы. Укый-яза белмиләр. Борынгы заманнарда боларның **кан** дип аталып йөртелгән *(ихтимал, хан дигән сүздер. – Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе, алга таба. – Г.И. –* **А.Р.***)* әмирләре булган, хәзер исә беркемнәре дә, берниләре дә юк. Тик йөрәкләрендә бер тирән яра бар һәм ул әле дә булса әрни: бу – соңгы тапкыр руслар белән берничә тапкыр сугышкан, аннары руслар тарафыннан әсир алынган, качып яңадан сугышка кергән, тагын әсир төшкән, соңгы чиктә рус зинданында вафат булган Каңза Батыр[2] исеме. Халык бу шәхесне изгеләштергән.

Шул **абгайлар**ның[3] каны *(ханы. –* **Г.И.***)* Каңза Батыр *(баһадир дигән сүз булырга тиеш. –* **Г.И.***)* яшәгән заманда барлыкка килгән, ул үзе сөйләгән шигырьләрне бүгенге көндә дә һәр абгай баласы яттан белә һәм халык аларны изге дип саный.

Мин бу шигырьне, абгайлар арасында танылган Сәфәргали исемле мулладан ничек ишеткән булсам, шулай язып алдым. Әлеге шигырь абгайларның батырлыгын һәм шул ук вакытта бәхетсезлеген дә ачык күрсәткәнгә, аны төгәл бирүне һәм, аңлашылсын өчен, шәрехләүне дә кирәк дип таптым[4].


٨٥ عالم اسلام

كنوريهرك ايفاى تشكر وابرازحسن توجه اولندى .

تومغ ولايتنده ياصاچناى تاتارلر :

« ياصاچناى تاتارلر » ناميله معروف يرلى توركلر نسل ونسبلرى براولمقله برابر ، شيمدى مذهبجه اوچ قسمه آيرلمشلردر : قسم اعظمى اسلامدر ، برقسمى اورتودوقس اولمش ، متباقيسى ده مجوسيتده ، شامان مذهبنده قالمشدر . بونلرك مجوسيلرى ، اصل اراضى وملك صاحبلرى عداوليبور وديكرلرينه وحشى، ظالم برمتغلب نظريله باقمقده درلر.

بونلرك احوال تاريخيه لرى غايت مبهمدر . اوقومق يازمق بيلمزلر . اسكيدن بونلرك « قان » ناميده (احتمال خاندر) امرالرى وارمش . شيمدى بونلرك هيچ برشيلرى يوقدر. يالكز قلبلرنده قالمش براثر وارايسه ، اوده صوك دفعه اولەرق روسلرايله برقاچ محاربه لرده بولنەرق ، اخيراً روسلر طرفندن اسير اولنمش ، تكرار فرار ايدەرك محاربه يه طوتوشمش ، تكرار اسارته كچمش ، عاقبت روس حبسخانه سنده وفات ايتمش « قاكره باطر » نامى دركه كنديلرنجه برنام مقدسدر .

شو آبغايلرقانى قاكره باطرك [بهادر ، ديمك اولەجق] بولونديغى زمانده سويلەديكى شعرلر ، بوكون آبغايلردن هرچوجغك آغزنده ازبرسويلەنمكده وتقديس اولنمقده در.

بن بوشعرى آبغايلر ميانده معروف سفرعلى ملا آغزندن ناصل ايشتدم ايسه اوصورته ضبط ايتدم . بو شعر ابغايلرك حماست وشهامتلرينه برترجمان بليغ اولمق مزيتنى حائز اولديغندن عيناً نقلى وايجه اكلاشلمسى ايچون آيريجه تحليلى مناسب كوردم.

شعر

— ١ —

قاش دن توروب آغتقان قاكرەنك آتى باشى آلدى
« قندلب » كه يتريب قازاق آتى باشى بوردى

— ٢ —

قوزغون يامان قوش بولوب « قو » دى تيب دم ديكايله
قازاق يامان يورت بولوب قاكرەنى توتدم ديكايله

— ٣ —

قازاقدك دككان توراسى اورجوق باشدى بولوبدى .
اورصدى بيلاكان قاكرەبى دشمان قولنده ياتوبدى .

ШИГЫРЬ

1. Кашдан туруб агыткан Каңзаның аты баш алды,
Кандәлибкә йитерип, Казак аты баш бурды/борды.
2. Кузгун йаман кош булуп/булып, «ку»ды тибдим дигәйлә,
Казак йаман йурт булуп, Каңзаны тутдым дигәйлә.
3. Казакдың диккән турасы урчук башды булыпды,

---

[2] *Каңза батыр* – Себер руслар тарафыннан яулап алына башлагач, ил-җирләрен саклап калырга теләп, милли азатлык көрәше алып барган кавемнәрнең легендар җитәкчесе Каңза би турында халык хикәятләре һәм җырлар хакас, телеут, шорлар арасында киң таралган. Хакас телендә каңза – челем дигән сүз. Хакасларда күбрәк ир-ат куллана торган җисемнәрнең атамаларын ир балаларга исем итеп кушу гадәте булган: Пычахтай< пычах – пычак, мылтых – мылтык, аларах – җәя һ.б.ш. *(тәрҗ. иск.)*.

[3] *Абгай* – мөгаен, Том төркиләренең үз атамалары, Габдерәшит Ибраһимов та аларны шулай атый. Хәзерге вакытта абгай исеме язмаларда очрамый. Рус язмаларында *абинцы* рәвешендә теркәлгән кавем әлеге халык булса кирәк. ‘Абинцы’ Томск губернасында яшәгән төрки кавем дип танытыла һәм бүгенге көндә, шор халкын оештыруда катнашкан этник төркем дип санала *(тәрҗ. иск.)*.

[4] Габдерәшит Ибраһимов шигырьнең һәр ике юллыгын бәет дип атый. Без дә искәрмәләрдә шул терминны кулландык *(тәрҗ. иск.)*.

Ур[ы]сды биләгән Каңза би дошман кулында йатыбды.
4. Казакдың сүде балтасы үсмә агачны үткәргән,
Урысдың [э]иткән дилләре умурткам турын үйкәгән (өйкәгән).
5. Алты түлктәб/төлектәб үй/өй кискән аймактымыз көч имтәр,
Алтун аймак йүнәткән Алматы бигә көч имтәр.
6. Кундузҗылаб кум казуб коб[ы]лаб чыгар көн кайда,
Кәбе колон бик тартыб Каңза йанар көн кайда.
7. Турусу бийүк ар былан, инә тум/том көстүб йелә бир,
Адам туралы туштаса, исәб/эсәб сәлам [э]итә бир.
8. Агачтан янгыз чыкбасун, анадан янгыз тукбасун,
Эмүлдәң янгыз үсбәсүн, энейдән янгыз тубасун.
9. Ак карчыгам бар булса, шаңшагай иде кәйнмдән,
Атар туралы бар булса, сурагай иде йортымнан.
10. Аркамдагы ак йаргак алга урулур булсачы,
Алты карындаш бар булыб, артымдан килүр булсачы,
11. Алты бүлү сы[г]рыгу мырга, кил абазы[й] тарталы,
Ай чулмон чыкканча, кил абазы[й] кайталы.
12. Каңза менгән «кир калтар», казакды йапа каткайла,
Казакды биләгән Каңза би, казак кулында йаткайла.

1. *Каш* – тау, калкулык. *Туруб* – ‘тору’ сүзеннән *торып*, язылышы Истанбулда да төрлечә, кайчак [т], кайчак [д] белән языла. *Агыткан* – ‘агыту’ сүзеннән «тезгенне бушатып, ирегенә кую». *Кандәлиб*[5] – бер шәһәр исеме, бүгенге көндә тәмам җимерек авыл хәлендә калган. *-кә* – бер кушымча, ягъни ‘Кандәлибкә таба’ дигәнне аңлата. *Йитериб* – ‘йиту’ – «килеп җиту» сүзеннән, «килеп җиткәч» дигәнне аңлата. *Казак* – абгайлар русларны *казак* дип тә атап йөртәләр. Кырым татарларында бу сүз шулай ук кулланыла. *Бурду* – ‘бору’ фигыленең үткән заман шәкеле, ягъни ‘борды’[6].

2. *Кузгун/козгон* – бер кош атамасы. *Йаман* – «түбән, дәрәҗәсез, начар» мәгънәсендәге сыйфат. *Булуб* – ‘булса да’ дигән сүз, чөнки бөтен татарлар ‘олмак’ мәгънәсендә булу сүзен кулланалар. *Ку*[7] – бер кошның атамасы, ерткыч кошларның иң зурысы, иң игътибарга лаегы.

Бу кош Себердә бик күп, ау этләре кебек, бу кош та җәнлек авында кулланыла, төлке аулаганда аеруча эшкә ярый. *-ды* – кушымча, *куды* – «куны, ку кошы» дигән сүз. Абгайлар телендә бу кушымчаның *-ты*, *-ны* шәкелләре дә бар. *Тибдим* – типтем. *Дигәйлә* – диячәк яки ди. *Йурт* – йорт, халык. *Тутдым* – тоттым, Истанбул төрек телендә – ‘туттум’. Биредә Каңза үзен ку кошына, русларны исә козгынга охшаткан.

3. *Казакдың* – казакның; биредәге төрки телдә әлеге кушымча [д] белән әйтелә. *Диккән* – төзегән, салган. Татарларда «Фәлән кеше өй дикте», диләр һәм бу «Фәлән кеше өй салды (төзеде)», дигәнне аңлата. Биредә дә «агач дикте, чатыр дикте» дип кулланалар. Кайчандыр татарларның йортлары чатыр кебек күчереп йөртелә торган булган, кирәгендә сүтеп җыелган, кирәгендә утыртып куелган. Бу *дик-* сүзе шуннан калган. *Тура* – шәһәр. *Урчук/орчок* – орчык, хатыннарның җеп эрли торган нәрсәсе. *Башды* – башы. Руслар төзегән шәһәрләрне, аларның әһәмиятсезлегенә

[5] *Кандәлиб* – Кандалеп, бүгенге Себердә Кондома елгасының кушылдыгы *(тәрҗ. иск.)*.
[6] Бәетнең мәгънәсе түбәндәгечә: «Каңзаның тезгенен бушатып җибәрелгән аты беренчелекне алды; казакның аты исә, Кандәлибкә җиткәннән соң, кире борылды» *(тәрҗ. иск.)*.
[7] *Ку* – бу атама бөтен төрки язма истәлекләрдә, себер төрки телләрендә, борынгы төрки телдә (quġu) «аккош» мәгънәсендә кулланыла дип күрсәтелә.

кинаяләп, орчыкка охшаткан[8]. *Ур[ы]сды* – ‘рус’ урынына татарлар ‘ур[ы]с’ диләр һәм язалар. *Биләгән* – яулаган, басып алган. *Би* – би, бәк.

4. *Суд* – чәлик, ягъни корыч дигән сүз, татарлар ‘курч’ диләр. *Суде*[9] – ‘корычны’ дигән сүз булырга тиеш. *Үсмә* – үсү сүзеннән, «Фәлән кеше үсде», диләр, бу – «Фәлән кеше буйга үсте, зурайды» дигән сүз. «Фәлән кабилә үсде», диләр, бу – «Фәлән кабиләнең кешеләре күбәйде» дигән сүз. *Үткәргән* – «ярып, тишеп үткән» мәгънәсендә, ‘үтү’ фигыленнән. *Ур[ы]сның* – русның. *[Ә]иткән* – әйткән, сөйләгән. *Умуртка* – умыртка, калак сөяге. *Уйкәгән/ өйкәгән* – «имгәткән» мәгънәсендә, ‘өйкәү’ фигыленнән[10].

5. *Түлк/төлек* – почмак. *Түлктәб/ төл[е]ктәб* – почмаклап, почмаклы. *Үй/өй* – өй, йорт. *Кискән* – «бүлгән» мәгънәсендә, ‘кисү’ фигыленнән. *Аймак* – кабилә. *Имтәр* – моннан соң. *Йүнәткән*

---

[8] Бередә, әһәмиятсезлеккә кинаядән бигрәк, мөгаен, охшату-чагыштыруга урын бирелгәндер. Ул заманнарда җирле халыкларның йорт түбәләре, күп кенә этнографик хезмәтләрдә күрсәтелгәнчә, түшәм рәвешендә генә булган, ягъни түшәлгән. Руслар исә йортларын очлы түбәләп салганнар. Орчыкның аскы өлешендә, җеп сарганда тыгыз булып җыелып барсын өчен, гөмбәз рәвешендәге очлы чыгынтысы була. Йорт түбәсе шуңа охшатылган *(тәрж. иск.)*.

[9] Бу сүз, кулъязмада ачык язылмаган булу сәбәпле, соңыннан ялгыш укылган булырга тиеш. Бу «корыч» мәгънәсендә түгел, «үткен» (үткен балтасы) мәгънәсендәге *сүри* <*сүрү*, *сөйрө* сүзе булырга тиеш. Чагыштырыгыз: *сүүрү* (алтай, телеут) «острый, остроконечный» (Радлов В.В. Опыт словаря тюркских наречий. Т.IV, Ч.I. С.-Петербург, 1911. – С.815) *(тәрж. иск.)*.

[10] Бу бәеттәге *иткән дилләре* сүзләре аңлатмасыз калган. Бередәге *дил/дәл* сүзе «тимерчыбык», *иткән/ ийткән* сүзе исә «керткән» мәгънәсендә булырга тиеш. Ул борынгы *дил/дел* «ат кылыннан үрелгән нык бау» сүзенә тоташа, *дилбегә* сүзендә дә бар. *Үйкәгән* сүзе исә алтай телендә «тишеп үткән» дигәнне аңлата. Шул рәвешле, бәетнең мәгънәсе түбәндәгечә: «Казакның балтасы үткен – үсеп утырган агачны ега; Урысның [минем тәнемә] керткән тимерчыбыгы кабырга турын (янын) тишеп үтә» *(тәрж. иск.)*.

– идарә иткән. *Алматы* – Каңза бинең улының исеме[11].

6. *Кундуз* – кондыз. *Коб[ы]лаб* – юлын табып. *Кайда яки кандай* – кайда. *Кәбе* – коскон, бер башы камытка тоташканнан соң хайванның гәүдәсе буйлап сузыла, койрыгы астыннан үтеп, икенче башы да камытка тоташтырыла торган нәрсә. *Кулун/колон* – кулан. *Бек тартуб* – бик нык итеп тартып. *Йанар* – ялтырар[12].

7. *Туру* – йөз, бит. *Турусу* – йөзсуы. *Ар* – гарь һәм хиҗаб (оялу, яшеренү). *Билән/белән* – белгән. *Инәтум/ инәтум* – туры. *Көстүб* – күзәтеп. *Йелә* – тиз, кызу. *Бир* – бар, кит. *Туштаса* – очраса. *Исәб* – хәлъәхвәл. *[Ә]итә* – әйтә[13].

8. *Йангыз* – ялгыз, берүзе генә. *Чыкбасун* – чыкмасын. *Токбасун* – тумасын. *Умулдың* – өметнең. *Инайдан* – өненнән[14].

9. *Карчыга* – бер ерткыч кош. *Шаңшагай* – кычкырыр (кош турында). *Кәйн* – арт, арка. *Йорт* – ватан.

10. *Йаргак* – калак, көрәк[15]. *Урулур/орылыр* – капланыр, ябылыр. *Булсачы* – булса иде.

11. [Беренче юлын аңлап булмады. – *Габдерәшит Ибраһим]. Абазый* – абзый. *Тарту* – кичкә каршы юлга чыгу. *Чолым* – йолдыз[16].

12. *Кир калтар* – көрәнсу ат төсе[17].

Шигырьдән аңлашылганча, бу халыкның теле – төркичә, нәселнәсәпләре дә төрки. «Ясачнай татар» дип аталулары исә, тавар төреннән бирелә торган салым мәгънәсендәге ясак түләргә тиешле булулары белән бәйле. Абгайлар үзләре дә төрки кавемнән булуларын әйтәләр. Борын-борыннан боларның ата-бабалары Чана (Чаны) күле тирәсендә һәм Обь елгасы буйларында күчмә тормыш белән яшәгән. Соңрак бу халыкның бер өлеше Енисей, бер өлеше Минусин елгалары ярларына килеп урнашкан.

Мин абгайларны өйрәнергә бик ты-

---

[11] Бу бәеттәге *алтун* сүзе аңлатмасыз калган. Бу – алтай *(алтан)*, хакас *(алтон)* телләрендә «алтмыш» дигән сүз, ягъни «алты ун». *Тулк/төлек* сүзен Г.Ибраһимов «почмак» мәгънәсендә дип күрсәткән. Шул рәвешле, бәетнең мәгънәсе түбәндәгечә: «Алты почмаклап йорт салучы халкыбызга [халкының уңганлыгын, алдынгылыгын билгеләргә тели] бик авыр инде; Алтмыш кабиләнең башында торучы Алматы бигә бик авыр инде» *(тәрҗ. иск.)*.

[12] Бу бәеттәге *кундузҗылаб* (кондызчалап) сүзе «кондыз кебек» мәгънәсендә булырга тиеш. *Кобы* – алтай телендә «чокыр», *кобылаб*, димәк, «чокыр казып» дигән сүз. *Кәбе* сүзен Г.Ибраһимов *коскон* дип аңлаткан, ат иярләүдә (җигүдә) кулланыла торган бу җисемгә хакас телендә *хосхын* диләр. Себер татарларында *кулан*, алтайчада – *колоң*, тува телендә – *колун* рәвешендә кулланыла торган сүз «ыңгырчак (ияр) бавы» дигәнне аңлата. Алтай телендә *йанар* «әйләнеп кайтыр» дигән сүз. Шул рәвешле, бәетнең эчтәлеге түбәндәгечә: «Кондыз кебек ком казып, юл ярып чыгар көн кайда? Эшлеясен, ыңгырчак бавын нык тартып, Каңза әйләнеп кайтыр көн кайда?» *(тәрҗ. иск.)*.

[13] *Туру/торо* – торык. *Бийүк* – алтайчада – *бийик* «биек». *Ар/эр* былан – ата болан (ата поши). *Инә/энә* – ана, *тум/том* – Том елгасы. *Йелә бир* – алтайчада *йеле* бер «юыртып бар, юырт». *Адам* – атам. *Исәб* – алтай телендә эзеб «искә төшереп». Бәетнең мәгънәсе: «Озын торыклы болан, Том юнәлешен күзләп юырт; Атамның якташлары очраса, искә алып, сәлам тапшыр» *(тәрҗ. иск.)*.

[14] Биредә *умул* дип укылган сүз *эмул/эмил* булырга тиеш, алтай телендә ул «җимеш төше»н аңлата. *Инайдан* рәвешендә укылган сүз дә *энейдән* булырга тиеш, алтай телендә *эне* «әни, ана» дигән сүз. Бу бәетнең мәгънәсе: «Агачлардан агач ялгыз үсеп чыкмасын; ана хайван ялгыз бала тудырмасын. Җимеш төшеннән ялгыз [үсенте] үсмәсен; Анадан ялгыз [бала] тумасын» *(тәрҗ. иск.)*

[15] *Йаргак* – болан яки пошин тиресеннән тегелгән өске кием *(тәрҗ. иск.)*.

[16] 11нче бәеттәге *сы[г]рыгу* сүзе «сыгрыгны, ягъни курайны» мәгънәсендә, алтайчада – *сыгыр* – «сызгыру»; *мырга/марга* – алтайчада *марга* «үз дигәнен итү»; *тарталы* – (курай) уйный-уйный; чагыштырыгыз: башкортчада – Таштугайкай, һинең камышыңдан сор курайзар яһап *тартайым* (халык җырыннан). *Кайталы* – карый-карый, күзәтә-күзәтә, алтайчада – *кайы* – «күзәтү, тикшерү». Бәеттәге *абазы* сүзе алтайчадагы *аба* «ыру башы, юлбашчы» сүзеннән «абасы, ягъни (халыкның) юлбашчысы» мәгънәсендә булырга тиеш. Шул рәвешле, бәетнең эчтәлеге: «Алты бүлемле кураеңны, бернигә карамый, уйный-уйный кил, ыру башы; Ай, Чулпан калыкканчы, күзәтә-күзәтә кил, ыру башы» *(тәрҗ. иск.)*.

[17] *Кир* – хакас телендә *кир* «зур, өлкән; карт» мәгънәсендә кулланыла. *Калтар* – алтайчада *калтар* «сары тимгелле җирән ат». *Йапа* – алтайчада *йаба* «бергә, бөтенләй». *Каткайла* – алтайчада *кат* – «бөгү, кәкрәйтү». *Биләгән* – алтайчада *бийле* – «кулында тоту, ия булу». Бәетнең мәгънәсе: «Каңза би атланган карт, сары тимгелле җирән ат казакны [егып] бөтереп ата ла; [Кайчандыр] казакны үз кулында тоткан Каңза би казак кулында [әсир] ята ла» *(тәрҗ. иск.)*.

рыштым, телләрен дә тикшердем. Алда телгә алынган Каңза Батыр шигырен очраган бер абгайга укыдым, мәгънәсен сүз-сүз сорадым. Бер тапкыр бер хатынга укыганда, елады. Берничә сүзнең мәгънәсен ул хатыннан сорадым. 7 нче бәетнең беренче юлындагы *турусу* сүзенең «хиҗабы, япмасы ачылмаган йөзсуы» мәгънәсендә икәнен әйтте. Шул ук вакытта кайбер сүзләрнең мәгънәләрен аңлый алмадым. 11нче бәетнең беренче юлын бөтенләй аңламадым. Абгайлар үзләре дә аңлата алмадылар.

КАҢЗА БАТЫР

Бу кешенең исеме рус тарихында күренми. Ихтимал, руслар аның исемен үзгәрткәннәрдер. Абгайларның карашында Каңза би – гаять бөек шәхес, бүгенге көнгә кадәр исеме изге исем итеп искә алына. Риваятькә күрә, хәзерге Томск урнашкан җирләрне руслар яулап алырга җыенганда, бу шәхес илен саклап калу өчен бик тырышкан, рус гаскәренә каршы берүзе каршы торган вакытлары да булган, берничә тапкыр әсир төшкән. Качып китеп тагын сугышкан. Соңгы тапкыр әсир төшкәч, зинданда әлеге шигырьне сөйләгән. Шигырьнең эчтәлеге һәм мәгънәсе буенча да бу кешедәге батырлыкның, шул ук вакытта бәхетсезлекнең дәрәҗәсен аңларга мөмкин. Шигырьнең икенче бәетендә, мәсәлән, ул козгын дәрәҗәсендә яман русларның кулында ку кебек мәгърур Каңзаның әсир калуын никадәр хурлык икәнен аңлатырга тели. 3-4 нче бәетләрдә дә русларның кулында әсир булуы ачык



٨٦ عالم اسلام

— ٤ —
قزاقلك سودی بالطه‌سی اوسمه آغاجنی اوتکارکن
اورس‌نك ایتکان دیلری اوموزقام تورین اویکاکن
— ٥ —
آلق تولكتب اوی کسکان آیما قیمز کوچ ایتز
آلتون آیماق یونا تکان آلماتی بیکه کوچ ایتز
— ٦ —
قوندوز جلاب قوم قازوب قوبلاب جیغارکون قایدا
«كابى» قولون بیك تارتب قاکرا بانار کون قایده
— ٧ —
توروسو بیوك آربیلان اینه‌توم کوستب بیله بر
آدم تورالی توشناسه ایساب سلام اینه بر
— ٨ —
آغاجدن یانکز جیقباسون آنادن یانکز توقباسون
امولدك یانکز اوسباسون انیادین یانکز توباسون
— ٩ —
آق قارجیغام باربولسه شانکشاغای ایدی کایمدن
آنار تورالی بار بولسه صوراغای ایدی یورنم نان
— ١٠ —
آر قامداغی آق بارقاق آلغه اوریلور بولسه‌چی
آلی قرندش باربولوب آرتمدن کیلور بولسه‌چی
— ١١ —
آلی بولو صریغو مرغا کیل آبازی تارتالی
آی جولون جیغغانچه کیل آبازی قابشالی .
— ١٢ —
قاکره منکان «کیر قالتار» قازقدی بابه قاقسایله
قازاقدی یلاکان قاکرمنی قازاق قولنده یاتقایله .

аңлашыла. 5 нче бәеттә кавем-кабиләсе һәм улы өчен кайгыруы аңлашыла. 6 нчы бәеттә бу әсирлектән котыла алмаячагына әрни. 7 нче бәеттә үзе зинданда ятканда, аны күрергә килгән улына: «Нинди йөз белән чыгасың? Очраган кешеләрдән оялмыйсыңмы? Атаң түбәннәр кулында әсир, син ничек яшисең, түзәсең?»[18], – дип әйтергә тели. 8 нче бәеттә улының ялгыз калуына кайгыра. Шигырь, башыннан ахырына кадәр, бу кешедә никадәр зур ныклык һәм кыюлык булуын күрсәтә.

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе.* ■

[18] *Турусу* сүзен «йөзсуы, намус, хәя» дип аңлатканга, Габдерәшит Ибраһимов 7 нче бәеттән бу мәгънәне чыгарган. Ләкин төп борынгы диннәре шаманчылык булган алтай, телеут, хакас халыкларының ата-бабалары тарафыннан XVII-XVIII гасырларда ук иҗат ителгән бу халык җырларында Ислам дине белән бәйле мотивлар, гарәп теле сүзләре булу бик үк ышандырмый. XX гасыр башында өч төрле дин инде янәшә яшәгән бу җирлектә халык арасында борынгы текстның аңлашылмый торган сүзләрен үзләренчә аңлау яисә кайбер сүзләрне үзләре белгән сүзләргә охшату күренеше булмый калмагандыр, күрәсең. Г.Ибраһимов, үзе әйтеп үткәнчә, җырның мулла сөйләве буенча язып алынган булуын да онытмаска кирәк. *Абазы* сүзенең, мәсәлән, *абазый* рәвешле укылып, «абзый» дип аңлатылуы моңа ачык мисал булып тора. *Абзый* сүзенең килеп чыгышы гарәп телендәге *хафыз* «Коръәнне яттан белүче хөрмәт иясе кеше» сүзе белән бәйле һәм бәетләрнең эчтәлеге белән туры килми *(тәрж. иск.)*.

Безнең мирас №3 март 2018

ХӨСНИ ХАТ

Мөхәммәт Галләм,
Уфадагы «Ихлас» мәчетенең имам-хатыйбы

Дини хәятебез вә рухи тормышыбызга бәйләнеше гаять зур булган милли сәнгатебездә каллиграфия лаеклы урын алган. Үзенә генә хас нәфислек белән матур язу – хөсни хат Ислам диненең үзенчәлекле һәм киң үсеш алган юнәлешләреннән санала.

Хөсни хат матур язуны аңлата.

Ә «хат» кәлимәсенең уннан артык мәгънәсе бар.

Ислами сәнгатебезнең казанышларыннан саналган хөсни хат үрнәгенең җәүһәрләре кулъязма китаплар, шәмаилләр аркылы буыннан-буынга күчеп, тарихыбыз төпкеленнән бүгенге көннәребезгә кадәр килгән. Аның нәфислек көче иң башта изге Китабыбыз Коръәни Кәримдәге аять җәлиләләр язылышында күренә.

Шәрыктә киң таралган әйтемдә: *«Кешенең матурлыгы – аның матур язуында, бигрәк тә ул зирәк тә булса»*, – диелә. Бер мөбарәк хәдистә исә: *«Матур язу – иманнандыр»*, – дип бәян ителә.

Язу – телнең кулы, кулның – теледер. Күңелнең – тәрҗемәчесе, ихтыярның – үлчәве, акылның – илчесе, рухның – көзгеседер.

Матур язу күзне һәм зиһенне тиз арудан саклар. Фикер гәүдәләнүенең җәһәт җитешүенә сәбәпче булыр. Сүзне тәртипкә салыр, мәгънәсен куәтләндерер. Телне – тезгенләр, укыган чакта төзәтергә мөмкинлек бирер.

Бүген тарихта югалган яисә югалу хәленә дучар ителгән милләтләргә хас булган язуларның кайда, ничек барлыкка килгәнен вә никадәр язма төрләре булганын тулысынча белмибез. Ләкин Коръәни Кәримдәге хәрефләр һәм язуларның эстетика, гүзәллек җәһәтеннән һичбер нәрсә белән чагыштырылмаслык дәрәҗәдә уңышлырак һәм отышлырак **мөстәкыйль бер барлык булганы** – бәхәссез.

Мөбарәк дин китапларыбызда, Адәмнең (г.с.) Җәннәттә булып, Җәннәтнең һәр җирендә җиде күк өстендә матур хәрефләр белән язылган «Кәлимәи Тәүхид» язуларын күргәнлеге бәян ителә. Ислами язмаларның илаһи булуы, ул хәрефләрнең кеше язуы түгеллеге, аларның дөнья һәм Адәмнең юк чагында ук булганы әйтелә.

Ислами язу Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) якын сәхабәләреннән хәзрәте Гали, хәзрәте Гомәр, хәзрәте Тәлха, вәхи китапларын язып, Ислам дөньясының беренче язучыларыннан булган.

Ә инде милли каллиграфия сәнгатебезнең тамырлары халыкларыбызның Ислам динен кабул итүе һәм гарәп язмасының таралуы белән бәйле.

Матур язу – хөсни хат үрнәкләре мәдрәсәләрдә өйрәтелгән. Шунысы да бар: бу сәнгатьнең чын осталары бик аз булган.

Бөек хаттатларның – матур яза белүчеләрнең исемнәре безнең көннәргәчә саклангән. Алар йөзләгән китапларны күчереп язган. Мәшһүр матур язучылардан Собхан Мәрҗани, Исламкол әль-Каргалы, Мостафа Чутай, Мөхәммәт Али Мәхмүтовлар билгеле.

XVIII-XIX гасырларда Казанда күчереп язучылар, каллиграфлар – хатчылар җәмгыяте яшәп килгән.

Каллиграфия сәнгате бөтен нәфислеге белән халык иҗатында, шәмаилләрдә чагыла.

Шәмаилләр бөтен барлыгы белән халыкның матурлык һәм рух төшенчәсен чагылдыра. Аларда, гадәттә, Коръәни Кәрим сүрәләре, урта гасыр шагыйрьләре Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр кебек мәшһүр затларның шигъри юллары язылган булган.

Ислам мәдәниятенең нәфислек-гүзәллекләре бүген дә рәссамнарыбызның игътибар үзәгендә. Танылган рәссам Вәсил Ханнановның «Чыңгыз Хан» рәссамнар төркеменең иҗаты аеруча игътибарга лаек. ■

УКУ КИТАБЫ

Хөсәен Әбүзәров

Революциягә кадәр мәктәп-мәдрәсәләр өчен басылган дәреслекләр – педагогик мирасыбызның аерылгысыз бер өлеше. Шуларның берсе – Хөсәен Әбүзәров[1] төзегән «Уку китабы». Дәреслек «Мәгариф көтебханәсе»ндә басмага әзерләнеп, 1908 елда И.Н.Харитонов басмаханәсендә дөньяга тарала. Китапның алдагы бер бүлегендә: *«Мөселман булган кешегә иң әлек дин гыйлемен, ягъни иманны белмәк, моннан соң үзенә кирәк фарыз вә важибларны белмәк, моннан соң башка гыйлемлекләргә тырышмак тиештер»*, – дип язылган. Шуңа нисбәтле булса кирәк, басма әдәп-әхлак, үгет-нәсыйхәттән гыйбарәт хикәячек-кыйссалардан, ислам дине нигезләре һәм табигать, тарих, география фәннәреннән белем-мәгълүматны колачлаган 85 бүлек-дәрестән (112 бит) тора. Алар арасында Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев шигырьләре һәм халык мәкальләре дә бар.

Китапның азагындагы бүлекләрдән җәдиди ибтидаи *(башлангыч)* мәктәпләрдәге уку-укыту ысулын һәм эчтәлеген күзалларга мөмкин: *«Бу ел августның 25 нче көнендә осуле мәддия[2] илә «Әлифба»дан сабак башладым. Аллаһы Тәгаләгә шөкер булсын ки, гыйнвар башына кадәр бер дә язу укый белмәгән балалар хәзердә бик яхшы язу язарга вә укырга өйрәндек һәм үземезнең динемезне, пәйгамбәремезне таныдык»; «Мәктәп шәкертләре беренче, икенче, өченче сыйныфларга бүленеп укытылмактадыр. Беренче сыйныф балаларына төрки танытып, язуга, әхлак вә әдәбкә өйрәтеп, Коръән газыйм, гыйльме халь вә хисап укытыладыр. Икенче, өченче сыйныф шәкертләренә Коръән газыйм, тәҗвид, гыйбадәте исламия, хисап, әхлак, тарих, имля тәгълим ителмәктәдер (укытыла)».*

Игътибарыгызга әлеге китаптан кайбер дәресләрне тәкъдим итәбез. Болар галимголәмә өчен революциягә кадәрге уку китаплары ничек төзелгәненә бер мисал булса, гади укучылар исә үз бала яки оныкларына шунда язылганны белдерсәләр, бу эшебез бушка китмәс, дип ышанырга мөмкин. Текстлар мәдрәсә мөгаллиммөгаллимәләренә яки башлангыч класс укытучыларына да файдалы булыр.

Китап белән тулысынча ТР Милли китапханәсенең Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә танышырга мөмкин.

Редакция.

---

[1] Әбүзәров Хөсәен Габдрахман улы (188?-1917) – **Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатки районындагы Яңа Зимничә авылы**нда туган. Шундагы атаклы «Хансөяр» һәм Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә белем ала. «Таң йолдызы», «Тавыш», «Таң мәҗмугасы» исемле газеталарның мөхәррире.
[2] Осуле мәддия – аерым иҗекләрне алып өйрәтү ысулы (силлабик метод).

Безнең мирас №3 март 2018



Уку китабы /мөрәттибе Хөсәен Әбүзәров; нашире «Мәгариф көтебханәсе». – Казан: Лито-Тип.: И.Н.Харитонова, 1908. – 112 б.

ЯҢГЫРАУ

Беркөнне Шакир атасы илә бер авылдан икенче авылга барганда урман эчендә агач төбенә утырып ял итмәкче булмышлар. Шулвакытта атасы угылына:

– Угылым! «Ялганчы! Алдакчы!» – дип кычкыр, – диде.

Шәкерт, атасы әйткәч, аяк өстенә басып:

– Ялганчы! Алдакчы! – дип кычкырды. Урман эчендәге тавыш, шәкертнең тавышына каршы, ялганчы, алдакчы, дип үзенә кайтып килде. Шәкерт, бу тавышка гаҗәпсенеп, бераз курыкты. Атасы:

– Инде: «Бик яхшы! Бик гакыллы!» – дип кычкыр.

Шәкерт:

– Бик яхшы! Бик гакыллы! – дип кычкырды. Каршысына, бик яхшы, бик гакыллы, дигән тавыш килде. Шәкерт бу тавыштан бик курыкты, гаҗәпләнеп атасының күзенә карады.

Атасы:

– Кара, угылым, начар сүз кычкырсаң, үзеңә начар сүз кычкырды, яхшы сүз кычкырсаң, үзеңә яхшы сүз кычкырды, – диде. – Имди һәрвакытта вә һәр заманда кешегә яхшы вә ягымлы сүз әйтергә тырыш. Яман сүз сөйләсәң яисә бер-бер начарлык эшләсәң, сиңа да яхшы эш вә яхшы сүз әйтмәсләр, диде. Урманнардагы, елгалардагы, су

буендагы тавышлардан курыкма. Чөнки шундый урыннарда кешенең үз тавышы үзенә кайтыр, дөньядагы кешеләр дә шул тавышлар кебидер, әдәбле холыклы вә ягымлы бала булсаң, кешеләр дә сиңа бик яхшы вә ягымлы булырлар. Сине бик яратырлар, бик сөйләрләр. Әгәр дә яман холыклы, әдәбсез вә гакылсыз булсаң, кешеләр дә сине бер дә яратмаслар вә сөймәсләр, – дип, Шакирне кулыннан тотып, юлларына китмешләрдер.

САДАКАЧЫЛЫК

Садакачылык безнең динемездә, шәригатемездә тыелмыштыр, чөнки садакачылыкка илтүче нәрсә – фәкыйрьлек вә мохтаҗлыктыр. Бу фәкыйрьлекнең начарлыгы хакында пәйгамбәремез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Фәкыйрьлек көферлеккә якындыр», – димеш. Адәм балалары көчләре йиткән кадәре иҗтиһад кылып эшләмәсәләр вә һәм бер-бер эшкә тырышмасалар, һәрвакыт үзләрен үзләре ялкаулыкка салып, һичбер нәрсә эшләмичә тик торсалар, ул кешеләр фәкыйрь вә мохтаҗ булырлар. Имди, сөекле балалар! Яшь вакытыңызда сабак укырга, әдәбле вә әхлаклы булырга тырышыңыз, һичбер вакытта кеше нәрсәсенә күзеңезне вә күңелеңезне төшермәңез. Яшьлек заманыңызда сабак укысаңыз, әдәбле, инсафлы булсаңыз, насыйп булса, зур булгач, бай вә дәүләтле булмасаңыз да, үз кул көчеңез берлән хидмәт итеп тамагыңызны туйдырып көн итүче тугры бер кеше булачаксыңыз.

ЯХШЫ СҮЗЛӘР

Байлык вә сәламәтлек, һәм шатлык – кадерене белеп шөкрана кыла белмәгән кешеләр өчен файда түгел, бәлки бик зарардыр. Галимлек берлә генә кешене яхшы диеп булмыйдыр. Гыйлеме илә бергә гамәле һәм яхшы-гүзәл холкы да булса, шулвакытта ул кеше беренче яхшы кеше буладыр. Үч алып ләззәтләнүгә караганда, кешегә шәфкать вә мәрхәмәт кылып ләззәтләнү бик күп артыктыр.

Вакыт иркен, диеп уйлап кылыначак эшне кичектерү – бик диваналыктыр, чөнки вакыт бик аздыр. Яман сыйфатлардан сакланмак тиешледер. Ул сыйфатларның берсе – башланган эштән туеп ташламак, икенчесе – сабырсызлык. Эч пошып күңелсезләнү – бер зур авырудыр. Аның дәвасы – бер эш илә шөгыльлләнүдер. Ялкаулык бик күп җәфаның әүвәлге сәбәбедер. Яман холыкларның иң начары – ялкауланып эшсез ятуны рәхәтлеккә хисап кылудыр. Әмма бер-бер эш илә шөгыльләнүнең өч йимеше бардыр: беренчесе – әгъза сәламәтлеге, икенчесе – күңелнең рәхәтләнүе, өченчесе – зиһеннең артуыдыр.

Кич илә йокыга ятканда, Аллага шөкер, бу көнемне бушка үткәрмәдем, берничә төрле кешегә яхшылык вә ярдәм иттем яисә никадәрле сабак вә китап укыдым, диярлек булган кешедән бәхетле кеше юктыр.

Галим вә мәгърифәтле кешеләрнең әүвәлге хәлләрен уйлап карасаңыз, күрерсез: аларның гыйлем вә дәүләткә ирешүләре бик күп зәхмәт вә мәшәкать чигү илә генә булмыштыр. Кәеф вә сафа бик рәхәттер, ләкин юлында бик күп җәфаларга тугры киленәдер. Әгәр дә үземездә кимчелекләр булмаса иде, башка кешеләрдә кимчелекләр күргәч, һич артык сөенмәс идек. Кешеләргә күп ярәм вә мәрхәмәт кылган кешенең вөҗданы һәрвакыт рәхәт вә шат булыр. Үзең эшләп тапкан дәүләттән кадерле нәрсә юктыр. Һәм дә үз көчең берлә хидмәт итеп, көн күрүдән кадерле вә мөкатддәс эш юктыр. Шуның өчен, атадан калган мал илә бай булган кеше яисә эшчеләр көче илә табылган малдан көн итүчеләр, байлыкның рәхәтен сизмиләр һәм дә хидмәтчеләрнең кадерен дә белмиләр. Шуның өчен хәзрәти Гомәр: «Бер кешене күрсәм, бик яхшы

ихлас куямын, ләкин шул кешенең һөнәрсезлеген белсәм, шул кешедән ихласым кире кайтадыр», – димеш.

ЯЛГАН СӨЙЛӘШМӘК

Ялган сөйләшмәк – бик яман холык вә гакылсызлыктыр. Ялганчы бала – Аллаһы Тәгаләнең һәм ата-анасының вә хәлфә, вә башка кешеләрнең дошманыдыр. Ялган сөйләшүдән бик саклану тиештер. Үзең бик зур начарлык кылсаң да, ялган сөйләшмәсәң, тугрылыклы булсаң, нинди начар эштән дә котылырсың. Ялган сөйләүче олуглар каршында һәм иптәшләре каршында кадерсез вә игътибарсыз булыр. Ялган сөйләшергә өйрәнгән кешенең күп вакытта ялганчылыгы сизелеп, оятка калыр. Кешеләр алдында ялган сөйләшеп оятка калу кеби дөньяда һич зур гаеп юктыр. Имди һичбер вакытта ялган сөйләшергә вә кешене алдарга өйрәнмәңез. Тугры сүзле булыңыз, бер мәртәбә ялганчылыгыңыз чыкса, мең мәртәбә дөрест сөйләсәңез дә сезнең сүзләреңезгә ышанмаслар.

ЯХШЫ ИПТӘШ

Һәрвакытта яхшы кешеләр илә йөреп, сөйләшеп, утырышып, начар холыклы, әдәбсез, әхлаксыз кешеләр илә йөрүдән, утырышудан вә сөйләшүдән сакланмак бик тиештер. Чөнки һәрвакыт утырышкан, күрешкән вә сөйләшкән кешесенең холкы вә кыланышы илә холыкланмак – адәм баласының табигатеннәндер. Әгәр дә шундый начар вә холыксыз кешеләр илә сөйләшсә, йөрешсә, бара-бара үзе дә шул кешеләр кеби начар вә холыксыз булуына һич шик юктыр. Әдәбле балалар, һәрвакытта яхшы вә әдәбле балалар илә йөрерләр, утырышырлар, сөйләшерләр. Вә һәркем каршында яхшы вә әхлаклы булырга тырышырлар. Начар эшләр эшләмәсләр, үзләренең иптәшләре бер-бер әдәбсезлек кылса, ул баланы яхшылыкка димләп, әдәбсезлекнең начарлыгын аңлатырга тырышырлар.

ЭЧЕҢНЕҢ МАТУРЛЫГЫ

Бер кеше үзенең наданлыгын белмичә бер хидмәткә керешсә яисә матур-матур киемнәр киенеп, галим вә белекле кешеләр арасына керешеп сүз сөйләшә башласа, хәзер наданлыгы беленеп, саескан кеби кем икәнлеге аңланыр. Шуның кеби адәм баласына да тышыннан гына матурланып яисә үзе белмәгән нәрсәләрне, беләмен, диеп йөрергә ярамыйдыр. Тышыңны матурлаган кеби эчеңне дә матурларга кирәк буладыр. Тыштан матур булган кеби күренеп, эчтән каралып йөрергә ярамыйдыр.

КҮҢЕЛ РӘХӘТЛЕГЕ

Богдайга һәркем мохтаҗ булып, аның илә һәркаюсы дога кылмыштыр. Һәм догалары кабул булып, ягмур яумыштыр имди. Балалар да һәркемгә үзләрен сөйдереп, олугларга хөрмәт вә фәкыйрьләргә ярдәм итсәләр, дөньяда вә ахирәттә кадерле булырлар вә һәм дә кешеләрнең догасын алган булырлар. Шуның өчен дә үзең тырышып, иҗтиһад кылып, көчең йиткән кадәре кешегә ярдәм вә яхшылык кылмак тиештер. Кешегә ярдәм кылган кешенең күңеле рәхәт вә шат булыр. Кәсеп вә иҗтиһад илә тапкан дәүләттән кадерле нәрсә булмас. Әмма ата-анадан яисә башка кешедән калган дәүләтнең һич кадере юк. ■

Безнең мирас №3 март 2018

Мәхмүт Хәсәнов хатлары



САЛИХ БАТЫЕВКА

Салих ага, саумысез!

Иң элек Азнакай төбәгенең таҗы булган Чатыр тавы кадәрле сәламемне иңдерергә рөхсәт итегез. Берьюлы, якынлашып килгән олуг бәйрәм – Бөек Октябрьнең 60 еллыгы белән дә тәбриклим.

Хәзер сүзгә күчәм. Салих ага, быел миңа 50 яшь тула. Аны районда әдәби кичә итеп билгеләп үтәргә булдылар. (16 декабрьдә, дип торабыз.) Шул мәҗлестә Сезнең дә булуыгызны бик теләр идем. Азнакай Сезнең өчен ят җир түгел, бәлки, тормыш иптәшегезне култыклап, килеп тә чыгарсыз? (Чакыру билетын, чак кына соңрак, декабрь ае башларында алырсыз.) Сезнең килүегез барыбыз өчен дә нур өстенә нур булыр иде.

Сез, Салих ага, миңа карата һәрвакыт изге теләктә булдыгыз, иң авыр вакытларда ярдәм кулыгызны суздыгыз. Сез эшләгән изгелекләрне гомерем буена да онытасым юк.

Хәзер мин дә Сезнең ышанычыгызны акладым кебек. Фидакарь хезмәтем белән акладым. Мин 1970 елның маеннан бирле КПСС члены. Район газетасында промышленность бүлеге белән идарә итәм. Азнакайга күчеп килгәннән бирле (сез җибәрдегез) 8 роман яздым. Алтысы дөнья күрде. 50 яшьлек юбилеемны «Шөгеровлар» исемле күләмле яңа роман төгәлләп каршылыйм. Әсәр нефть чыгаручылар турында. Мәктәп яшендәге балалар өчен «Шайтан малае» дигән повесть тәмамладым. Ул «Ялкын» журналының 9, 10, 11, 12 нче саннарында басылып ята.

Сезгә, Салих ага, әле яңарак кына чыккан китабымны җибәрәм. Рәхим итеп, кабул итегез.

Кабат чакырам Сезне, килүегезне өмет итеп калам.

Менә, Салих ага, шул гына иде.

Ак бәхетләр, зур уңышлар, какшамас сәламәтлекләр Сезгә!

Кабат сәлам белән,

М.Хәсәнов.
Азнакай.
20.10.1977 ел.

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ ДИРЕКТОРЫ ГАРӘФ НИЗАМЕТДИНОВИЧ ШӘРӘФЕТДИНОВКА

Гарәф туган, саумы!

Иң элек Азнакай төбәгенең Чатыр тавы кадәрле сәламемне иңдерергә рөхсәт ит. Берьюлы, якынлашып килгән олуг бәйрәм – Бөек Октябрьнең 60 еллыгы белән дә тәбриклим.

Хәзер бер-ике авыз сүз. Быел минем өчен шактый мәшәкатьле ел булырга тора, 50 яшемне тутырырга чамалыйм. 50 яшь! (Гавриль Ефимович Беляев бүлегендә бергә утырган чаклар әле яңарак кына кебек. Уйласаң, хәйран калырлык, чирек гасырдан артык вакыт үткән дә киткән.) Менә бит гомер дигәнең!

Хәзер төп мәсьәләгә күчәм. 1976 елда китап чыгара алмау, шулай ук 1977 елда да (зурга өмет итеп тә) бәләкәй генә переиздание белән чикләнү, 1978 елның да (кулъязма соңарып килде, дигән сылтау белән) «кысыр» калуы материаль якка шактый каты сукты. Муеннан тиң бурычта яшим. Рәхәт!..

Нилектән әйтәм әле боларны? Әлмәттәге дуслар мондыйрак фикер әйттеләр: теге яки бу әсәрне кабат бастырганда 25-30 проценты яңадан эшләнсә, беренче басма кебек үтә, имештер. «Урман шаулый» повесте (бик яраткан әсәрем) нәкъ шулай, ныклап торып яңадан эшләнде. Яңа бүлекләр өстәдем, искеләрен сыздым, кыскасы, нык кына үзгәрттем. Моны редактор Н.Гамбәров та раслар.

Әгәр дә мәгәр шул искәрмәне миңа карата да куллана алсаң, чак кына тернәкләнеп китәр идем шикелле. Юбилейга дус-ишләр киләбез, дип атлыгып торалар (Әлмәт белән Лениногорсктан гына да кырыклап кеше киләчәк). Гариф Ахунов та килергә җыена. Гарәф туган, син дә карчыгыңны култыклап, безнең якларга килергә әзер тор. Чакыру билетын декабрь башларында җибәрермен. Юбилей кичәсе 16 декабрьдә Техниклар йортында булачак. (Махсус төзелгән комиссия, зурдан кубып, әзерлек эшләре алып бара.)

Тагын менә нәрсә: Хәсән ага Хәйри «Шөгеровлар»га менә дигән рецензия язган. Рецензияне Дамир Асылов һәм башка иптәшләр белән бергәләп кычкырып укып чык-

тык. Хәзер, җиң сызганып, шул әсәр белән утырам. (1979 ел планына кертү турында синең исемгә гариза язган идем инде.)

Менә, Гарәф туган, язасы сүзләр шул гына иде. «Динозаврлар өнендә» дигән 2 табаклы повестьны (карап чыгып, машинкада бастырып) Шамилгә җибәрдем.

Кабат сәлам белән,

М.Хәсәнов.
Азнакай.
20.10.1977 ел.

ТУФАН МИҢНУЛЛИНГА

Туфан дускай, саумы!

Иң әүвәл үзеңә, шулай ук дус-ишләргә чуктин-чук сәламнәремне иңдерергә рөхсәт ит. Бу хат бәлки сине чак кына гаҗәпләндерер, дип уйлыйм. Тик бер дә исең китмәсен.

Мин, ниһаять, соңгы чиккә җиткерелдем, уннарча ел буена, тешләремне кысып булса да, түздем, ахыр чиктә сабыр канатларым сынды, «сынды кылыч, бетте көч», инфарктның бик начары белән егылдым, больницада ятам.

Хикмәт менә нәрсәдә: әгәр дә исән калып, чыга-нитә калсам, иң беренче КПСС Өлкә комитетына барам. «Үзегезнең партоешмагыз кайда иде?» – дип әйтмәсеннәр өчен, син дә белеп тор, Туфан. Менә алты ел инде нәшрият минем китапларымны чыгармый. (Күз буяу өчен чыгарылган вак-төяк брошюраларны санамыйча, әлбәттә.) Бүгенге көндә нәшриятта минем биш романым ята. Чыгу белән КПСС Өлкә комитеты тарафыннан (С.Хәким, Х.Хәйри, Р.Фәйзуллин һ.б.) кебек иптәшләрне кертеп, комиссия төзүен таләп итәчәкмен. (Биш әсәрем турында да уңай рецензияләр, матбугатта чыккан материаллар бар.)

Мине хәйран иткәне, кешелектән чыгарганы – бер уч, бер төркем сволочьларның гомеремне багышлаган, үзем өчен изгегә санаган олуг Татар әдәбиятында, ничек теләсәләр, шулай эшләүләре, күтләкләрчә алыш-биреш итүләре.

Гомеремдә кешегә этлек эшләмәдем, шулай булуга карамастан, бер төркем җирәнгеч вак җан (үзләренең тоткан урыннарыннан файдаланып) мине материаль яктан, мораль яктан юк итүне үзләренә максат итеп куйды. Көчләрен күрсәтәләр, янәсе! Әлеге эт җаннар, өлешчә максатларына иреште: мине аяктан ектылар, икенчедән, бүгенге көндә дару алырга да акчам юк. Үзем муеннан бурычта. Шуның өстенә әни рактан үләргә ята.

Билгеле, нәшриятта 1980 елда да «Шайтан малае» дигән ике хикәясе чыга, дип әйтүләре бар. Әмма аннан аласы акча Литфондка түләргә дә җитмәячәк. (Андагы бурыч – 300 сум.) Син, Туфан, мине дөрес аңла, хикмәт бер бурычта гына да түгел, иң гарьләндергәне, йөрәгеңә каләм очы белән кадап язган әсәрләреңне халкыңа җиткерә алмау. Һәм шундый чакта берәүнең дә әлеге җирбитләргә: «Җиткәндер бит, җәмәгать!» – дип әйтә алмавында.

Синең: «Мәхмүт, нәрсә телисең?» – дип соравың бар. Менә җавап. Мин «Шөгеровлар» дигән роман яздым. Аны Әлмәт бүлегендә тикшердек. Бик яраттылар. Моннан төп-төгәл өч ел элек (төзәтеп, эшен бетереп) нәшриятка китереп тапшырдым. Әсәр турындагы фикер нәшриятка да килеп җиткән иде инде. Шунда нәшрият директоры Г.Шәрәфетдинов бүлек мөдирләрен җыеп алды да: «Мәхмүтнең берничә әйбере бездә ята. Әйдәгез, «Шөгеровлар»га туктыйк», – дип тәкъдим ясады. Шулай иттеләр дә. Алай да Гарәф бер искәрмә ясаган икән әле: «Әгәр дә ки әсәр «Казан утлары»нда басылса, китап итеп чыгару бермә-бер җиңеләячәк», – диде. Аның ул шарты да үтәлде. Әсәрнең 1981 ел планына керүенә шигем юк иде. Идарәдә тикшергәндә дә: «Син бар»,

Күңелле мизгел: Мәхмүт Хәсәнов хатыны Мәрьям белән

– дигәннәр иде. Тагын алдадылар, тагын мыскыл иттеләр. Монда керер алдыннан гына, ниһаять, әйттеләр: күзеңә карап алдыйлар бит, беркатлы булма, алты ел буена әсәрләреңне кертмәделәр һәм кертмәячәкләр, диделәр. (Бу хәлләр турында Гариф Ахуновка язган хатым бар, зинһар, дип сорыйм, алып танышсаңчы. Күп нәрсәгә күзеңне ачачак.) Теләгем шул, Туфан, «Шөгеровлар»га договор төзеп, хатыныма чак кына аванс бирсеннәр иде. Югыйсә, гаилә бик аяныч хәлдә.

Туфан, ни өчендер, сиңа ышанам, ярдәм итәрсең, дип өмет итәм. (Үзеңә ярдәмгә Сибгат аганы чакыр, мин аңа әдәбиятыбызның намусы, вөҗданы итеп карыйм.) Әсәргә договор төзеп, хатынга бераз акча бирсеннәр иде. Югыйсә, мине тиз генә чыгармаячаклар. Бу больницадан (өйгә дә кертеп тормыйча) Васильевога алып китәчәкләр икән. Кыскасы, миңа беренче звонок бирелүе шулдыр...

Ярар, Туфан туган, бу сүзләрне мин сиңа, партоешма секретаре булудан бигрәк, олуг художник, чын кеше буларак язам.

P.S. «Көя күбәләге» турында кәгазь миңа да килде. Саба районының халык театры куйган булган икән.

Кабат сәлам һәм ихтирам белән,

М.Хәсәнов.
Зеленый дол.
30.7.1980 ел. ■

МИЛЛӘТЕМ, ДИП, ХАЛКЫМ, ДИП...

(Көндәлек язмалары)

Клара Булатова

13 сентябрь, 1993 ел

Көндәлегемне даими алып бара алмыйм. Хәерле булсын, җитешә алмау – минем иң зур җитешсезлегем. Башымда берничә әйбәт әйбер бар. Шуның хет берсен кәгазьгә төшерәсе иде, дим.

Үзем күптән җәннәтле,
Күршем өчен кайгырам...

Үз җәннәтем, дип язуым шуннан: үлеп бетә язган Туган телебез, әкренләп булса да, терелеп, тернәкләнеп килгән кебек, ләкин аны һаман «аякка» бастыра алмый изаланабыз.

Моннан нәкъ ике ел элек, ягъни 1991 елның көз башында, Әлмәтнең «Нур» («Луч») телекомпаниясе: «Атнага бер мәртәбә татар телендә 20-30 минутлык тапшыру оештыруда булышсагыз иде», – дип, безнең Язучылар оешмасына мөрәҗәгать иткән иде. Туган телгә, милли мәдәният, мәгариф, сәнгать хәрәкәтенә бәйле булган татар зыялыларыннан җиде кешене теркәп, үзенә күрә саллы гына редколлегия төзеп куйдык. Ул исемлектә «Нур»дан – В.Лавущенко, В.Ногманов, Язучылар оешмасыннан – Нур Әхмәди, Фәрит Гыйльми, Клара Булатова, сәхнә дөньясыннан Рузалия Солтанова (артистка Луиза Солтанованың бертуган сеңлесе) һәм Рәис Нәгыймов бар иде. Эш җәмәгатьчелек йөкләмәсе рәвешендә булгач, кабинеты, телефоны, хезмәт хакы юк, эше бар: сценарий язарга, татар телендә кешечәрәк сөйли белүчеләрне барларга, бер тиенсезгә экранга чыгып җырлардай фидакарь җаннарны табарга, төрле буын вәкилләренә йогынтылы-үтемле булсын иде, дип, шәһәр һәм авыллар буйлап чабарга кирәк. Кыскасы, бу түләүсез вазыйфаны, кыстый-кыстый, шагыйрә К.Булатовага тәкъдим иттеләр. Әй-йе! Анысы да монысы, дигәндәй... Сүзем шул атнага бер чыгып бара торган бүгенге «Җомга» турында. Дөресен әйткәндә, җан-йөрәктән кан саркыту хисабына бара бу эш. Асылда юк ул. Шөкер, шул «җилдән туган» «Җомга»ны яшәтүче «Нур» телекомпаниясе бар инде анысы...

Әйе, үзем күптән «җәннәтле», ә менә күршеләремә килгәндә... Алар хәле турында сөйли башласаң, «А!», «У!» «Ы!» һәм шундый башка ымлыклар гына чыга авыздан. Әлеге дә баягы шул «Җомга» тапшыруының берсендә, якташларыбызны бүгенге татар музыкасының кайбер яңарыш-төрләнеш үзенчәлекләре белән таныштырырга теләп, «Сөләйнефть» идарәсенең бер цехында «фатир» алып яшәүче «Сәйлән» ансамбленә мөрәҗәгать иткән идем. «Сәйлән»нең музыка җитәкчесе Ирек Кәримов һәм башкарма җитәкчесе Альберт Дәүләтов белән сөйләшүдән соң... чын-чынлап «күршем» өчен кайгырыр нигез бар булып чыкты. «Ерактагы кояш җылы» безгә, ә үзебезнең җирлектә туган сәнгать яралгысын үстерә, бәяли белүче юк. «Хәтер көне»ме, төзүчеләр көнеме яисә бүтән бер истәлекле чарамы – анда, һичшиксез, «Сәйлән» чыгыш ясый. Чөнки башкалар: «Бушка йөрергә без «Сәйлән» түгел!» – дип кенә җибәрәләр», – дип, җаны әрнеп сөйләде миңа Альберт Дәүләтов. Репетицияләре цехның бер кысан бүлмәсендә

Бер очрашу (сулдан уңга): Клара Булатова, Гамил Афзал, Гариф Ахунов, Ибраһим Гази, Гази Кашшаф

уза икән. «Уен кораллары да шунда саклана. Цех начальнигы Николай Александрович Пчельниковка зур рәхмәт! – диде Альберт туган. – Үзебезнең милләттәшләр күбрәк корсак һәм тамак туклыгын гына кайгырта шул...»

24 сентябрь

Россиядә Ельцин диктатура урнаштырмакчы булып маташа. Югары Советны куып таратмакчылар... Халыкка... аңа тегесе ни дә, бусы ни...

7 октябрь

Педучилищеда татар әдәбиятыннан кереш дәрес үткәреп кайттым. Тугызынчы сыйныфны бетереп килгән ике төркемдә 60 бала: 59 кыз һәм 1 малай. Арада, әлбәттә, төрлесе бар. Рус мәктәпләреннән килүчеләр байтак. Алар белән җиңел булмастыр, хәерлегә булсын!

13 октябрь, чәршәмбе

Һич көтмәгән-уйламаган җирдән Фәрит Гыйльми вафат булды. И Алла! Иллесенә әле ерак ирдән ятим калды бүген дүрт бала.

Кайчан гына, май аенда
Шушы зират өстендә:
«Кемдә чират таягы?» – дип,
Әйткәннәрем исемдә.

Чиратын да көтеп тормый,
Саташыпмы, хәл итте:
Көтмәгәндә алып китте
Ир уртасы Фәритне.

Кичә генә исән кеше...
Баш түнәрлек, җан яргыч...
Дүрт баланы ятим итте
Аянычлы бу язмыш.

Ниләр диик? Мондый чакта
Бер ифадә халыкта:
Калганнарга сабырлык бир,
Киткәннәрне ярлыка.

15 октябрь, җомга

Кичә Фәрит Гыйльмине Бигәш зиратына җирләп куйдык. *(«Татар әдипләре» китабында Ф.Гыйльминең үлгән вакыты һәм кайда җирләнүе дөрес күрсәтелмәгән: «1993 елның 16 октябрендә кинәттән вафат була. Кабере – Зәй районының Бигеш авылы зиратында», – диелгән. Чынлыкта, К.Булатова көндәлегендә теркәлгәнчә, әдип 13 октябрьдә вафат була, ә икенче көнне, ягъни 14ендә Әлмәт районының Бигәш авылы зиратында җирләнә. –* **Л.Л.***)*. Халык күп иде. Сарман, Мөслим, Азнакай язучылары да килде. Казан – юк...

19 ноябрь, шимбә

Бу җомгада, ягъни кичә була инде ул, Фәрит Яруллин исемендәге музыка училищесына багышланган тапшыруны («Җомга») экранга чыгардык. Аннан алдагысында колшәрипләрне биргән идек.

7 декабрь

Кайчандыр мукшы көенә язылган бер такмак килеп чыкты әле:

Каенана:
Әй син, килен, киленчәк,
Ник син шундый иренчәк,
Йон да эрли белмисең,
Он да или белмисең.
Мин әйткәнне, өйрәткәнне
Колагыңа элмисең.

Килен:
Әй, каенана, каенана,
Кызып китмә, кайнама,
Килен – каениш җиреннән,
Бу сыйфатым үзеңнән.
Йонны эрләп күрсәтсәң,
Онны иләп күрсәтсәң,
Телең белән телеп түгел,
Эшең белән өйрәтсәң,
Өйрәнермен үзеңнән:
Килен – каениш җиреннән.

12 декабрь, якшәмбе

Ниһаять, еллар буе ишетеп кенә белгән Әлмәт базарына чыктым бит әле бүген.

Сулдан уңга: Әзһәр Габиди, Шамил Бикчурин, Азат Ганиев, Гамил Афзал, Җәмит Рәхимов, Дамир Гарифуллин, Фәрит Гыйльми, Хәниф Хәйруллин, Фоат Садриев, Рафаил Төхфәтуллин.1986 ел

Искитмәле яңалык инде бу безнең гаилә өчен. Айлар буе тиенләп җыя торгач, 184 мең сум акча туплаган идем, әтиләре *(Нәфис – К.Булатованың ире. –* **Л.Л.***) 100 мең кайтарып биргән иде. Бүген шуны Марсның (шагыйрәнең улы. –* **Л.Л.***)* куен кесәсенә салып, бәләкәй Маратны *(К.Булатованың оныгы. –* **Л.Л.***)* Зурага калдырып, өчәүләп базар йөреп кайттык. Чыгымны юри генә теркәп куйыйм әле:

1. Миңа – чәшке бүрек: 133 мең сум *(140 мең сорадылар)*;
2. Маратка – аю: 25 мең *(28 мең сорадылар)*;
3. Зөлфиягә – күлмәк: 49 мең *(50 мең сорадылар)*;
4. Алма (3,5х600): 2,1 мең;
5. Чикләвек: 3 мең;
6. Шоколад (2х500): 1 мең;
7. Балага – питание (2х600): 1,2 мең.

Барлыгы: 213 мең 300 сум.

Саташып бетәрсең!.. Кыскасы, кесәдә 55 мең сум акча калды. Яңа ел өстәленә кайтасы пакет-букчаларга бер 20-30 мең җитсә, элегрәк алган токмач әрҗәсе өчен 9600не түләсәм, иншаллаһ, Яңа елга бурычсыз кереп булыр, дип өметләник.

Әллә заман үзгәргәнгә,
Әллә язмыш көлгәнгә,
Бөтен нәрсә үзгәләнә
Яңа елга кергәндә.

Менә шушыдыр инде ул – килеп җитү, барып чыгу, килеп терәлү дигәннәре!..

Әлмәт.

Шагыйрә К.Булатованың көндәлеген, авторның рөхсәте белән,
Л.Лерон укыды. ■

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

Кыңгыраулар җыры

(Балалар әдәбияты секциясе утырышы)

27 гыйнвар, 1966 ел.

Утырышта катнашалар: *Абдулла Әхмәт, Самат Шакир, Газиз Мөхәммәтшин, Роза Хафизова, Я.Гыйльметдинова, Зуммер Гыйлаҗев, Мәсгуть Латыйфуллин, Габделхәй Сабитов, Сарьян Хәсәнов (Хәсән Сарьян) һ.б.*

Көн тәртибе:

1. Роза Хафизованың «Кыңгыраулар җыры» исемле хикәяләр җыентыгын укып тикшерү.

2. 1966 елның 1 нче кварталына эш планы белән танышу.

Мәсгуть ЛАТЫЙФУЛЛИН:

– Гомумән алганда, җыентык миңа ошады. Ул мәктәпкәчә яшьтәге балаларга багышланган. Хикәяләр уңышлы, үзенчәлекле. Мәсәлән, «Песнәк» хикәясе. Матур язылган. Соңгы абзац кирәк түгел, ул артык. «Бал кортлары нигә ачуланды» хикәясе дә ярыйсы, ләкин аны бераз эшлисе бардыр.

«Рөстәм этисенә әйтә» исемле хикәя русча чыккан бер хикәяне хәтерләтә. Аны үзгәртәсе бар. «Сикертән» – матур хикәя. «Сыерчыклар килгәч» хикәясе дә уңышлы. Ләкин тиеннең койрыгы өзелү вакыйгасы авыррак кебек. Зәмзәм суы, пәрәнҗә кебек сүзләр кирәкмәс иде. Бу хикәядә табигать бик матур сурәтләнгән.

«Балыкчы Зәмзәм» исемле хикәя шулай ук кызыклы, анда да табигать күренеше бар.

«Гөлчәчәк» хикәясе йомшак. Аны җыентыкка кертү кирәк түгелдер. Хикәяләрдә бертөрлелек сизелә.

Гомумән, җыентык матур, секция исеменнән нәшриятка тәкъдим итәргә кирәк.

Газиз МӨХӘММӘТШИН:

– Бездә пионер тормышы турында хикәяләр әз. Кече яшьтәгеләр өчен тагын да әзрәк. Хафизованың бу хикәяләре бик матур. Анда табигатьне танып белергә өйрәтү бар. Мин хикәяләрне тәкъдим итү ягында.

Р.Хафизова *үзенең кайбер хикәяләрен укып китә.*

Габделхәй САБИТОВ:

– Хикәяләрдә сюжетка табигый рәвештә бәйләнми торган урыннар бар. Мәсәлән, «Рөстәм этисенә әйтә» исемле хикәясендәге күлмәк вакыйгасы. «Төймәләр» хикәясен эшлисе бар. «Кыңгыраулы койрык» хикәясе уңышлы түгел. Ясалма. Койрыкта кыңгыраулар булуы аеруча ясалма.

Самат ШАКИР:

– Хикәяләр танып-белү ягыннан әһәмиятле. Мәсәлән, «Рөстәм этисенә әйтә» хикәясендә автор файдалы фикерләрне бик образлы итеп әйтеп бирә. Минемчә, күлмәк вакыйгасы хикәядә урынлы алынган.

Тиеннең койрыгы мәсьәләсе дә начар түгел. Рус әдәбиятында андый характердагы

Роза Хафизова

Хәсән Сарьян

Госман Бакиров

әйберләр бар. Дөрес, танып-белү ягына ныграк басым ясалган булса, яхшырак булыр иде. Ләкин мондый хикәяне дә инкарь итәргә ярамый. Мин бу җыентыкны киләсе ел планына кертергә тәкъдим итү ягында.

Сарьян ХӘСӘНОВ (Хәсән Сарьян):

– Хикәяләр миңа ошады. Нәшриятта чыккан хикәяләргә игътибар иткәндә, яхшы хикәяләр бик аз. «Кыңгыраулы койрык» хикәясе миңа барыннан да ныграк ошады. Тиеннең койрыгында кыңгыраулар булу да начар түгел.

Күлмәк вакыйгасы чыннан да урынсыз. Русчадан кергән сүзләр бар. Сүзләрнең яңгырашына да игътибар бирергә кирәк.

Абдулла ӘХМӘТ:

– Роза Хафизова чыннан да хикәя язуның серенә төшенә башлаган. Күлмәк вакыйгасы чыннан да урынсызрак, ләкин аны аңлап була.

Госман БАКИРОВ:

– Бездә чыннан да кыска, җыйнак хикәяләр бик аз. Роза Хафизова хикәяләрендә сюжетка ялганып җитмәгән урыннар, борылышлар бар. «Койрык» мәсьәләсе, минемчә, начар түгел.

Минемчә, җыентыкны, һичшиксез тәкъдим итәргә кирәк. Автор тагын берничә хикәя өстәсен иде.

Карар: *Хикәяләр җыентыгын, тагын бер кат эшләп чыккач, нәшриятның 1967 ел планына кертергә тәкъдим итәргә.*

План белән таныштырыла.

Председатель Госман Бакиров (имза)
Секретарь (Кем булуы билгесез)

Беркетмәне Ләбиб Лерон укыды. ■

Роза Хафизованың балалар өчен әкиятләре һәм тәрбияви эчтәлектәге хикәяләре тупланган «Кыңгыраулар җыры» исемле тәүге китабы 1967 елда Татарстан китап нәшриятында басыла **(Л.Л. иск)**.

Абдулла Алиш әкиятләренең басма вариантларындагы үзгәрешләр

(«Нечкәбил» һәм «Сертотмас үрдәк» мисалында)

Рамил Мозаффаров,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы



Абдулла Алиш – дөньяда аз гына яшәп тә, фидакарь иҗади эшчәнлеге, Ватанга тугрылыгы һәм батырлыгы белән халык күңеленә кереп калган шәхес. Әгәр сугыш булмаса, талантлы каләме белән халык күңеленә тагын никадәр матурлык орлыклары чәчәр иде ул.

А.Алиш – татар балалар әдәбиятына саллы өлеш керткән әдипләрнең берсе. Аның чын таланты әкиятләр жанрында ачыла. Әдип әкиятләрнең балаларга тәэсирен, бу нигездә тәрбияләүнең халык педагогикасында иң отышлы алымнарның берсе булуын аңлап эш итә. Әсәрләре аша ул сабыйлар күңеленә үтеп керә, аларга тәрбия бирә. Әкиятләрен бүген дә бик яратып укыйлар. Мәктәп программасына аның «Сертотмас үрдәк», «Чукмар белән Тукмар», «Нечкәбил», «Мактанчык чыпчык һәм тыйнак сыерчык», «Койрыклар» кебек әсәрләре кергән.

Язучы бала психологиясенең бөтен нечкәлекләрен өйрәнеп, алар белән якыннан аралашып иҗат итәргә тырышкан. Аның әкиятләре һәркемне сокландыра, укучыларны үз дөньясына тарта, мавыктыра, балаларда тырышлык, хезмәт сөючәнлек, ярдәмчел булу, һәр эшне җиренә җиткереп эшләү кебек сыйфатлар тәрбияли.

Әдипнең әсәрләре уку өчен кызыклы, җиңел, аһәңле, ритмлы. Әкиятләрен иҗат иткәндә, Алиш үзен шагыйрь итеп тә таныта. Кыска җөмләләрдә олы, тирән фикер әйтелә. Болар барысы да аны прозадагы шагыйрь итеп күрсәтә. Әйтик, «Аерылсагыз, айга җитмәссез, бүленсәгез, бүген бетәрсез» («Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар»), «Серең эчеңдә торса, йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр» («Сертотмас үрдәк»), «Мактану зарар гына итә, сизгерлекне киметә; Мактану һәркемне хур итә, тыйнак булуга ни җитә!» («Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык»).

Әдипнең күп әкиятләре хайваннар тормышыннан алып язылган. Аларда хайваннар һәм кошлар, бөҗәкләр дөньясы сурәтләнә. Алар, үзләренә хас табигый сыйфатлары белән бирелгәннәр, шулай ук аларда кеше характерында була торган үзенчәлекләрне дә күреп була.

Алиш еш кына әкият исемнәрен халыкның мәкаль-әйтемнәренә нигезләнеп куя, контрастлыкны, парлы төшенчәләрне актив куллана. Мәсәлән, «Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык», «Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык», «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» һ.б. Бу әйтергә теләгән фикерне тагын да үтемлерәк итеп җиткерергә ярдәм итә.

Әдип әкиятләренең күпчелеге чагыштырмача кечкенә күләмле булуы белән аерылып тора. Мәсәлән, «Куян кызы», «Чукмар белән Тукмар», «Бикбатыр белән Биккуркак» һ.б. Үзәктә бер сюжет сызыгы гына, әмма гади генә вакыйга һәм детальләргә дә тирән мәгънә салынган. Ул әсәрләр бай эчтәлекле, тематик яктан төрле, тормышка якын булулары белән дә аерылып торалар. Аларда вакыйгалар мавыктыргыч, кызыклы сурәтләнә, тиз укыла һәм җиңел хәтердә кала. Композицион яктан охшашлыклар да бар. Мисал өчен, «Сертотмас үрдәк» һәм «Нечкәбил» әкиятләрендә төп геройларның төрле җәнлекләр, бөҗәкләр белән очрашуы композицион дәвамлылык белән аңлатыла.

А.Алиш әсәрләрнең художество эшләнешенә зур игътибар биргән, кат-кат төзәткән. Язган әкият һәм хикәяләрен бастырып чыгарганчы, аларны дусларына, йә балаларга

укып фикер алышуны гадәткә керткән. Яңадан редакцияләнгән китаплар, әсәрләр, әлбәттә, тел-стиль ягыннан камилләшүгә юл тота, әмма эчтәлектәге үзгәрешләр язучының үзенә генә бәйле булмаска да мөмкин. А.Алиш әкиятләренең беренче басмаларын чагыштырмача соңрак чыккан (автор һәлак булганнан соң) җыентыклары белән чагыштырып күзәтү ясагач, моның дөреслегенә инандык.

«Нечкәбил» әкиятен әдип 1935 елда яза һәм ул беренче тапкыр аның «Әкиятләр» (1937) исемле җыентыгында дөнья күрә. Шул ук елны исә «Нечкәбил» әкияте төсле рәсемнәр белән аерым китапчык булып та чыга. Латин графикасындагы бу басманы без А.Алишның 1978 елгы «Әкиятләр, хикәяләр» җыентыгындагы текст белән чагыштырдык һәм төрле характердагы үзгәрешләрне таптык. «Үзгәреш» төшенчәсенә без кыскартылмаларны, фактик, стилистик, грамматик үзгәрешләрне кертеп карадык. Әйтергә кирәк, бу үзгәрешләр соңрак чыккан башка җыентыкларда һәм «Сайланма әсәрләр»дә саклана.

Язучы әкиятнең башыннан ахырына кадәр безне табигать белән таныштыра, матурлыкны күрергә өйрәтә. Нечкәбил образы аша автор балаларны тату яшәргә, эшчән булырга, табигатьнең матурлыгын күрә һәм аны саклый белергә өнди. Шунысын әйтергә кирәк, А.Алишның элегрәк язылган «Отряд умартасы» (1929) хикәясендәге бал кортларының агачка саруы, аларны тубалга җыю, лимон мае сөртү кебек күренешдетальләр «Нечкәбил» әкиятендә дә кабатлана. Гомумән, әкияттә умартачылыкка бәйле күп мәгълүмат җиткерелә һәм авторның бу һөнәр белән якыннан таныш булуы ачык чагыла.

Соңрак чыккан басмаларда әсәр тукымасыннан аерым сүз-җөмләләрнең генә түгел, ә кечерәк абзацларның да төшеп калуын күрдек. Әйтик, Нечкәбилнең бал (нектар) җыю күренешен сурәтләгән бу юллар хәзерге вариантта юк: «Кып-кызыл мәк чәчәгеннән дә бал ала. Ап-ак чәчәкле борчакка да туктала. Сап-сары «әбием башмагы» чәчкәсенә дә куна. Кызыл тукран башы чәчәген дә авыз иткән була». Югыйсә, бу өзектә болында үскән никадәр чәчәк исемнәре искә алынган.

А.Алишның «Сертотмас үрдәк» әкиятенә килгәндә, биредә шулай ук текстны җыйнакландыру максатыннан (бәлки) ясалган кайбер кыскартылмаларны очраттык. Сер саклый белмәүнең бәлагә илтүен искәрткән әкият беренче басмада: «Ерактамы – анысын белмәдем, якындамы – анысын күрмәдем, безнең киң илебезнең бер почмагында бер аучы яшәгән», – дип башланып китә.

Шунысы үзенчәлекле, язучының «Әкиятләр» (1939) җыентыгында беренче тапкыр чыккан бу әкиятнең язылу елы итеп 1937 ел күрсәтелгән. Башка басмаларда ул 1938 ел белән билгеләнгән. Шулай ук тәүге чыганакта, башкалардан аермалы буларак, аучы этенең исеме дә бар. Ул – Актырнак. Әмма русча тәрҗемәләрдә бу факт сакланган. Әйтик, А.Бендецкий тәрҗемәсендәге китапта («Болтливая утка», 1983) «Белый Коготь» дип бирелә.

Кыскасы, А.Алиш әкиятләренең беренче басма текстлары белән соңрак чыкканнары арасында аермалар, үзгәрешләр шактый. Күләм ягыннан алар беркадәр кыскарганнар. Шуның нәтиҗәсендә, безнең уебызча, балалар өчен кайбер кызыклы булган детальләр, күренешләр югалган. Киләчәктә академик басмаларда болар исәпкә алыныр, дип ышанабыз.

Абдулла Алишның иҗат мирасына игътибар кимемәсен иде. ■

МӘКТӘП-МУЗЕЙ

14 февральдә Казандагы А.Алиш исемендәге 20 нче гимназиядә (директоры Рәхимә Минвәли кызы Арсланова) «Иске татар бистәсе» музее (әлеге гимназиядә бу – дүртенче музей) ачылды. Аны ачу тантанасында «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон һәм «Шәһри Казан» газетасы хезмәткәре, шагыйрә Йолдыз Шәрәпова чыгыш ясады. ■

Гимназия директоры, «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының Казан бүлеге җитәкчесе Рәхимә Арсланова

Фатих Сәйфи-Казанлы (1888-1937)

Язучы, тәнкыйтьче, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Фатих Сәйфи-Казанлы (Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин) 1934 елның августында Мәскәүдә узган СССР язучыларының I съездында Татарстан делегатларының берсе буларак катнаша. Ул бу съездан рухланып, үз сүзләре белән әйткәндә, «язучылык профессиясенең социалистик илне төзүдә җаваплылыкта инженердан, архитектордан, профессордан, җаваплы совет эшчесеннән – гомумән, җаваплы эшченең һичберсеннән ким түгеллегенә тирән ышанып», эшкә зур дәрт һәм яңа әдәби иҗат планнары белән әйләнеп кайта.

Ләкин яңа хакимияткә хезмәт итүне намус эше итеп санавына, тырышып совет идеологиясен пропагандалауга һәм аның сәясәтен гамәлгә ашыру өчен бөтен көч-сәләтен куюына карамастан, тоталитар режимның утызынчы еллар ахырындагы «олуг террор»ы Фатих Сәйфи-Казанлыны да үзенең тегермәнендә тартып чыгара.

Әдип 1936 елның 16 сентябрендә кулга алына. Кайчандыр эсерлар партиясендә әгъза булып торганлыгына нигезләнеп, аны хөкүмәт башлыкларына һәм партия җитәкчеләренә каршы һөҗүм әзерләүдә, милләтчелектә һәм башка шуның ише «җинаятьләр»дә гаеплиләр.

Бу уңайдан «Гасырлар авазы» журналының 2009 елгы 1 санында урын алган «Җәмәгать эшлеклесе Ф.Сәйфи турында ВКП(б) өлкә комитеты сәркатипләре А.К.Лепа һәм Б.А.Абдуллинга хәбәрдән» исемле мәкалә игътибарга лаек. Анда имзасы күрсәтелмәгән «хәбәрче», берничә пункт куеп, әдипнең «ялганнарын фаш итә»:

«1. Ф.Сәйфи татар буржуазиясенең контрреволюцион оешмалары булган Казан губерна Милли Шурасында һәм Идел-Урал штатын игълан итү буенча коллегиядә советка каршы эш алып баруын яшерде.

2. Үзен большевиклар ягында эшләгән сул эсер дип танытып һәм эсерлар партиясе белән үзе арасында булмаган низагны бар дип күрсәтеп, Ф.Сәйфи ничек тә татар

СССР язучыларының I съезды делегатлары. Ф.Сәйфи-Казанлы сулдан дүртенче басып тора. Мәскәү. 1934 ел

эсерлары оешмасында үзенең җитәкчелек итү һәм оештыру ролен, уң эсер булып торуын йомшартып күрсәтергә тырышты.

3. Ак чехлар идарәсе чорында Казанда яшәвен һәм актив конрреволюцияче Гомәр Терегулов[1] белән бәйләнештә булуын яшереп, 1929 елгы партчистка вакытында партияне ачыктан-ачык алдады.

4. Патша самодержавиесе йомышчысы[2] – мөфти С.Баязитов[3] сакчысына хезмәт итүен һәм «Мәгълүмат» мөселман диния мәҗлесе журналында эшләвен йомшартып (эшчәнлеген техник хезмәт башкару белән чикләп) күрсәтте.

5. Татар оешмасының «сул» төркемендә[4] актив катнашуын яшерде»...

Автор бу гаепләүләрне алга таба «дәлилләр» белән «ныгыта».

Ф.Сәйфи-Казанлы хатыны Абруй белән. 1920–1930 нчы еллар

Фатих Сәйфи-Казанлы шәхесенең фаҗигасе шунда ки: ул чордашлары өчен дә үз кешегә әверелеп бетми, киләчәк буыннар өчен дә «большевикларга сатылган хаин» булып кала.

1937 елның 3 августында СССР Югары Мәхкәмәсенең Хәрби коллегиясе ябык утырышта әдипнең «җинаять эше»н карап, аны иң югары җәзага – атарга хөкем итә. Хөкем карары ике көннән соң – 1937 елның 5 августында гамәлгә ашырыла. Күмелгән урыны Казанның Архангел зиратында, дип фаразлана.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: II том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.357.
2. Из донесения секретарям ОК ВКП(б) А.К.Лепа и Б.А.Абдуллину об общественном деятеле Ф.Сайфи. // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2009. – №1. – С.97-100.
3. Гыйззәтуллин Н. Үз заманының улы // Казан утлары. – 1998. – №3. – Б.185-186.

***Рүзәл Мөхәммәтша** әзерләде.* ■

[1] Гомәр Хәбибрахман улы Терегулов (1883-1938) – хокукчы, меньшевик, инкыйлабтан соң чит илгә чыгып китә.
[2] Оригиналда бу сүз «ставленник» дип бирелгән.
[3] Сүз җәмәгать һәм дин эшлеклесе Мөхәммәтсафа Гатаулла улы Баязитов (1885-1937) турында барганга охшый.
[4] Оригиналда бу сүз «группировщина» дип бирелгән.

Безнең мирас №3 март 2018

КАЛА ЮЛЫ
ЯКИ КАЧКЫН МАЛАЙ

Хәлим Җәләй

*Кала юлы белән барсаң, безнең авылдан (Балык Бистәсе районындагы Олы Солтан авылы турында сүз бара. – **Ред.**) Казанга хәтле җитмеш чакрым, диләр.*

Ә кала юлы авылның нәкъ уртасыннан, киң елга аша салынган кала күпере аша үтә. Машиналар йөри торган олы юл. Безнең авыл кешеләре, йомыш белән Казанга барганда, шушы юлдан бара, шушы юлдан кайта да. Кала юлы... Кала күпере... Зур тормышка алып чыга, киләчәккә алып бара торган күпер...

...Сугыштан соң әтиләре кайтуын көтеп үскән малайлар арасында бер җыр бик хутта иде. Әвеслек астында ясалган таганда атынганда булсын, кичләрен сыер ашатырга чыкканда булсын, бик еш җырлый идек без аны:

Безнең әтәч кукәй сала,
Кәрҗинкәне тутырып.
Безнең әти кайтыр әле,
Машинкага утырып.

Без көттек... Ни өчендер җәяү дә түгел, атка утырып та түгел, нәкъ менә «машинка»га утырып кайтырлар, дип көттек. Кояш баешына карап, әниләр көтте. Кайтсалар, кала юлыннан, кала күпере аша кайтырга тиешләр иде югыйсә.

Ә бит кайткаладылар. Берән-сәрән булса да, кайберләренең юллары бик urau булса да, бик көттереп кенә булса да кайткаладылар...

Әтиләр кайтуын көтә-көтә, мәктәпкә барыр чак җитте.

1947 елның 1 сентябренең салкынча аяз иртәсе иде ул. Каян юнәткәндер инде, әнкәй өскә яңа күлмәк-чалбар кигезде. Башта – абыйдан калган кепка, аякта – яңа галошлар.

Шулай пөхтә киенеп, мәктәпкә киттем. Әмма: «Беренче класслар төштән соң укыйлар», – диделәр. Мин, кире әйләнеп өйгә кайтканда, нишләптер, чишмә янынннан, су буеннан кайттым. Кайтканда яңа чалбарыма тигәнәкләр, сырганаклар ябышып беткән иде. Минем мәктәпкә беренче баруым әнә шулай уңышсызрак тәмамланды...

1949 ел. Октябрь урталары. Мин өченче класста укыйм. Безнең дәресләр төштән соң башлана. Беркөнне мәктәпкә барганда күрше малае Бәдамша дустым килә. Мәктәптән кайтып килеше. Алар иртәнге якта укый. Кулында яшелгә буялган таш сыбызгы. Минем кул да бөтенләй буш түгел. Ул чактагы сирәк «байлык» – кечерәк йодрык хәтле

Үсмер Хәлим

акбур ташы. Алыш-биреш тиз хәл ителде. Минем акбур Бадый (без аны ул чакта шул исем белән йөртә идек) кулына күчте, сыбызгы минем кесәгә шуды. Икебез дә канәгать булып аерылыштык.

Дәрес бара. Укытучы апа кара тактага нидер яза. Мин, кесәдән сыбызгыны чыгарып, сызгыртып та җибәрдем. Аграфена апа, борылып, миңа кисәтү ясады. Апа тактага борылуга, мин тагын... Бу юлы укытучы кисәтеп тормады, яныма очып диярлек килде дә (мин сыбызгыны партадашым Мансурга биреп өлгерә алмадым) минем кулымнан сыбызгыны тартып та алды. Ә бу минем өчен бик хәтәр нәрсә: бүген кичке якта, сыбызгыны тотып, Аграфена апа безгә төшәчәк. Өйдә мине нәрсә көткәнен күз алдыма китерәм... Нишләргә? Мансур белән киңәшләшәм. «Мине өйдә «үтерәләр» бүген. Укытучы апа төшкәнче, өйдән чыгып ычкынырга кирәк булыр. Тик кая? Чирмешәнгә таярмын, мөгаен. Безнең авылдан Чирмешәнгә ике чакрым. Анда безнең туганнар бар. Караңгы төшкәнче ничек тә барып җитәрмен. Бер тапкыр, әнигә ияреп, ул авылга барганым бар иде». Өйгә кайттым. Нәкыйп абый обой кәгазен әйләндереп өстәлгә салган да чиста ягына лозунг яза. Әни казан тирәсендә кайнаша. Өйгә тәмле аш исе чыккан. Урамда кояш, өйдә кояш, якты, җылы. Ә минем юлга чыгасым бар. Әни янына килеп: «Әни, ашарга берәр нәрсә юкмы?» – дип соравыма, ул: «Бар әле, бар, аяк астында чуалып йөрмә, менә хәзер аш өлгерә», – дип, сүзне кыска тотты.

Кояшлы, җылы көн кичкә авышып килә. Минем өстә бер төймәле чалбар, бер сәдәфле күлмәк, башта кепка һәм, әлбәттә инде, яланаяк. Бар булганы шул. Тәвәккәлләп

Әни абыйлар (артта басып төшкәннең уңдагысы – Нәкыйп абый) белән. 1951

киттем мин Чирмешәнгә. Авыл башындагы полосаны үттем. Әкренләп караңгы төшеп килә. Кичке салкын да үзен сиздерә, инде күз дә бәйләнә башлады. Мин шүрли калдым. Тугыз яшьлек малай төнлә япа-ялгыз кыр уртасында берүзе. Ә Чирмешән күренми дә күренми. «Беттем, адаштым, ахры», дигән курку биләп алды. Берәрсеннән ишеткәнем булдымы икән, әллә берәр китаптан укыганым булгангамы, мин колагымны җиргә куеп тыңлый башладым. Чыннан да, кайдадыр алда этләр өргәне, сыер мөгрәгәне, сарыклар бәэлдәве ишетелә сыман. Мин юлымны дәвам итәм. Ниһаять, алда, тау астында, утлар җемелдәве күренде. Эчкә җылы кереп китте. Мин инде йөгерә үк башладым. Авылга кергәч, чамалап барып, Бәдретдин җизниләрнең өен эзләп таптым.

Барып кергәч, җизниләр аптырап-гаҗәпләнеп калды.

– Кем белән килдең? – диләр.

– Үзем генә.

– Ә ник килдең?

– Сезне сагынып килдем, – дим.

Сорау алу озакка сузылмады. Кичке ашны ашарга әзерләнеп йөриләр иде, мине табын янына утырттылар. Тамакны ныгыткач, урын җәеп бирделәр. Уллары – минем яшьтәш Нуретдин белән йокларга яттык.

Иртән уянсак – өй эче яп-якты. Ә тәрәзәдән карасак!.. Бөтен дөнья ап-ак кар. Нәрсә инде бу? Авылга ничек кайтам мин хәзер? Җитмәсә, җизниләрнең бозауларын күрше Хвостово авылы урыслары ябып куйган. Нуретдин белән икәү шул бозауны алып кайтырга тиешбез. Аннан-моннан җыештырып киендерделәр. Инде чыгып китәбез,

дигәндә генә, ишектән капчык белән минем киемнәрне күтәргән Нәкыйп абый килеп керде. Беренче сүзе шул булды:

– Әһә, качкын малай монда икән!

Хуҗалар аптырашта калды, беразга утырырга, чәй эчеп алырга кыстасалар да, абый сүзен кыска тотты:

– Юк, юк, рәхмәт! Әйдә, киен тизрәк, әни көтә анда.

Кайтып барабыз. Җиңелчә генә кар сибертә. Эре-эре атлап абый бара, бер егерме метрлар калышып, мин теркелдим. Урамнан үткәндә, туганнар, күреп:

– Ә-ә, Хәлим килгән икән, бездә дә берәрне кунып китсен инде, – диләр.

– Булды, булды, бер кич кунды инде ул, – ди абый.

Өйгә кайтып җитеп, бусаганы атлап керүем булды... Әни! Чынлап та, бик көтеп торган икән. Елый-елый кирәкне бирде. Кыйнап хәле беткәч, бер тын алды да:

– Нәкыйп, китер чабата киндерәсен, сәндерә башына асам мин моны, – диде.

Ә минем котылу юлы бер генә – каравыл кычкыру. Ходай күпме тавыш биргән, бөтен көчемә акырам:

– Үтерәлә-әр, асала-ар, әни үтерә-ә!

Безнең өй авылның нәкъ уртасында, урам аша гына идарә йорты. Урамда туктаусыз кешеләр йөреп тора, ишетми калмаслар. Минем тавышны ишетеп, әлеге дә баягы Бәдамша килеп керде. Өйгә чит кеше кергәч, баланы кыйнау юк бездә, анысын беләбез. Мин көч-хәл белән исән калдым.

Ә эш болай була. Кичкә таба укытучы апа, сыбызгыны тотып, өйгә төшә. Ә мин – юк. Эзли башлыйлар – мин һаман юк. Караңгы төшә. Инде, борчылып, бөтен туганнар куба. Суга төшмәдеме икән, дип, тегермән буасыннан эзлиләр. Тирә-як күршеләр мәш килә. Әнинең йөрәге ничек түзгәндер инде, бичаракаем. Ярый әле кыйнап кына калды...

Соңыннан гына, бөтен кеше ыгы-зыгы килә башлагач кына, партадашым Мансур: «Хәлим ул, Чирмешәнгә таярмын, ахры, дип әйткән иде, шунда китмәдеме икән», – дип, туганнарны тынычландыра. Ә калганын инде сез беләсез...

***

Мәктәптә яратып укыдым. Миңа табигать кешедән артык сәләт биргәндер, дип һич әйтергә җыенмыйм. Ләкин мәктәптә чакта ук рәсем ясау, шигырь, шахмат, сәхнә белән җенләнгән идем. Боларга мәхәббәтне газиз укытучыларым тәрбияләгәндер, дип уйлыйм.

Укытучыларым, дип әйтүгә, иң элек Аграфена Малова апа күз алдыма килә. Хәреф танырга өйрәткән беренче укытучым! Нинди сабыр, нинди мөлаем, нинди кешелекле апа!..

Габдулла абый Яруллин! Миңа калса, аның бөтен бәхете, куанычы-максаты үзе укыткан укучыларны игелекле, эш сөючән, намуслы итеп тәрбияләүдә иде...

Мөрсәлимә апабыз Сибгатуллина сигезенче-унынчы классларда укыганда класс җитәкчебез булды. Яше белән бездән әллә ни олы булмаса да, без аны бик тә яраттык...

Габделфәрт абый Җамалиев, Наталья апа Крылова, Әминә апа Нәҗметдинова һәм башка укытучыларым минем күңелемдә иң изге затлар булып саклана...

Гомумән, безнең мәктәптә укучыларда сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүгә зур игътибар бирелгәндер. Роберт Әхмәтҗанов, Вакыйф Нуруллин, Кадыйр Сибгатуллин, Мидхәт Миншин, Әхәт Гаффар, Равил Шәрәфиев, Рауза Хәйретдинова кебек күренекле әдәбият-сәнгать осталары чыккан икән, бу сүзләрне мин ышанып язам. Полковниклар, очучылар, агрономнар, укытучылар, юристлар, табиблар һәм башка һөнәр ияләрен бирде ул Олы Солтан урта мәктәбе...

Мәктәпне мин 1957 елда көмеш медальгә тәмамладым. ■

Безнең мирас №3 март 2018

ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ!

ТАТАР СОВЕТ ЯЗУЧЫСЫ, ДРАМАТУРГ ДӘРҖИЯ АППАКОВАНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Дәрҗия Сәйфулла кызы Аппакова 1898 елның 2 мартында Уфа губернасының Минзәлә өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Түбән Кама районы) Байгол авылында ярлы крәстиян гаиләсендә туа. «Тапкыр егет» (1943), «Шүрәле» (1944), «Бишек җыры» (1946), «Илдус» (1947) исемле пьесалар авторы. Үзе исән чагында «Кечкенә Бануның тарихы» (1938), «Дүрт әкият» (1945) һәм «Шыгырдавыклы башмаклар» (1948) дигән китаплары дөнья күрә.

1948 елның 28 маенда Казанда фаҗигале рәвештә вафат була.

«Дәрҗия Аппакованы мин беренче тапкыр Матбугат йортында күрдем. Баскычтан төшеп килә. Сугыш елларының студент паегына яшәп, чүрәкәй үрдәк хәтле генә калган кызга ул олы, мәһабәт күренде. Өстендә, нинди мехтан булгандыр, ул чагында «манто» дип йөртелгән тун, башында каракул бүрек, бүрек өстеннән кызыл йон шарф салган.

Үзем шикелле үк әдәбият җене кагылган, буш вакыты булдымы, Матбугат йортының бишенче катындагы консультация бюросына шигырь тотып йөргергән иптәшем, ул үтеп киткәч:

– Дәрҗия Аппакова, – дип пышылдады.

Келт итеп «Кечкенә Бануның тарихы» дигән китап исемә төште...»

Ләбибә Ихсанова

ЯЗУЧЫ ҺӘМ ДРАМАТУРГ МӨХӘММӘТ ГАЛИНЕҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Мөхәммәт Гали (Мөхәммәт Мөхәммәтвәли улы Галиев) 1893 елның 24 (иске стиль белән — 12) мартында элекке Казан губернасының Лаеш өязе (хәзерге Балык Бистәсе районы) Олы Елга авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Башта атасы укыткан авыл мәктәбендә, 1903-1910 елларда үз авылыннан алтмыш чакрым ераклыктагы Сатыш мәдрәсәсендә, аннары Казанның Күл буе («Касыймия») һәм 1912 елдан 1915 елга кадәр Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. 1952 елның 6 маенда үпкә авыруыннан Казанда вафат була.

Басылып чыккан китаплары: «Кура җиләге җыю» (1921), «Балачак көннәремдә» (1925), «Кала кешеләре булдык» (1928), «Шагыйрь баскан эзләрдән» (1957), «Каюмның балачагы» (1958).

ТАНЫЛГАН ЯЗУЧЫ-ТӘРҖЕМӘЧЕ, ӘДӘБИЯТ БЕЛГЕЧЕ РӘИС ДАУТОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Рәис Нәүширван улы Даутов 1928 елның 15 мартында Мамадыш районының Шәмәк авылында мулла гаиләсендә туа. 1953 елның февраленнән 1989 елның мартына кадәр Татарстан китап нәшриятында эшли. М.Твенның «Янки король Артур сараенда» (1958), Ф.Куперның «Соңгы могикан» (1962), Ф.Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» (1974), А.Купринның «Атышу» (1976) дигән әсәрләрен, О'Генри новеллаларын (1979) тәрҗемә итә. 2007 елның 28 августында Казанда вафат була. Яңа бистә зиратына җирләнә.

«Миңа бер яшь чагында әтине, советка чит сыйныф вәкиле буларак, Архангельск өлкәсенә мәҗбүри эшкә сөргәннәр. Әни дүрт бала белән берүзе утырып калган. Мин белгәндә, кулакларга салына торган «каты налог» исәбенә йорт ихатасындагы бөтен каралты-кураны сүтеп саттырганнар, хәтта йорт яны бакчасын да кисеп алганнар иде инде. Алабута оны кушып пешерелгән икмәктән гайре башка ризык күрмәгән ул балалык еллары әле дә хәтердә саклана...»

Рәис Даутов

АТАКЛЫ БИЮЧЕ, БАЛЕТМЕЙСТЕР РУДОЛЬФ НУРИЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ



Рудольф Хәмит улы Нуриев 1938 елның 17 мартында Ерак Көнчыгышка – Владивостокка баручы поездда дөньяга килә. 1993 елның 6 гыйнварында Париж читендәге Леваллуа-Перре каласында вафат була.

«...Дөнья халкының теленнән бер исем төшми, ул да булса – Рудольф Нуриев. Аны теләсә кайсы кыйтгада беләләр! Нуриев – чын татар бренды, аны өлге итеп күтәргән очракта гына безне – татарларны җиһан таный ала. Рудольф, кая гына бармасын, кайда гына булмасын, сәбәбе чыгып та, сәбәпсезгә дә: «Мин – татар! Мин – татар!» – дип сөрән салган, шуның өчен бик зур рәхмәт аңа. Нуриев күптән, бик күптән һәйкәлгә лаек, ул һәйкәл коелса, безне тагын да күбрәк белә башларлар иде».

Рауль Мир-Хәйдәров ■

Безнең мирас №3 март 2018

САИМӘ ИБРАҺИМОВАГА 90 ЯШЬ

Саимә апа, дисәм...

Ләбиб Лерон

Саимә Ибраһимова. Февраль, 1977 ел

Саимә апа, дисәм... Әүвәл «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә бергә эшләгән чак келт итеп искә төшә...

1983-1984 еллар. Роза ханым Туфетулованың – баш мөхәррир, Саимә апаның исә җаваплы сәркатип вазыйфасын башкарган чагы. Җаваплы сәркатипнең әллә ни зур булмаган эш бүлмәсендә кеше өзелеп торганы юк: авторлар, каләмдәшләр, редакция хезмәткәрләре... Керәләр, чыгалар... Арада йомыш белән керүчеләр дә, болай гына – хәл белергә генә сугылучылар да бар. Йөз кеше – йөз төрле холык, дигәндәй... Редакциядә эшләүчеләргә генә кара син: һәрберсе – үзенчәлекле, кабатланмас шәхес: шигырь язу осталары – чын шагыйрьләр – Зөлфәт, Нияз Акмал, Госман Садә, хатлар бүлеге мөдире Илгизәр Сәмигуллина, фотограф Николай Седов, фән һәм спорт бүлеге мөдире Рәйсә Яхина, журналист һәм язучы Сәйдә Зыятдинова (Сәйдә Зыялы), пионерлар һәм мәктәпләр тормышы бүлеге мөдире Фирая Бәдретдинова, спорт темасына язучы журналист Атлас Гафиятов, киләчәктә прозаик булып танылу алачак Вакыйф Нуриев, редакция «үзе тудырган һәм үстергән» журналист Фоат Хәмидуллин, корректор Фирая Маликова, һәрвакыт нинди дә булса «мөгез» чыгарырга һәвәс булган рәссам Йосыф Вәлиәхмәтов, хатлар бүлеге хезмәткәре Фәридә Вәгыйзова, боларга өстәп – араларында иң яше булган мин бахырыгыз – Ләбиб Лерон... Кем әйтмешли, һәммәсе иҗат кешесе – һәрберсенә аерым «ачкыч» кирәк. Башкаларга мөнәсәбәте ничек булгандыр, белмим, әмма мин фәкыйрегезгә карата Саимә апа һәрчак игътибарлы, хәерхаһ булды. Таләпчән, әйтергә кирәк, вакыты белән үтә кырыс, үтә җитди. Ул мине беркайчан да тиргәмәде, ачуланмады, киресенчә, әниләрчә кайгыртучанлык күрсәтеп, тормыш иткәндә яисә язганда-сызганда файдасы һичшиксез тияргә тиешле киңәшләрен бирергә тырышты. Язуга нисбәтле бер киңәшен әле дә хәтерлим:

Илдар Юзеев белән Рәдиф Гаташ – «Яшь ленинчы» кунаклары: утырганнар (сулдан уңга) – Илгизәр Сәмигуллина, Роза Туфетулова, Илдар Юзеев, Саимә Ибраһимова, Рәдиф Гаташ; Николай Седов, Вакыйф Нуриев, Фәридә Вәгыйзова (бүлек хезмәткәре), Илгизә Садриева (машинистка), Рәйсә Яхина, Зөлфәт. 1980 нче еллар

– Ленарис («Яшь ленинчы»дагыларның һәммәсе дә миңа шулай дип дәшә иде), исеңдә тот: «хәбәрдар» сүзе җөмләдә, син әйткәнчә, «ул яңалыкларны укып хәбәрдар иде» дип түгел, ә «ул яңалыклардан хәбәрдар иде» дип языла. Онытма, «я-ңа-лык-лар-дан хәбәрдар»!

Саимә апа, дисәм... Урыс классигы А.П.Чехов, дөресрәге, Чеховның Саимә Ибраһимова тәрҗемә иткән «Хикәяләр»е (А.П.Чехов. Хикәяләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1980, 216 б.) хәтергә килә. Әлеге китапны мин университетның беренче курсын тәмамлап килгән көннәрнең берсендә – 1980 елның 17 маенда (җыентыкның алгы бер битенә шул датаны теркәп куйганмын) сатып алган идем. Шуннан бирле күп сулар акты, ләкин ул китап миңа әле дә хезмәт итә: вакыт-вакыт кулыма алам, тәрҗемәченең теленә – Чеховның татарча «сөйләвенә» соклана-соклана, әле бер хикәясен, әйтик, «Ураза алдыннан» дигәнен яисә икенчесен – «Курку» дип исемләнгәнен укыйм. Үзем укыйм, үзем Саимә апа тәрҗемәсендәге башка әсәрләрне – Р.Стивенсонның «Хәзинәләр атавы»н һәм М.Твенның «Том Сойер маҗаралары»н кайчандыр шулай бер тында укып чыкканымны искә төшереп алам. Ул да булмый, хәтергә Илдар абый Юзеев сүзләре килә: «Татарга тылмач кирәкми, диләр дә бит, кирәк шул, Рәис Даутов, Кыям Миңлебаев, Саимә Ибраһимова кебек тылмачлар бик тә кирәк!»

Саимә апа, дисәм... Әлеге дә баягы, дигәндәй, «Яшь ленинчы»да эшләгән вакытта, бертөркем шагыйрь-шогарә (арада Мөдәррис Әгъләм, Атлас Гафиятов булганлыгы аеруча истә калган), кумәкләшеп, Саимә апа белән Фатих абыйларның Займищедагы дачасына булышырга дип барганыбыз, яңа йорт бурасын күтәреп әвәрә килгән чакта Фатих абый белән Мөдәррис әкәнең, «ут яндырып» бәхәсләшә-бәхәсләшә, бура астына кырыкмаса-кырык кереп чыгуыннан үзебезчә тәм табып көлүебез, кичен хуҗаларның тыштан зур умарта оясын хәтерләткән сандугач оясыдай күркәм йортларында кунарга калуыбыз, өстәл янына җайлашып, чиратлашып – әле беребез, әле икенчебез төн уртасына кадәр Влас Дорошевичның «Сахалин. Каторга» дигән китабын кычкырып укуыбыз исемә төшә...

Саимә апа, дисәм... Сөембикә-ханбикә һәм «Сөембикә» журналы, дөресрәге, Саимә апаның шул журналда эшләгән чагында әлеге басманың ул вакыттагы баш мөхәррире Роза апа Туфетулованың («Яшь ленинчы»дан соң ул башта – «Ялкын»да (1986-1988), аннары «Азат хатын»да (1988-1999) баш редактор булып эшләде) тәкъдиме белән Сөембикә-ханбикә темасы белән шөгыльләнүе, мәшһүр бикәгә нисбәтле җыентык әзерләп йөрүе һәм соңыннан аны китап итеп бастырып чыгаруы хәтеремә килә. «Сөембикәгә бәйле берәр нәрсәң – шигырь-фәләнең юкмы?» – дип, Саимә апа миннән дә сораган иде, ни кызганыч, ниндидер сәбәпләр аркасында шигырьләремне үз вакытында тапшыра алмадым, китап 2006 елда минем «шедеверлар»ымнан башка гына дөнья күрде. (Китапның басылып чыгуында, әлбәттә, Роза ханым Туфетуловадан тыш, аның урынына «Сөембикә» журналына баш мөхәррир булып килгән Фирая Бәдретдинованың да өлеше зур.) Академик Мансур Хәсәновның (Саимә апаның ире Фатих абыйның энесе) кереш мәкаләсе белән ачылган, бихисап рәссамнарның рәсем-картиналары тупланган әлеге саллы китапта, Илдар Юзеев әйткәнчә, «Сөембикә турындагы антология»дә кайсы гына авторлар урын алмаган да, нинди генә әсәрләр кермәгән: күренекле галимнәр, дин эшлеклеләре Һ.Атласи, Р.Фәхреддин, М.Худяков, Г.Баттал, И.Рәмиева, язучы-әдипләр Ф.Әмирхан, М.Гафури, Г.Афзал, А.Тимергалин, Роберт Әхмәтҗан, Зөлфәт, М.Әгъләмов, М.Хуҗин, Р.Хәмид, Г.Зәйнашева, Р.Батулла, Разил Вәлиев, Р.Фәйзуллин, Р.Гаташ, Ф.Бәйрәмова, Ә.Рәшит, Э.Шәрифуллина, С.Шәмси, С.Зыялы, Илгаз Ваһап Нәүрүзхан, Музаффер Кайа (аның «Казан мәликәсе Сөембикә» пьесасын Саимә апа үзе тәрҗемә иткән), Р.Зәйдулла һ.б.

Китапта Саимә Ибраһимованың үз язмасы да урын алган. Шуннан бер өземтә: «*...бу мәшһүр шәхесебез турында үзем дә юньләп белми идем. Аның турында исә төрле сүзләр йөри. Ничә гасырлар элек яшәгән бу затның да бөеклеген күтәрә алмаучылар бар. Әмирхан ага Еникинең: «Үз патшасын үз кулы белән дошманга биреп җибәргән халык җирдә бүтән юк», – дигән сүзләре йөрәк түрендә тора. Ниндидер юлларын табып, ханбикәбезнең исләлеген, чисталыгын, сафлыгын акларга, сакларга кирәк иде...*»

Саимә апа, дисәм... аның биографиясендәге бер кызыклы факт (минем өчен бигрәк тә!) – Сарман районы Зур Нөркәй кызының Актаныш районындагы Пучы авылы мәктәбендә укуы, мәктәпне шул авылда 1946 елда уңышлы тәмамлавы турындагы «деталь» хәтеремдә калка. Ничәмә мәртәбә шул турыда Саимә апаның үзеннән сорыйм, дип йөри торгач, күптән түгел генә үземне кызыксындырган сорауга телефон аша җавап алу

Нурлыхода апа алты кызы (уңнан беренче – Саимә) янәшәсендә

Мәскәүдә укып йөргән чаклар: басып төшкәннәр (сулдан уңга) – Надежда Скрябина (Киров), Клава Слепцова (Орел), Мария Завитневич (Киев), Валерия Хршчанович (Рига), Шолпан Байбатшоева (Алма-Ата), Эмма Юрьян; утырганнар – Евдокия Плеханова (Таулы-Алтай), Клара Чулкова (Куйбышев), Вероника Волкова (Иркутск), Саимә Ибраһимова (Казан), Евгения Вишнякова (Барнаул), Ольга Колесникова (Краснодар). Мәскәү. 1952-1953 еллар



Кадерле Саимә!
Мин бүген бирәдә
15.00 кә чаклы һәм
18.00 дән соң булам.
Адресым: Неглинная,
гост. «Европа» к. 315
телефон да комм. аша шул ук
номер.
4/XII-52. Сәлам белән Кави

К.Нәҗминең С.Ибраһимовага язган запискасы. 1952 ел

бәхетенә ирештем. Саимә апа сөйли: *«Сугыш елларының ахырында минем апам Рәхимә («Вечерняя Казань» газетасының шеф-мөхәррире Хазбулат Шәмсетдиновның әнисе. Хазбулат, дигәннән... Әле генә исемә төште: Займищедагы «өмә» вакытында ул да бар иде. –* **Л.Л.***) Мөслим районы газетасының редакторы булып эшли иде. Көтмәгәндә аны Пучыга (элекке Калинин районының үзәге, хәзер Актаныш районына карый) редактор итеп билгеләделәр. «Анда үзем генә ничек яшәрмен, – дип борчылганга күрә, апага иптәш булып, Пучыга яшәргә һәм шунда укырга барырга туры килде. Редакция бинасының бер бүлмәсендә яшәдек. Миңа, мәктәптә укудан тыш, Рәхимә апага ярдәм итү йөзеннән, кичләрен газетаның «ирекле» корректоры да, «от Советского информбюро»дан көн саен килеп торган, дөресе, телефон аша тапшырыла торган хәбәрләрне (сводкаларны) кабул итүче дә булырга туры килә иде. «Комсомольская правда» газетасын мин шул чакта укый башладым...»*

Саимә апа, дисәм... Архивымда сакланган бер записка хәтеремне бимазалый башлый. Ул Кави дигән кешенең «тов. Ибрагимовой С.» дигән адресатка язган язуы: *«Кадерле Саимә! Мин бүген бирәдә 15:00гә чаклы һәм 18:00дән соң булам. Адресым: Неглинная, гост. «Европа», к.315 телефонда комм. аша шул ук номер. 4/XII. Сәлам белән Кави».* Елы – «52» саны сыек шәмәхә кара белән соңыннан өстәп язып куелган (Саимә апа үзе язган, ахры). Моңа да Саимә апа күптән түгел генә ачыклык кертте: *«Матбугат йорты – гомер китабы» дигән китапта минем «Гомер мизгелләре» дигән мәкаләм бар. Шунда барысы да әйтелгән,* – диде. Әлеге язмадан бер өзек: «Мин Матбугат йортында *(Бауман урамындагы 19 нчы йорт турында сүз бара. –* **Л.Л.***)* эшли башлаганда, әле

Фатих ага Хөсни янәшәсендә. Утырганнар (сулдан уңга) – Рәйсә Яхина, Фатих Хөсни, Саимә Ибраһимова; басканнар – Хәкимҗан Халиков, Зөлфәт. 1975–1979 еллар

Кави абый Нәҗми, Таҗи абзый Гыйззәтләр исән иде. Кави абыйның «Язгы җилләр»ен редакцияләргә туры килде. Ул чакта Кави абыйның эше бик тыгыз иде, редакторга кирәк булганда да ул нәшриятка килеп йөрмәде, миңа өйләренә килергә куша иде. Мин аларның хәзерге Кави Нәҗми урамындагы өйләренә барып йөрдем. Сәрвәр апа Кави абый турында бик җылы итеп сөйли иде...

Илленче еллар башында (микән?) «Советский комитет сторонников мира» дигән оешма бар иде. Ә Кави абый шул оешманың Татарстан Республикасындагы бүлеге рәисе иде. Мин Мәскәүдә укып йөргән чакта, әлеге оешманың конференциясе булды. Кави абый, шул конференциягә килгәч, мине үзе белән Зур театрга «Красный мак» балетын карарга алып барды. Аннары Кече театрда М.Горькийның әсәрен (кайсысы икәнен хәтерләмим) караганда елап утырганына шаклар каткан идем. Миңа ул, киң җилкәле, эре сөякле, олы башлы булгангадыр инде, бик олы кебек тоела иде. Шушы кеше елап утырсын әле!.. Ул аны миңа күрсәтмәскә тырышты инде.

Нәкъ шулчакларда бит инде «Язгы җилләр» өчен аңа Сталин премиясе бирелгән иде. Кави абыйның театрда миңа алып биргән тартмалы конфетларын, ачмыйча, менә лауреат язучыбыз (ул чакта алар сирәк бит әле) күчтәнәче, дип, гомуми торакка алып кайтып мактандым, иптәшләремне сыйладым...

Мәскәүдән кайткач та, мин Кави абыйларда еш була идем. Тик шунысы үкенечкә калды – Кави абыйны соңгы юлга озатуда була алмадым – районга укытырга киткән идем...»

Саимә апа, дисәм...

Кыскасы, Саимә апа белән бергә эшләү, аралашу вакытында булган бик күп нәрсәләр, вакыйгалар истә. Дөрес, күбесе хәтердән җуелгандыр да инде. Ә менә алда сөйләгәннәрем һич онытылмый.

5 февраль, 2018 ел

Редакциядән: *Язучы һәм тәрҗемәче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Саимә Ибраһим кызы Ибраһимовага 1 мартта 90 яшь тулды. Каләмдәшебезне күркәм юбилее белән ихлас котлыйбыз һәм аңа саулык-сәламәтлек, иминлек телибез!* ■

Кем ул Васил Әхмәтҗанов?

Үткән гасырның алтмышынчы-җитмешенче елларында безнең төбәктә Васил абый Әхмәтҗановны белмәгән кеше сирәк булгандыр. Ул – укытучы, музыкант, тәрбияче, агитатор, лектор һәм дивар газетасы редакторы... Иң гаҗәбе – ул көйләр яза белә иде. Мәкалә белән шигырьләрне инде аны үзебез дә әмәллибез: район һәм республика матбугаты битләрендә басылгалыйбыз. Ә менә нindидер койрыклы ноктaларны сызыкларга урнаштырып көй язучылардан, язылганнарга карап, гармунда яки мандолинада өздереп уйнаучылардан без берәүне генә – Васил абыйны гына белә идек. Безнең буын укучылары шуның белән бәхетле дә булгандыр. Ул елларда мәктәпләрдә иҗади фикер йөртүче укытучылар күп иде. Ни өчендер бу чорда әдәбият-сәнгать белән шөгыльләнү модага керде. Модага, дип... Ул шулай булырга тиеш тә сыман. Ничек инде мәктәп хәтле мәктәптә шигырь яза белүче яки музыка инструментларында уйнаучылар булмаска тиеш, ди. Без яшь вакытта кичке уеннарда гармунчылар чират көтеп тора иде. Ә хәзер гармунчыга чират. Бию һәм уеннарның нindиләре генә юк иде... Әби-бабаларыбызның борынгы гореф-гадәтләре бернинди плансыз-нисез сакланды, яшь буынның күңел түренә онытылмаслык булып урнашты.

Васил абый менә шул чорда безгә өлге булды. Ул безне җырларга, уйнарга, матурлыкны күрергә һәм тоярга өйрәтте.

Бәхеткә каршы, Васил абый үзе турында үзе язып калдырган. Үзен сагыначакларын, яшь буынның күңелендә кабат терелячәген аңлагандыр ул.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов,
шагыйрь, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты

Безнең мирас №3 март 2018

Автобиография

Васил Әхмәтҗанов

Мин, Әхмәтҗанов Васил Миркасыйм улы 1933 елның 29 ноябрендә Мөслим районының Түреш авылында колхозчы гаиләсендә туганмын. Башлангыч белемне Түреш авылында, ә җидееллык белемне Кубәк мәктәбендә алдым. Шуннан соң, ягъни 1948-1952 еллар арасында, Минзәлә педагогия училищесында укып, аны уңышлы тәмамладым.

Үсмер Васил

Кече яшьтән үк музыка, җыр яраттым. Гармун тавышын сәгатьләр буена бик теләп тыңлый идем һәм үзем дә гармунчы булу турында хыялландым. Ләкин ул авыр сугыш еллары иде. Әти-әнием миңа гармун алып бирә алмады. Укытучы булып эшли башлагач кына, үз гармуным булды.

Училищеда музыка грамотасына өйрәндем. Җыр һәм музыка иң яраткан дәресләрем иде. Бу фәннәрдән мин «5»ле билгеләренә генә укыдым. Беренче укыту елында ук инде җыр-музыканы үземнең эшем белән бәйләп җибәрдем. Миңа драмтүгәрәк белән җитәкчелек итүне тапшырдылар. Яраткан эшем шулай башланып китте. Яңа җырлар өйрәнү, укучыларны концертка әзерләү барлык буш вакытымны ала иде. Унбер ел укыту дәверендә мин җитәкчелек иткән драма түгәрәкләре бик яхшы концертлар бирде.

Үзешчән сәнгать бәйгеләрендә район күләмендә беренче яки икенче урыннарны алып килдек. (Барлыгы өч авылда укыттым һәм һәр авылда мин бу эшне алып бардым). Кубәк авылында эшләү чорында мәктәпнең драмтүгәрәген грамота белән дә бүләкләделәр. Мәктәптә эшләвемнең өченче елыннан җыр фәнен укытуга керештем. Башта җыр фәне башлангыч классларда гына укытыла иде, аннан соң эшемне бишенче-сигезенче классларда да дәвам иттем.

Үземнең унбер ел укыту чорымны җыр һәм музыкадан башка һич күз алдына китерә алмыйм. Соңгы ике елда үз классымны музыка грамотасы белән таныштыра башладым. Укучыларым һәммәсе дә диярлек мандолиналар алды, нота буенча бу инструментта уйнарга өйрәнде. Шул ук вакытта алар гармун белән дә кызыксына, яртысыннан күбесе гармун алды һәм уйнарга өйрәнеп килә. Шулар исәбендә кызлар да бар. Минем класс концертын ата-аналар һәм яшьләр яратып карый. Бик матур уйнаучылар һәм җырлаучылар бар. Бер укучым (Баязитов Әслах) быел июнь аенда Казанда радиокомитетта ике җырын яздырып кайтты («Уфа – башкалам» һәм «Ана сагышы» җырларын).

Укучыларның җыр һәм музыканы яратулары һәм һәрвакыт шулар белән шөгыльләнүләре аларның фәннәрне үзләштерүләренә һич комачаулык итми. Киресенчә, мин аны алга этәргеч көч дип саныйм. Бу балаларны өченче класстан алып укыта баш-

«...Васил Әхмәтҗановның (Мөслим) «Түгәрәк күл», «Зөһрә» җырларында вокальне дөрес аңлау, аның үзенчәлекләрен тулысынча файдалана белү күзгә бәрелә».

Бату Мөлеков,
композитор.

лаган идем, быел инде алар – 7 нче сыйныфта. Өченче классны тәмамлаганда өлгермәүче укучыларым бар иде. Инде дүртенче класста андыйлар булмады. Шушы елны класс «Җидееллык юлдашы» исемен яулап алды, бу мактаулы исемне алар бүгенге көнгә кадәр горур йөртә һәм саклый. Шул вакыттан бирле, минем класс мәктәп күләмендә һәрбер

эштә һәм ярышта беренче урынны алып килде. Быел иң яхшы отряд өчен барган Бөтенсоюз ярышында дружина күләмендә беренче урынны яулап алдык. Дирекция классны мәктәп хисабына Казанга экскурсиягә җибәрде. Үземнең хезмәтемне дә искә алалар. Укытучы булып эшләү дәверендә өч мәртәбә Мактау кәгазе һәм грамоталар белән бүләкләндем, телдән һәм язма рәвештә күп кенә рәхмәтләр алдым. Узган уку елында «Халык мәгарифе отличнигы» дигән мактаулы исемгә лаек булдым.

Укучыларны җыр һәм музыкага өйрәтү белән бергә, үзем дә бу өлкәдә өзлексез өйрәнәм. Унбер ел эчендә дүрт мәртәбә белем күтәрү курсларында булдым: икесе – җыр, икесе математика буенча (мин бит математика да укытам). Татар халык көйләренең төзелешен өйрәндем, аннан композиторларыбызның эш алымнары белән кызыксындым. 1955 ел башларыннан үзем дә көйләр яза башладым. Шул елның җәенә унлап көй яздым (сүзләре дә үземнеке – шигырь язу белән училищеда ук шөгыльләнә идем) һәм, Казанга алып барып, композитор А.Вәлиуллинга күрсәттем. Билгеле, минем кимчелекләрем күп булды. Бер генә көем дә югары бәя ала алмады. Иптәш Вәлиуллин миңа һаман өйрәнергә, эзләнергә кушты. Беренче мәртәбә композитор белән очрашуым һәм аның эшлекле тәкъдимнәре, өйрәтүләре миңа чын этәргеч бирде. 1956 елның җәендә мин тагын Казанга бардым һәм бу юлы А. Ключаревка туры килдем. Ул минем яңадан төзәтеп эшләгән көйләремне карады, уңай бәя бирде. Унбиш көй алып барган идем, шуларның икесенә «5»ле, икесенә «+4»ле, берсенә «4»ле билгесе куйды һәм музыка училищесына керергә тәкъдим итте. Бу елны мин училищега имтихан бирдем, ләкин, гаилә хәле белән, укырга бара алмый калдым. Шул елны мине Халык иҗаты йорты үзешчән композиторлар союзына әгъза итеп кабул итте.

Ел саен үзешчән композиторлар семинарларына барып, җыр һәм музыка буенча белемемне арттырам. Узган уку елында Мәскәү сәнгать университетында музыка факультетының унбиш айлык теория курсын читтән торып тәмамладым һәм таныклык алдым. Быел ике еллык гармония курсына керергә әзерләнәм.

Музыка буенча белемне системалы күтәрә бару иҗат эшенә дә зур йогынты ясый. Соңгы вакытта көйләремне күбрәк ике тавышка һәм хор өчен яза башладым. Баштарак куплет формасындагы гади лирик җырлар гына язсам, хәзер туган ил, партия һәм балалар өчен дә җырлар иҗат итә башладым. Үзешчән композиторлар семинарларында яхшы бәя алган һәм үзем яхшы дип тапкан ике дистәдән артык җырым бар. Шуларның бишесе (дүртесе үземнең сүзләр белән) матбугатта чыкты инде. 1961 елны ук Иҗат йорты җыентыкка дип берне алган иде, анысын басылачак, диләр. Тагын тикшерелгән дүрт җыр бар. Шагыйрь Зәки Нурида аның сүзләренә язылган өч җыр басарга рөхсәт алынган килеш ята. Мине соңгы вакытта укучылар һәм пионерлар темасы

«Васил Әхмәтҗанов белән комсомол конференциясендә таныштык без. Якташлар булып чыктык: күрше Түреш авылыннан икән яңа танышым. Ә мин Октябрь авылында мөгаллимлек итәм.

Конференция тәмамлангач, минем атка утырып, Иске Карамалыга хәтле бергә кайттык. Юлда сүзебез күбрәк кызлар турында булды. Бер матурның фотосын күрсәтте. Фәридә исемле, ди. Ворошилов (хәзерге Сарман) районыннан, күренекле методист, күп дәреслекләр авторы Мәрьям Галләмованың кардәше икән.

Минем тәкъдим белән, Васил безнең мәктәпкә эшкә килде. Ул бик оста гармунчы, өздереп мандолинада уйный, үзе көйләр дә яза. Казанга радиога барып, берничә җырын яздырып та кайтты. Аларны Нәҗия Теркулова башкаруында тапшырганнарын әле дә хәтерлим.

Дустым озакламый Фәридә Мансуровага өйләнеп тә куйды. Бик тату яшәделәр. Берсеннән-берсе матур биш бала үстерделәр. Ни кызганыч, бик иртә китте Васил якты дөньядан, әле аңа яшисе дә яшисе иде».

***Ягъсуп Мортазин*[1].**

[1] Ягъсуп Мортазин озак еллар Мөслим районының Октябрь авылында укытучы һәм мәктәп директоры булып эшләде. **(Ред.)**

ныграк кызыксындыра. Аларның бәхетле балалыкларын һәм эшчәнлекләрен чагылдырган җырлар язасым килә.

Укучылар өчен язылган җырларымны башта үзебезнең мәктәп укучыларына өйрәтәм. Алар минем «Яшь пионерлар маршы», «Орденлы Татарстан», «Звонок чакыра» кебек җырларымны яратып җырлый һәм күрше мәктәп укучыларына да өйрәтә.

Безнең мәктәптә дүрт йөз чамасы укучы белем ала. Мин бу мәктәпкә 1959-1960 уку елында килдем. Үземнең мандолинам ватылу сәбәпле, миңа инструмент эзләргә туры килде. Мәктәптә ул юк иде. Янәшә торучы ике зур авылдан бик озак эзләгәннән соң гына, мин бер иске мандолина таба алдым. Дүрт ел эчендә кискен үзгәреш булды. Хәзер мәктәпнең үзенең егерме биш мандолинасы бар. Укучыларның да җитмештән артыграгы мандолиналар алды инде. Быел аларның саны йөз илледән дә артачак, ә якындагы ике-өч елда безнең һәрбер укучыбызның үз мандолинасы булачак. Мәктәп якын арада кыллы оркестр алырга планлаштыра.

Укучылар җыр дәресләрен көтеп ала. Бу дәрес керәчәген алар иртән әти-әниләренә үк әйтеп килә һәм аларны концерт-дәресләргә чакыра. Дәресләрем, гомумән, күңелле уза. Беренче класстан ук җыр өйрәтү белән бергә, укучыларга музыка грамотасы һәм нота буенча җырлау күнекмәләре бирә башлыйм. Гомумән, мин дәресләремне программада таләп ителгәнчә алып барырга һәм иҗади итеп оештырырга тырышам. Ике ел инде җыр фәне буенча алдынгы тәҗрибә мәктәбе җитәкчесе булып эшлим. Август һәм гыйнвар киңәшмәләрендә җыр дәресен укыту буенча җыр укытучыларына докладлар сөйлим, яңа җырлар өйрәтәм.

Күп кенә еллар пропагандист һәм комсомол оешмасы секретаре булып эшләдем, соңгы елларда колхозның гомуми стена газетасы редакторы, фәнни һәм политик белемнәр тарату җәмгыятенең Иске Карамалы авыл группасының бюро председателе дә. 1959 елның февраль аеннан алып КПСС члены. Үземнең җыр укыту тәҗрибәмне тарату өстендә эшлим. 1961 елдан бирле «Совет мәктәбе» редакциясенә мәкаләләр һәм үземнең көйләремне җибәреп торам. Җыр фәнен укыту буенча методик кулланма язарга рөхсәт сорап, Укытучылар белемен күтәрү институтына хат язган идем, әле җавап юк. Брошюра итеп чыгарырга иде, җыр укыту буенча кулланмалар бер дә юк бит.

ӘТИЕМ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Без гаиләдә биш бала үстек. Безнең өчен әти-әниебез һәрьяклап үрнәк булды. Аларның бер-берсен аңлап, кайгыртып, яратып яшәүләре өйне җылы, рәхәт итә иде. Тик бу бәхет озак булмады. Без аларны иртә югалттык.

Мин әтине бик ярата идем. Балачактагы иң истәлекле вакыйгаларның күбесе әти белән бергә күз алдына килә. Ул бик бала җанлы, йомшак күңелле иде. Гаиләбездә әти сүзе һәрвакыт өстен булды. Әни дә: «Әтиегез ни әйтер?», «Әтиегездән сорадыгызмы?» – дип, өстенлекне әтигә бирә иде.

Бездә бөтен эш тә киңәшләшеп башкарылды. Мин, кыз бала буларак, әнидән ашарга пешерергә, юарга, тегәргә өйрәндем. Хуҗалыктагы күмәк эшләрне (утын кисү, бәрәңге утырту-алу, яшелчә бакчасында чүп утау, кар көрәү һ.б.) оештыруда исә әти башлап йөрүче булды. «Тегене эшләгез, моны эшләгез», – дип түгел, үзе беренче булып тотынып, безне дә үз янына тартып өйрәтте ул эшкә.

Гаиләдә алдашу, караклык ише начар гадәтләргә урын булмады. Бакчада иң беренче өлгергән җиләкләрне дә, шәһәрдәге туганнардан килгән тәмле-тәмле күчтәнәчләрне дә җиде җанга тигезләп бүләләр иде.

Әти-әниебезнең җыр-моңны яратуы, гаиләдә музыкага зур урын бирелүе безгә дә тәэсир итми калмады: кечкенәдән музыка уен кораллары белән кызыксынып, җырлап-биеп үстек. Бала вакыттагы иң күңелле вакыйгаларның берсе – без – балалар тарафыннан куелган кечкенә концерт. Әти белән әнине диванга утыртабыз. Мин – концертны алып баручы. Абый гармунда, мин мандолинада уйныйбыз, сеңлем белән биибез, кечкенә сеңлебез шигырь сөйли, барыбыз да җырлыйбыз... Бераздан әти түзми, үзе дә кушылып гармунда, мандолинада уйный, җырлый башлый.

Ул безнең белән горурлана, безгә ышана иде. Әле дә исемдә: радиодан нинди дә булса яңа җыр ишетсәм, тизрәк өйрәнергә тырышам. Әти дә өйрәнә: «Кызым, бу урыны ничек әле?» – дип, миннән сорый. Әллә чынлап сорый, әллә мине үсендерә...

Мин әтине укытучы буларак та бик хөрмәт итә идем. Математика, җыр, рәсем дәресләрен укытты ул. Таләпчән, гадел булды. Әти алдында уңайсыз хәлгә калмас өчен, мин бу дәресләргә тырышыбрак әзерләнә идем. Әтинең эше авыр, җаваплы. Төннәр буе дәрескә әзерләнүләр, план язулар, дәфтәр тикшерүләр... Минем әтигә булышасым килгәнгә, үземнән түбәнрәк сыйныфта укучыларның контроль эшләрен тикшерергә бик теләп алына идем. Укытучылык һөнәрен сайлауга бәлки шул булышуларым да йогынты ясагандыр.

Әти берничә ел авылдагы яңа мәдәният йортының директоры булып эшләде. Мин, бала булсам да, аның төрледән-төрле түгәрәкләр алып баруын, кичәләр, концерт-театрлар оештыруда күпме көч түгүен күреп, аңлап тора идем. Безнең мәдәният йорты район буенча берничә тапкыр алдынгы урыннарны яулады. Әтинең, өйгә кайтып, сөенеп-горурланып сөйләгәне әле дә истә.

Мин үз балаларымда да әтинең чагылышларын күрәм: өч кызыбыз да җырга, музыка коралларында уйнарга, рәсем ясарга тартылды. Уртанчы кызыбыз төс-кыяфәте белән дә, көлүләре белән дә әтигә охшаган.

Әгәр дә әти исән булса, безнең – биш баласының бәхетле гаиләләрен, унике оныгының искиткеч сәләтле, кызыксынучан булып үсүләрен күреп бик сөенер иде.

Иң авыр чакларымда төшемә әти керә, юата, аңлата. Әтидән башка егерме сигез елдан артык вакыт үтсә дә, мин аның ярдәмен, кайгыртуын һаман тоеп яшим.

В.Әхмәтҗанов хатыны Фәридә һәм балалары белән

Васил белән Фәридә

Дилбәр Ситдыйкова,
Чаллы шәһәре. Июнь, 2005 ел.

ОЗАТА БАРМА

Васил Әхмәтҗанов сүзләре һәм көе

Озата барма, иркәм, кайталмассың,
Әйтер сүзең әйтә алмассың.
Син бит минем кайнар йөрәгемдә
Онытылмаслык урын алгансың.

Озата барма, иркәм, озата барма,
Олы юл бит, бәлки, адашмам.
Синең серле кара күзләреңне
Башка бер күзләргә алмашмам.

Алма бакчасына әгәр керсәм,
Сиңа өзәр идем алсуын.
Нинди сүзләр белән аңлатыйм соң
Бу йөрәккәемнең ярсуын?



Васил Әхмәтҗанов җырларының нотасы һәм сүзләре

Безнең мирас №3 март 2018

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ТӘСБИХ г. – 1. Шул ук *сөбха*. Гарәпчә «мактау» мәгънәсендәге сүз. *«Сөбхан Аллаһ»* дигән гыйбарәне кабатлау. Риваятьләргә караганда, Идрис галәйһиссәлам һәр көн 12 мең тәсбих әйтә торган булган. Валерия Порохова «Хадисы Пророка» китабында *тасбиха* язылышын (*женский род* формасын) куллана. // *Агач башкайлары тәсбих әйтә Акрын гына искән җил белән.* **Җырдан.**

Теологлар: ««Сөбхан Аллаһ» гыйбарәсе Аллаһның ширеге яки берәр кимчелеге, йомшаклыгы, сәләтсезлеге юк икәнен дә белдерә», – диләр.

2. Зикерне санау өчен кулланыла торган «тәсбих мәрҗәнен» тәсбих (дисбе) дип йөртәләр (гарәпчә тулы исеме – «әл-мисбат әл-вирдийят»). Чыганакларда *мисбаха* дип атау да очрый («четки»). Тәсбих Аллаһның мактаулы исемнәре санынча – 99 төймәдән гыйбарәт, алар, өч тигез өлешкә бүленеп, бер җепкә тезелгән. Тәсбих төймәләре сөбхи дип атала. Йөзенче зуррак төймә – *шаһданә* яки *нишанә* халык телендә тәсбихнең *мулласы* (имамы) яки *Мәрйәм анасы* («мәрйәмәнәсе») исәпләнә. Дөрес, **Нурихан Фәттах**: *«Тәсбихтәге һәр 33 төймәдән соң «тәсбих анасы» куела»*, – дип яза. Ихтимал, «мәрйәмәнә» термины тәсбих төймәләрен еш кына *мәрҗәмана* агачыннан (байбай, мәрҗән агачы, карга миләше) кисеп ясауга бәйледер. «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә тәсбих төймәләренең мәрйәмана дигән бүлмә гөле җимешеннән ясалуы телгә алына.

Габдулла Тукай үзенең Лев Толстойның вафат булуы уңаеннан язылган **«Мөбарәк**

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

тәсбих өзелде» дигән мәкаләсендә: «Андреев, Максим Горький, Потапенко, Куприн, Сологуб, Мережковский, Григорий Петров, Скиталец вә гайре, вә гайре бөтен Россиянең мөхтәрәм мөхәррирләреннән тезелгән мөбарәк тәсбихнең очындагы *бисмилласы, Мәрьям анасы*, яки *имамы* өзелде», — дип, тирән кайгысын белдергән иде. *(Курсив минеке. –* **А.Т.***)*

Әлфинә Сибгатуллина: *«Халыкта утыз өч яки илле төймәле, өч яки биш баш төймәле тәсбихләр мәгъкуль күрелгән»*, – дип яза. Ә суфилар йөрткән тәсбихләр йөз илле төймәле, унбиш нишанәле булган. Йәһүд дисбесе 13 төймәле.

Баштарак зикерне санар өчен вак чакматашлар (чуерташлар) һәм хөрмә төшләре дә кулланганнар һәм бу Мөхәммәд галәйһиссәламгә мәгълүм булган. Шулай булгач, зикер кәлимәләренең санын исәпкә алу өчен мәрҗән итеп тезелгән тәсбихне дә, чәчмә ташларны да кулланырга ярый дигән сүз.

Югары катлау кулланган тәсбихләр асыл ташлардан ясалган була. Мәс., Иван Калитаның биографиясен язган **Николай Борисов** Алтын Урда ханы Үзбәкне: *«Ляҗүрд (лазурит) дисбесен тартып, кымыз капкалап утыра иде»*, – дип тасвирлый.

Гомумән, тәсбих тарту гадәте Һиндстанда килеп чыккан, дип уйлыйлар. Мөселманнарда беренче тапкыр тәсбих **Әбү Нувайс**ның шигырендә телгә алына (миляди 808-813 еллар). Ләкин баштарак тәсбихне хатын-кызлар (суфиялар) гына кулланган. Тәсбих тарту Будда динен тотучыларда һәм католикларда да бар. XV гасырга тәсбих мөселман илләрендә киң таралыш ала.

Суфилар телендә тәсбих мәрҗәне *шайтанны суктыра торган камчы* дип аталган.

Мисырда һәм Согуд Гарәбстанында намаздан соң тәсбих тартмыйлар икән, чөнки ул дингә соңрак кергән һәм анда бидгать гамәл булып санала.

Ваһһабиларның тәсбих куллануны тыюларын да әйтеп китик.

Тәсбих (дисбе) асылда функциональ яктан борынгы *санар тактага* (рустагы «счеты» – *чут*) тәңгәл.

Язучы Нурихан Фәттах Крит утравында табылган мәшһүр Фест дискысын «дисбе» дип атый. Моның өчен, аңа ышанычсыз арифметик гамәлләр башкарырга туры килә: дисктагы «сүзләр» санын 100гә тутыру өчен, аңа бер яктагыларын икегә тапкырлап (33х2=66), шуңа икенче яктагы «сүзләр» санын (34) кушарга кирәк була. Мондый ысул белән барганда, 66 санының ахырына янә бер 6лык өстәп, шайтани 666 санын хасил итәргә дә мөмкин, әлбәттә. Әмма иң әүвәле 3 мең яшьлек дискны дисбе дип атау хронология белән сыешмый.

//Шәрәфәтле иманыңны зикер-тәсбих белән сакла. **Мөнәҗәттән.** Бәдри карчык намазлык өстендә тәсбих чәкеб [тартып] утыра иде. **Ф.Кәрими.** Кайбер сөйләшләрдә тәсбих тартуны таш тарту дигәннәр. Монда «таш» тәсбих төймәләре ясалган җимеш төшен белдерсә кирәк. Тәсбих әйтү. Тәсбих санау. Тәсбих нуры. Тәсбих әҗере.

ТӘҮ – «Башлангыч»; «беренчел»; «килеп чыгыш», «башта», «элек», «элгәре» мәгънәләренә ия. Бу сүз Урхун язмаларында да очрый, охшашы башка төрки телләрдә дә бар. *Тәү/тәүге* сүзләрен рус телендәге «начальный», «ранний», «первобытный» мәгънәсендә кулланып булыр иде (мәс., *тәүге феодализм* – ранний феодализм, *тәүге урта гасырлар* – раннее средневековье яки (башкортлардан үрнәк алып): *тәүтормышлы җәмгыять* – первобытное общество); *тәүге татар теле* – раннетатарский язык (кыпчак-татар теле); Ләкин, әйтик, *ранние болгары* терминын татарчада *элгәре болгарлар* дип бирергә туры килә. //Тәү мында татар булган. Оренбург өлкәсенең Абдуллин авылы сөйләше. Тәү башлап – башта. Иң тәү – иң элек, инал (иң алда). ■

КУКМАРА МИРАСЫ

КИЕЗ ИТЕКЛӘР ИЛЕ

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

АВЫЛ ЭШМӘКӘРЛӘРЕ

Мәгълүм ки, XIX гасырда Кукмара авылында гына түгел, ә бәлки аның тирә-юнендә дә киез итек басу кәсебе белән ныклап шөгыльләнгәннәр. Атаклы фабрикантлар – бертуган Комаровлар, шулай ук Родигиннар һәм Войдиновларның эшчәнлегеннән без инде азмы-күпме хәбәрдар. Бу хакта «Безнең мирас»та да кызыклы, мәгълүматлы язмалар дөнья күреп тора (кара: «Безнең мирас», №2, 2018).

1883 елда Составак авылы крәстиәне Хөсәен Исмәгыйлев киез итек басу эшен оештырып җибәрә. 1890 елда, мәсәлән, 10 эшче җәмгысы 2000 сумлык 1000 киез итек әзерли. Түбән Казаклар авылы крәстиәне Ситдыйк Габделгаффаров исә, 1877 елда ук, киез-киез итек басу-эшкәртү эшен җайга салу белән беррәттән, бу

Киезне сыгу вакыты. XX нче гасыр башларында төшерелгән фото

эшне максатчан алып бару өчен махсус бина да салдыра. Аның карамагында 20 кеше (шуның уникесе өендә торып эшли) була. Эш сентябрьдән алып май ахырына кадәр бертуктамый алып барыла. 1886 елда С.Габделгаффаров хезмәтханәсендә 7000 сумлык эш башкарыла. Бу – 3000 пар итек дигән сүз. Әзер киез итекләрне Минзәлә һәм Бөгелмә, шулай ук Алабуга һәм Чистай ярминкәләрендә сатканнар. С.Габделгаффаров белән берүк вакытта аның авылдашы Мөхәммәтвәли Ситдыйков та үз эшен ачып җибәрә. Эшчеләр саны аз (15 кеше) булуга карамастан, Ситдыйков эшчеләре башкарган эшнең нәтиҗәсе С.Габделгаффаровныкылар белән бертигез дәрәҗәдә була.

Бу уңган кәсепчеләрнең авылдашлары Габдулла Казаков һәм Каюм Фәизов та киез итек басу эшен киң җәелдереп җибәрә: алар хәтта 1890 елда – Казанда, 1896 елда Түбән Новгородта узган күргәзмәләрдә дә катнаша.

Түбән Новгородта үткән күргәзмәдә бертуган Насыйр һәм Фатих Садыйковлар да катнаша. 1885 елда үзләренең уртак эшләрен ачкан бу эшмәкәрләрнең унҗиде кешедән торган «эшчеләр төркеме» 1897 елда 3500 сумлык киез итек җитештерә. 1909 елда бу ике бертуган аерым эшли башлый.

1882 елда Олыяз крәстиәне Кадыйр Бикчәнтәев тә үз эшен җайга сала. 1886 елда аның 6 эшчесе июнь-март айлары арасында 2000 сумлык мең пар итек эшләп өлгертә. Шул ук авыл кешеләре – отставкадагы рядовойлар Мөхәммәтҗан Гыйззәтуллин һәм Бикмөхәммәт Биктин да шундый эш белән шөгыльләнеп, товарларын Минзәлә, Бөгелмә һәм Алабуга ярминкәләрендә саттыра.

Киез итек басу эше белән шөгыльләнүчеләр арасында Казаковлар династиясе аерым игътибарга лаек. Түбән Казаклар авылы крәстиәне Габдулла Гыйззәтулла улы Казаков үз эшен 1867 елда ача. Күпмедер вакыттан соң Кукмарада «А.Г.Казаков һәм аның уллары» дигән Сәүдә йортын эшләтеп җибәрә. Ул вафат булганнан соң, уртак эшне

Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин,
«Кукмара киез-киез итек комбинаты»ның 1988-2017 еллардагы генераль директоры:

«1917 елдан соң, ике ел чамасы, фабрикада башбаштаклык хөкем сөрә. Революция солдатлары һәм матрослары бөтен мөлкәтне пыран-заран китерә. Мебель, урын-җир кирәк-ярагын, җәмгысы 8 сандык әйбер Мамадышка озатыла. Ни өчен, нинди максат белән? Бу хакта тарихи документлардан укыгач, чәчләрем үрә торды...»

Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин (1954-2017) турында

«Шамил Әхмәтшин – чынлап та зур хәрефтән языла торган Кеше. СССР コяшы баеп барган бер мәлдә, яп-яшь килеш – 33 яшендә директор була. Шикле төркемнәргә кушылмаган, бернәрсәне дә үзләштермәгән, таламаган, сатмаган, чит илгә чыгып качмаган, хәтта оешманы, башкага үзгәртмичә, ничек бар, шулай калдырган. Үз хезмәткәрләре өчен җаваплы булуын аңлаганга күрә, ул җиңел юлдан китмәгән дә инде».

(«Кукмара киез-киез итек комбинаты»ның 1988-2017 еллардагы генераль директоры Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшинның «Бизнес-Онлайн» электрон газетасы хәбәрчесенә биргән интервьюсы уңаеннан билгесез автор фикере. 8 декабрь, 2014 ел)

Хәйрулла Казаков гаиләсе. 1910 нчы еллар

аның уртанчы улы Хәйрулла (1874-1937) алып бара башлый. Ул җитәкчелек иткән елларда, әйтик, 1909 елда 400 эшче тарафыннан 130000 пар киез итек җитештерелә. Төп капитал 125 мең сум тәшкил итә. Ул вакытта Казаковларның Түбән Казаклар авылында өч ат көче белән эшли торган двигательле фабрикалары, зур кирпеч складлары, ясалма күлләре була.

Киез итек басудан тыш, Кукмара төбәгендә йон тетү эше белән дә шөгыльләнәләр. Мәсәлән, Зур Сәрдек авылы кешеләре Мөхәммәтнәфыйк Шәфыйков һәм Шаһимәрдан Биктимеровларның үз хезмәтханәләре булганлыгы билгеле.

Алда телгә алынган эшмәкәрләрнең берише 1917 елгы Октябрь түнтәрелешеннән соң да үз эшчәнлекләрен артель сыйфатында дәвам итәргә тырыша, әмма совет хакимиятенең «репрессия давылы»ннан аларның күбесе исән кала алмый.

1930 елда Хәйрулла Казаков гаиләсенә кайгы килә: гаилә башлыгы үзе, хатыны Әминә Гарәф кызы (1887-1969) һәм аларның балалары – Гали (1908-1982), Мәрьям (1916 елда туган, вафаты билгесез), Фәридә (1918-1976), Гомәр (1921), Фатыйма (1925), Зәйнәп (1928-1992) Красноярск төбәгендәге Удерей районының (1956 елдан соң Мотыгино) Лужанка прискасына сөрелә. Хәйрулла Казаковның өлкән улы Гали 1938 елда кулга алына: 10 елга хөкем ителеп, Норильлагка озатыла. 1946 елда аннан азат ителә һәм Норильскига сөргенгә җибәрелә. Анда ул 1956 елга кадәр була, «Аэродромстрой»да баш бухгалтер вазыйфасын башкара. 1962 елдан соң Красноярскида яши. Гомәр һәм Фәридә Бөек Ватан сугышында катнаша. Фатыйманың ире Фатих Арслановка да Норильлаг «җәһәннәм»ен узарга туры килә. Сәяси тоткыннар бары тик 1993 елда гына реабилитацияләнә. ■

Безнең мирас №3 март 2018

ТАТАР МАТБУГАТЫ
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНА 100 ЕЛ

قازان مسلمان کامیساریاتی طرفندن چغارلا طورغان کوندەلك سیاسی، ادبی واجتماعی گازیتە.

اش

ЭШ

Орган Комиссариата по мусульманскимъ дѣламъ при Совете Р. С. и К. Д. Каз. Республики. Выходитъ пока 3 раза в неделю.

Подписная цена:
На 12 месяцев .... 20 руб.
„ 6 „ .... 10 „
„ 3 „ .... 5 „

Адрес: Казань, редакция газеты „ЭШ".

№ 1 — ١٩١٨ نچی یل. — سهشنبه کون — ١٢ مارط — نومر ١

آول کامیسارلرینە.

«ЭШ» ГАЗЕТАСЫ

Газета белән танышканчы, иң элек матбугат белгече Исмәгыйль Рәмиев язганнарга тукталыйк. Ул «Эш» газетасы турында менә ниләр яза: *«1918 нче елны 12 мартта Казанда чыга башлады. Шигаре: «Берләшеңез, бөтендөньяның эшчеләре!» Бер дә тайпылмый коммунизм фикерен алга сөреп килде. Казан губернасы штабында чыгарылган газет булса да, Казаннан чит губерналарга кызыл фронтларга бик күп таралды. Материальный яктан башкаларга караганда байтак ук яхшы тәэмин ителгән булганлыктан, дәвамы да озак булды. Язучыларга да башка газеталар кебек үк аптырамады. Вакытында Казанның «төп гәзите» булып барды. Ләкин шулай да бәгъзе бер вакытларда язышучылары азаеп, мөндәриҗәсе (эчтәлеге) сыекланган вакытлары да булгалады. Мәсәлән: Казанда берәр яңа гәзит чыга башласа, моның яртылаш составы яңа гәзиткә күчерелә. Шуннан гәзит зәгыйфьләнебрәк кала иде. Гомумән алганда, бу гәзит башка гәзитләргә караганда мөндәриҗәсенең тулылыгы белән аерым урын тотты.*

Асылда көндәлек булып чыгарга тиеш булса да, заманаларның авырлыгына карап сирәкләп тә чыккалады. Урта кулда, дүрт битле булып, сары кәгазьдә басылды. Эшләнүе «Милләт» типографиясендә. Коммунизм җырларын башларыннан үткәргән гәзит-журналларның техникалары турында шәп дип тә сүз әйтеп булмый. Еллык бәясе – 280 сум, берәмләп – 2 сум 50 тиен.

Нашире – Казан губернасы советы хозурында «Мөселман эшләре шөгъбәсе (бүлеге)». Мөхәррирләре җыш кына алышынып торды. Язышучылары – Г.Ибраһимов, В.Шәфигуллин, С.Атнагул, Г.Баембит, Ибраһим Күләй, С.Җәләл, Хәсән Исхаков, Г.Кәрәм, Борындык, Ә.Сәгыйди, К.Әмири, Ф.Сәйфи, Яруллин һәм башкалар».

1918 елның 12 мартында беренче мәртәбә халыкка таралган «Эш» газетасы безнең көннәргәчә исемен үзгәртә: «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан», «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан» һәм 1992 елның февраль аеннан – «Ватаным Татарстан». Әлеге йөзьеллык газетаның тарихы турында язсак, мәкалә күләме бер журналга гына сыймас иде. Шунлыктан, аның иң тәүге санына гына тукталабыз. Газетаның безнең кулда булган беренче саны «Өмет» типографиясендә басылып чыккан. Беренче биткә, иң өскә басманың «Казан мөселман комиссариаты тарафыннан чыгарыла торган көндәлек сәяси, әдәби вә иҗтимагый газета» икәнлеге турында әйтелгән.

Тәкъдим ителгән текстларда татар җәмгыятендәге социаль киеренкелек, халыкның хыял-омтылышлары һәм илнең Гражданнар сугышына кереп барганлыгы ачык сизелә. Газетада басылган карарлар Үзәк мөселман комиссариаты рәисе Мирсәет Солтангалиев имзасы белән тарала. «Эш»нең 1918-1921 еллардагы баш мөхәррире – Вәли Шәфигуллин.

КАЗАН МӨСЕЛМАН КОМИССАРИАТЫ

Халык комиссарлары хөкүмәте милләтләргә йирле мохтарият алу, аерым мәмләкәт төзү дәрәҗәсенә кадәр киң хокук бирде. Бу хокук бер милләтнең эшчесе һәм фәкыйрь крәстиәненә бирелгән иде. Бер милләтнең эшчесе, фәкыйрь крәстиәне эш башында торып, хакимиятне үз кулында тоткан вакытта гына ул милләт истикъляльят *(бәйсезлек)* ала иде.

Бер милләтнең эшчесе һәм фәкыйрь крәстиәне үз теләгәнен әйткәнче, ул милләтнең хәзерге социальный революциядән, эшче, крәстиәннәр хөкүмәтеннән котлары очкан байлары һәм аларның ялчылары мәмләкәт төзүне үз кулларына алырга тырыштылар. «Без – бер милләт, без үзебез теләгәнчә үз тормышыбызны төзик», – диделәр. Халык комиссарлары һәм советлар шулай җавап бирделәр: «Дөрест, сез – бер милләт, ләкин бер милләтнең байлары мәмләкәт төзү хокукыннан мәхрүм. Эшче, крәстиән теләмәсә, байларга бернәрсә дә эшләргә ирек бирелми, чөнки байлар эшче белән крәстиәнне изәр өчен, үзләре эш башында тору өчен, үз куллары белән мәмләкәт төзергә, ыштат ясарга тырышалар», – диделәр.

Революциядән соң татар байлары, татарның ялган милләтчеләре сигез ай буена мөселманнарга бер комиссар урынын сорап йөргән иделәр, ләкин Милюковлар, Керенскийлар хөкүмәте аларга бирмәде. Халык комиссарлары хөкүмәте пайтәхеттә мөселман эшләре комиссарлыгы төзегәч, безнең татар байларына, татар милләтчеләренә бер дә ошамады. Имеш, сорамыйча, ялвармыйча, теләнмичә бирелгән, бирелсә дә анда эшче, крәстиән вәкилләре, большевиклар, сул революционерлар эш башында утырган. Эшчеләр, крәстиәннәр мөселман комиссарлыгын тәбрик итәләр, яшәсен мөселман комиссарлыгы, диләр. Байлар, ялганчы милләтчеләр каршы киләләр. Ул комиссарларны без сайламаган, диләр. Имеш, Галимҗан Ибраһимов, Мулланур Вахитов, Шәриф Маннатовларны байлар, алпавытлар һәм аларның ялчылары сайламаган.

Мәркәз мөселман комитеты менә нәрсәдән эш башлап җибәрә. Иманлы, пакь күңелле мөселманнар өчен иң газиз, мөкаддәс булган Сөембикә манарасын мөселман эшче һәм крәстиәннәр кулына алып бирә. Менә берничә ай гына татар гәзитәләрендә тавыш күтәргән, бөтен татарның күңелен әшгал (әсир) иткән Сөембикә манарасы эшче,

крәстиәннәр кулына кергәч, байларның, ялган милләтчеләрнең бөтенләй дәртләре сынды. Әле кичә генә Сөембикә манарасының әһәмияте хакында шәһәр саен лекция укып акча җыйнаган кешеләр дә бүген Сөембикә хакында, алай-болай гына, дип, ыкмык киләләр.

Казан мөселман комиссариаты мөселманнарның бөтен милли, мәдәни эшләрен үзе карау белән бәрабәр, мөселманнар арасында тынычлык кертергә һәм чыккан декретларның халәт рухиягә татбикъ ителүенә *(туры килүенә)* тырышачак. Крәстиән хакимияте һәм комиссарлыкка каршы килгәннәр, аяк чалганнарга нинди генә каты тәдбирләр *(чаралар)* кылудан да тайчынмаячак. Шулай ук эшче, крәстиәннәр хакимияте астында Идел-Урал ыштаты төзергә нык иҗтиһад итәчәк.

КАЗАН ГУБЕРНАСЫ МӨСЕЛМАН КОМИССАРИАТЫННАН КАЗАН ГУБЕРНАСЫНДАГЫ АВЫЛ, ВОЛОСТЬ МӨСЕЛМАННАРЫ КОМИТЕТЛАРЫНА

Казанның эшче, солдат, крәстиән вәкилләре шурасы хозурындагы Казан губернасы мөселман комиссариаты тарафыннан иҗбари *(мәҗбүри)* карарлар: төрле авыллардан килгән хәбәрләргә караганда, Ыстолыпин вакытында төрле юллар белән иллешәр, йөзәр дисәтинә йир алып, үзләре артына мәңгегә беркетеп куйган авыл байлары, үзара оешып, фәкыйрь крәстиәннәрне кыса башлаганнар һәм сугыштан кайткан солдатларны кыйнап, авылларына кертми башлаганнар. Үтерешле вакыйгалар да булган.

Авыл байлары онытканнар ахры! Чөнки фәкыйрь крәстиәннәрне һәм солдатларны кыйнап йөргәндә: «Безгә солдат законы кирәкми, үзебез хуҗа үз йиремезгә!» – дип кычкырганнар.

Шул мөнәсәбәт белән, Казан губернасы мөселман комиссариаты игълан итә: «Йир игүче халыкныкы, шунлыктан, йир игенне үзе игүчеләр арасында тигез итеп бүленергә тиеш». Менә бу – закон. Бу закон эшче, солдат, фәкыйрь крәстиән законы. Моңа каршы килүчеләр җинаятьчеләр саналып, бу законга каршы килгән кешеләр һәм фәкыйрь крәстиәннәрне кыйнап-сугып, авылларда тынычсызлык кертүчеләр фәүкыльгадә *(гадәттән тыш)* каты җәзага төшәчәкләр. Гаепле кешеләр үзләре кулга алынып, инкыйлаб судына биреләчәк һәм бөтен әйберләре конфисковать ителәчәк.

Бу карарлар авылларда, волостьларда фәкыйрь крәстиәннәрне, сугышта булган солдатларны чакырып укылырга һәм урамнарга ябыштырылырга тиеш. Бу карарларны яшереп калган авыл, волость комиссарлары да югарыда күрсәтелгән җәзага тартылырлар.

Комиссариат рәисе: М.Солтангалиев. Сәркатип: Харис Җомагыл. 27 февраль.

ЙОРТ ХУҖАЛАРЫНА ҺӘМ СӘҮДӘХАНӘ, ЗАВОД, ФАБРИКА ИЯЛӘРЕНӘ

Казан эшче, солдат һәм крәстиән советының башкаручы комитеты игълан итәдер: йорттан айга 3000 сумнан артык доходы булган йорт хуҗалары һәм сәүдәханә, фабрик, завод хуҗаларының 8000 сумнан артык сәрмаяләре булганнары 13 нче мартта, кич сәгать 6да Проломный урамда Биржа залында булачак мәҗлескә килергә тиешләр. Акчага тәгаллекълык *(бәйләнешле)* мәсьәләләр каралачак. Һәркем катгыя тиеш. Килмәүдә гаепләнүчеләргә 5000 сумга кадәр ыштраф салыначак.

КАЗАН ГУБЕРНАСЫНЫҢ МӨСЕЛМАН КОМИССАРИАТЫННАН

Казан губернасы мөселман комиссариаты, Казан губернасындагы мөселманнар арасында тынычлык кертүгә бик зур әһәмият биргәнгә, түбәндәге Декретны чыгара.



Газетаның беренче мөхәррире Вәли Шәфигуллин

Һичбер номер, чәйханәләрдә һәм хосусый йортларда эчемлек әйберләренә (...) һәм ул кешеләр торган номер, чәйханә, хосусый йорт хуҗаларына каты җәзалар биреләчәк. Гаепле кешеләр үзләре инкыйлаб хөкеменә бирелеп, бөтен йортлары, җиһазлары, әйберләре кулга алыначак. Урамда исереп йөргән кешеләр дә шундый каты җәзага дучар булачактыр. Рәис: Солтангалиев. Сәркатип: Җомагыл.

КАЗАНДА МӘХӘЛЛӘ ОЕШМАЛАРЫНДАГЫ КҮҢЕЛЛЕ МӨСЕЛМАН ДРУЖИНАЛАРЫ ҺӘМ МӨСЕЛМАН ЭШЧЕ КРӘСТИӘННӘРЕ ДИКЪКАТЕНӘ

Фәкыйрь эшче һәм крәстиән кардәшләр! Карыйк, иптәшләр! Тикшерик, иптәшләр! Безнең шул мәхәллә оешмаларындагы мөтәвәллиләр кемнәр? Анда мәхәлләләребездә иң байлар гына сайланып, күп мәхәлләләребездә рәислеккә дә сәясәттән һәм икътисадтан тузан кадәр мәгълүматы булмаган, әүвәлдән үк акча бәрабәренә байларга хәер-фатыйха кылып килгән һәм шул байларның гына мәнфәгатен химая итүче меллалар сайланган түгелме? Мәхәлләбезнең байларыннан һәм аларга хәер-фатыйха сатучы меллаларыбыздан гыйбарәт мөтәвәллиләребез: «Йир һәм капиталга социализм, подоходный налог», – дигән сүзләрне ишетү берлә: «Без – мөселманнар, безнең шәригатебездә «социализм» дигән сүз юк, ул безгә дөрест түгел. Без – милләтче, без милләт саклыйбыз», – диләр. «Татар милләтен бетү чараларын күрергә тиеш!» – дип карарлар чыгарган Николай һәм аның миссионерлары бетте, алар бетү берлә, милләтебезгә каршы дошманнар да юк.

Без хәзер кан түгелүләрдән сак булу өчен, бу көннәрдә генә таралган Бөтенрусия мөселманнарының игенче гаскәри корылтае тарафыннан чыгарылган карар буенча, һәр йирдә эш башында утырган буржуазияне һәм аларның җырын җырлаучы меллаларны себереп ташлап, бу көннән үк мәхәлләләребездә һәр эшендә капиталга ышанмый, бер Аллага гына һәм үзенең маңлай тирләрен чыгарып эшләвенә генә ышанып эш кылучы чын мөселман эшче һәм крәстиән вәкилләреннән генә гыйбарәт оешма төзергә тиешбез.

Шундый оешмалар төзү өчен, безгә кораллар кирәк, берегез дә кулыгызга, бәхетебезгә күрә эләккән коралларыгызны мөтәвәллиләргә дә, меллаларга да ышанып бирмәгез һәм кулыгыздан ычкындырмагыз! Шул кораллар берлә генә без буржуазия һәм капиталга каршы торып, фәкыйрь эшче һәм крәстиәннәрнең теләкләрен вөҗүдкә чыгара алачакбыз. Яшәсен чын мөселман фәкыйрь эшче һәм игенчеләр вә аларның вәкилләре шурасыннан гыйбарәт хакимиятле «Идел-Урал» ыштаты!..

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Арча районының Иске Кишет авылындагы музей җитәкчесе Гөлфия Габитова

Гани Сафиуллин мирасы

ТР Милли музеенда Советлар Союзы Герое, генерал-лейтенант Гани Сафиуллинның орден-медальләре, шәхси әйберләре, документлары һәм истәлек язмалары – барлыгы йөзгә якын экспонат саклана. Бөек татар каһарманының мирасы белән Арча районының Иске Кишет авылында «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин җитәкчелегендә оештырылган «Гани Сафиуллин мемориаль музей-йорты»нда да танышырга мөмкин.

Г.Сафиуллинның кителе. ТРММ

Г.Сафиуллин – сталинградчы. 1942 ел. ТРММ

ФЕВРАЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында



● Февраль башында Төркиянең Истанбул шәһәрендәге «Палто» нәшриятында мәшһүребез Аяз Гыйләҗевнең «Яра» повесте Фатих Кутлу тәрҗемәсендә аерым китап булып дөнья күрде.

● 2 февральдә «Безнең мирас» журналы редакциясе яшь галим Булат Рәхимҗановның «Москва и татарский мир» дигән китабына бәйле «түгәрәк өстәл» утырышы уздырды. Утырышта Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, галимнәр Булат Рәхимҗанов, Фәйзелхак Ислаев һәм Булат Хәмидуллин, «Ватаным Татарстан» газетасы журналисты Рәшит Минһаҗ, шагыйрә Нәҗибә Сафина, баш мөхәррир Ләбиб Лерон, журнал хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин катнашты.

● 9 февральдә Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә мәшһүр шагыйребез Фәнис Яруллинның тууына 80 ел тулуга багышланган «Җилләрдә сыналган җилкән» дигән әдәби-музыкаль кичә (сценарий авторы – Индус Сирматов, режиссеры – Илдар Хәйруллин) узды. Чарада Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары Эльвира Камалова, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, әдипнең хатыны Нурсөя ханым, каләм әһелләре һәм сәнгатькәрләр катнашты. Мәдәният министрының беренче урынбасары Э.Камалова Нурсөя ханымга Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәте өчен» медален тапшырды. Кичәне К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары Резеда Сәлахова белән Артем Пискунов алып барды.

● 12 февральдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында мәшһүребез А.Гыйләҗевнең тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналы кичә (сценарий авторы – Гүзәл Сәгыйтова, режиссеры – Радик Бариев) булып узды. Кичәдә Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, Татарстан Республикасының мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, шагыйрь Ркаил Зәйдулла, галимә Миләүшә Хәбетдинова, әдипнең хатыны Нәкыя ханым, уллары Искәндәр һәм Мансур Гыйләҗевләр чыгыш ясады. Мәдәният министры А.Сибагатуллин кичә барышында, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев исеменнән, Нәкыя апага Рәхмәт хаты тапшырды.



● Февральдә атаклы мәгърифәтчебез Каюм Насыйрига нисбәтле китап («Җыен» фонды әзерләгән әлеге басманың төзүчесе – Рәмил Исламов) басылып чыкты.

● 14 февральдә Казан шәһәренең татар телендә белем бирүче 149 нчы лицеенда (директоры – Фирдәүс Габделнур кызы Вафина) «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре – шагыйрь Ләбиб Лерон һәм драматург Рәдиф Сәгъди укучылар белән очрашты.

● 15 февральдә Казан федераль университетында журналистика факультетының беренче деканы Флорид Әгъзамов (1936-2005) исемендәге аудитория ачу чарасы узды. Чарада Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, Казан Федераль университеты проректоры Дмитрий Таюрский, галимнәр Индус Таһиров, Илдар Низамов һ.б. катнашты.

● 15 февральдә Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә атаклы җырчыбыз Илһам ага Шакировка 83 яшь тулу уңаеннан зур концерт (сценарий авторы һәм режиссеры – Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов) булды.

● Февральдә «Татарская деревня в местах компактного проживания татар в среднем Поволжье» дигән китап (төзүчесе – Булат Хәмидуллин) дөнья күрде.

● 15 февральдә башкалабыз Казанда һәм Чаллы каласында каһарман шагыйребез М.Җәлилне искә алу чаралары булып узды.

● 16 февральдә «Казан» милли-мәдәни үзәгендә танылган журналист, нәфис сүз остасы һәм «Татарстан – Яңа гасыр» телевидениесенең алып баручысы Илдар Кыямовның иҗат эшчәнлегенә һәм аның туган авылы турындагы «Кара Чишмә карьясе» дигән китапка нисбәтле әдәби-музыкаль кичә узды. Җыр һәм шигырь белән үрелеп барган әлеге чарада Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, галимнәр Индус Таһиров, Зөфәр Рәмиев һәм Искәндәр Гыйләҗев,

«Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, «Казан» милли-мәдәни үзәге директоры урынбасары, әлеге чараның сценарий авторы һәм режиссеры Халисә Исмәгыйлева, И.Кыямовның якташлары, туганнары, хезмәттәшләре һ.б. чыгыш ясады. ■

Мирасворд

«Ямашев» трилогиясе авторы

... Граши (әрмән шагыйре)

Хо ... Мин / Белән (иск.)

Борынгы грек мифологиясендә уңыш Алласы

Камытның ат муенына һәм түшенә тиеп торган аскы өлеше

Самоа акчасы

Рус революционеры / Хәснул Вәлиуллин операсы

Демонстрация (иск.)

Рус рәссамы, Айвазовскийның укытучысы

Малайя архипелагындагы утрау

Хөсәен Ямашев чыгарган газета

Һиндүләрдә өлкән рухани

Җәмит Рәхимов романы

«Россия 1 – Татарстан» телеканалындагы тапшыру

Дәвер, заман / Швеция каласы

Маҗар кенәзләре династиясе башлыгы

Ярдәмче фигыль / Украина җиңел автомобиле

Укымышлы (иск.)

Иң борынгы кешеләрнең бер вәкиле

Быргы (иск.)

Исеме җырга кучкән авыл

Калакирмәннәрдәге эчке сакчы (бор.)

Әбиләр ...

Экскурсовод

«Онытылмас еллар» трилогиясе авторы

Одиссей Ватаны

Кәрим Тинчурин драмасы

Ишек сакчысы (бор.)

XX йөз француз физигы

Иранда авырлык үлчәве

Ишморат, Шафи

Кеше, шәхес

Балтач районындагы авыл

... Урда / Грек хәрефе

XX йөз украин шагыйре

Ышкылау (диал.)

2 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Руми, тумак, Сәйф, Һәдия, әгәр, Бәркәтә, Рико, сут, Шәкүров, әл, шәт, турама, Шаман, Ра, Огайо, мега, Бакиров, сага, Ати, типтәр, Ани, стан.
Өстән аска: Рөстәм, шаурма, Мәйсәрә, раек, рикша, Ги, Күәм, «Артист», бортас, Ватан, Таһиров, шор, тән, лаг, Сирин, мәдрәсә, Мата, Тулбай, «Кыямәт», нота.

Рәис Габдулла төзеде.

17 нче татар гимназиясе каршындагы Галимҗан Ибраһимов бюсты

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / МАРТ

• 630 ел элек (1388)

Аксак Тимер, үз биләмәләренә бәреп кергән Алтын Урда гаскәрен 1388 елның кышында куып җибәрү белән генә чикләнми, яз җитеп, далалар яшәрү белән Хәрәземгә җавап явы оештыра.

• 165 ел элек (1853)

12 мартта педагог, җәмәгать эшлеклесе Шаһбазгәрәй Измаил (Исмәгыйль) улы Әхмәров (1853-1900) дөньяга килә.

• 110 ел элек (1908)

15 мартта язучы Рахман Ильяс (Габдрахман Вәкил улы Ильясов) дөньяга килә. 1943 елның 23 августында яу кырында батырларча һәлак була.

• 100 ел элек (1918)

«Шәрык кызы» журналының беренче саны дөнья күрә.

• 95 ел элек (1923)

20 мартта Мәскәүдә «Таһир-Зөһрә» спектакленең (Фәтхи Бурнаш трагедиясе буенча) премьерасы була.

Уфада «Яңа юл» дип аталган журнал чыга башлый.

Һади Такташның «Җир уллары» исемле беренче җыентыгы чыга.

• 90 ел элек (1928)

27 мартта Мәскәү Үзәк татар театры труппасы Нәкый Исәнбәтнең «Һиҗрәт» пьесасын сәхнәгә куя.

• 70 ел элек (1948)

5 мартта Уфада Мәҗит Гафури торган йортта музей ачыла.

• 60 ел элек (1958)

16 мартта Гомәр Бәширов Яңа Чишмә сайлау округы буенча СССР Югары Советы депутаты итеп сайлана.

• 50 ел элек (1968)

7 мартта башкалабыз Казандагы 89 нчы мәктәптә (хәзер – 17 нче татар гимназиясе) Галимҗан Ибраһимовка бюст куела.

• 25 ел элек (1993)

20 мартта Татарстан Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, татар әдәбияты аксакаллары Гомәр Бәширов белән Әмирхан Еники хозурына барып, аларның хәл-әхвәлләрен белешә.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■



Содержание. Март 2018

В мире останется слово моё...: Сажида Сулейманова

Историческое наследие: «Нурсултан». О.Иванова; «Татарская деревня: прошлое и настоящее»; Кем был писатель, написавший «Буз егет» («Молодой парень») и «Тагир-Зухра»?» Г.Рахим; «Султан Султаная». Г.Масагутова, А.Габдукаева; «Что в имени твоем, Россия?» Р.Хафизов; «Трагедия «вилочников». Г.Мустафина-Рафикова; «Сложная судьба татарской женщины». И.Габдрахманов; «Письма Каюма Насыри».

Тюркский мир: «Поэт ссылки».

Татарский мир: «Татарин остается татарином, где бы он не был...»; «Герой нашего времени». Р.Батулла.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Педагогическое наследие: «Книга для чтения». Х.Абузаров.

Литературное наследие: «Письма Махмута Хасанова»; «Ради своей нации, своего народа...» К.Булатова; «Песня колокольчиков».

В глубине памяти: «Дорога в город или мальчик-беглец». Х.Заляй; «В памяти, до сих пор в памяти!»; «Сказать ли Саима апа...» Л.Лерон.

Художественное наследие: «Кто такой Василь Ахметзянов?»

На страже памяти: «Страна валенок»; «Газета «Работа»; «Наследие Гани Сафиуллина».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Content. March 2018

There are left my words in the world...: Sagida Suleymanova

Historic heritage: «Nursultan» by O.Ivanova; «Tatar village: the past and the present»; What was the write who wrote the prose works «Buz eget» («The young man») and «Tagir-Zukhra»? by G.Rakhim; «The sultan of the Sultanay village» by G.Masagutova, A.Gabdukaeva; «What is it inside of you, Russia?» by R.Khafizov; «The forklifts' tragedy» by G.Mustafina-Rafikova; «What a miserable fate you have, Tatar woman...» by I.Gabdrakhmanov; «Kayum Nasiri's letters».

Turkic world: «The poet of the exile».

Tatar world: «Tatar man remains Tatar wherever he is...»; «The hero of contemporary days» by R.Batulla.

Religious heritage: «The Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

Pedagogical heritage: «The book for reading» by Kh.Abuzarov.

Literary heritage: «The letters of Makhmut Khasan»; «For the sake of native nation and people...» by K.Bulatova; «The bluebells' song».

From the deepest storage of memory: «The way leading to the city or the a fugitive boy» by H.Zalyay; «Keeping the memory, still keeping!»; «Should I say Sayma apa...» by L.Leron.

Creative heritage: «Who is Vasil Akhmatzyanov?» by Akhtam Zaripov.

On the guard of the memory: «The felt-boots country»; «The newspaper «Rabota» («Labour»); «The heritage of Gani Safiullin».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

Гайшә Габдрахман кызы Рахманкулова 1913 елның 3 декабрендә Башкортстанның Кырмыскалы авылында туган.

1941 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый. 1942 елдан СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1974), Татарстанның халык рәссамы (1984).

Төп әсәрләре: «Татар өе» (1972), «Тукай-Кырлай» циклы (1976-1977 еллар).

1991 елның 3 маенда Казанда вафат була.

Гайшә Рахманкулова



«Флокс чәчәге». Кәгазь, акварель

«Язгы Казан». Кәгазь, акварель

«Авыл күренеше». Кәгазь, акварель

Артта басып торалар: Зәйтүнә, Кадыйр (язучы Атилла Расихның әтисе һәм әнисе); утырганнар: уңнан Галия апаның әтисе Мөгънетдин һәм әнисе Рәбига (балаларның берсе – Галия). Уртада – Галия апаның әбисе. 1915-16 нчы еллардагы фото Мөслим районының Яңа Карамалы авылындагы Хавис абыйның апасы Нәкыя апада сакланган.

«Тукай-Зәйтүнә, Галия һәм Хавис».
М.Әхмәтҗанов

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Үз-үземә. Габдулла Тукай
Тукай-Зәйтүнә, Галия һәм Хавис. Мөҗәһит Әхмәтҗанов
«Бишектән үк иртә төшкәннәр... » Илгизәр Фазлуллин
Түгәрәк өстәл: «Мәскәү һәм татар дөньясы»
Тарихи мизгелләр. Шаһинур Мостафин

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»* *журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

*«**БЕЗНЕҢ МИРАС**» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*